Безнең МИРАС
НАШЕ НАСЛЕДИЕ
04
апрель 2019
ISSN:2500-011X
ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС һӘМ ДОКУМЕНТАЛЬ ЖУРНАЛ

НИКОЛАЙ КУЗНЕЦОВ «ЯҢА КАЗАН»

Фотолар president.tatarstan.ru сайтыннан алынды

# АВЫЛ ЭШКУАРЛАРЫ ҖЫЕНЫ

14-16 март көннәрендә Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты, «Россиянең татар авыллары» Бөтенроссия иҗтимагый оешмасы белән берлектә, VIII Бөтенроссия татар авыллары эшкуарлары җыены уздырды. Әлеге чараның пленар өлешендә ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов та катнашты.

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.

Дәрдемәнд

Безнең МИРАС 12 +

04 (304)

**апрель 2019**

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

11

80 **ТАТАРСТАН САНДУГАЧЫ.** *Әгъзам Фәйзрахманов*



93 **БАГДАДТАН ХАТЛАР** *Назыйм Мәхмүтов*

# ЭЧТӘЛЕК

## ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 **Габдулла Тукай**

## ТАРИХИ МИРАС

4 **Сөембикә.** *О.Иванова*
11 **Төрки халыкларның гомуми тарихы.** *Х.Габәши*
18 **Тәрҗеман-әл-Әнҗерәи нәселе.** *А.Нәҗми*
22 **Яңа Болгар пүчинкәсе.** *З.Әхмәд*
25 **Тукаев кәнфитләре.** *Л.Мортазина*
26 **Тау Иленең ташъязма истәлекләре.** *Р.Мәрданов, И.Һадиев*
34 **Габдулла Тукай турында бер истәлек.** *Л.Мортазина*
36 **«Кулында форсат вакытта укып кал».** *Э.Сабирова*
40 **Тукай жандармерия документларында.** *Л.Гайнанова*
50 **Татарлар Грузияне дә коткарган.** *А.Галимҗанов*

## ТАТАР ГАМЕ

52 **Галимнең ике җиңүе.** *Ф.Садриев*
55 **Нәкыйп Каштанов: «Без – серле халык»**

## ДИНИ МИРАС

58 **Ислам дөньясы. Габдерәшит Ибраһимов**

## ӘДӘБИ МИРАС

64 **«Күңелем һәрчак сине эзли, кайларда син?!»** *М.Өзтүрк*
67 **Бикә Рәхимова шигырьләре**
70 **«Җиңел адымнардан соң»**
73 **Гаффаризмнар.** *Ә.Гаффар*
74 **«Әллүки»ле еллар.** *Х.Ширмән*
79 **«Хәтергә уелган китап» конкурсының нигезләмәсе**

## ХӘТЕР САНДЫГЫ

80 **Татарстан сандугачы.** *Ә.Фәйзрахманов*
85 **Күршем Хәсән Сарьян.** *Ф.Якупов*
91 **Иске альбом хатирәсе.** *Р.Хуҗәхмәтова*

Баш мөхәррир
**Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ**
**(Ләбиб Лерон)**
(843) 222-09-83 (17-92)

Баш мөхәррир урынбасары
**Фирдәвес Зарифуллин**
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә
**Ирада Әюпова**
*(ТРның мәдәният министры)*
**Разил Вәлиев**
*(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)*
**Илдар Гыйльметдинов**
*(Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе)*
**Айрат Зарипов**
*(Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе)*
**Андрей Кузьмин**
*(«ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры)*
**Рөстәм Мөхәммәдиев**
*(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)*
**Васил Шәйхразиев**
*(ТР премьер-министры урынбасары, БТК Милли Шурасы рәисе)*
**Лотфулла Шәфигуллин**
*(«ТАТТЕЛЕКОМ» АҖ генераль директоры)*

Редколлегия
**Ислам Әхмәтҗанов**
**Марсель Әхмәтҗанов**
**Альберт Борһанов**
**Рәдиф Җамалетдинов**
**Фәнзилә Җәүһәрова**
**Ринат Закиров**
**Фәйзелхак Ислаев**
**Зиннур Мансуров**
**Ким Миңнуллин**
**Гөлчәчәк Нәҗипова**
**Данил Салихов**
**Сөмбел Таишева**
**Рафаил Хәкимов**
**Ирек Шәрипов**

Җаваплы мөхәррир
**Ленар Гобәйдуллин**
89196911406

Дизайнер һәм биткә салучы
**Диләрә Нәүрүзова**
(843) 222-09-83 (17-93)

Корректор
**Дания Фәйзуллина**
(843) 222-09-83 (17-93)

Бүлек мөхәррире
**Ләйсән Данилова**
(843) 222-09-83 (17-92)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта:
**yanamiras@mail.ru**

**«Безнең мирас» (Наше наследие)**
**Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)**

**93** **Багдадтан хатлар.** *Н.Мәхмүтов*
**98** **Төшләремә кергән Алмания...** *Г.Дәүләтшина*
**100** **Истә, һаман да истә!**

## СӘНГАТИ МИРАС

**102** **Борынгы татар милли музыка уен кораллары.** *Р.Гыйләҗев*

## ТЕЛ КҮРКЕ — СҮЗ

**105** **Тукай шигърияте безгә ник якын һәм кадерле?** *В.Хаков*

## ХӘТЕР САГЫНДА

**108** **Татарстан Республикасының Милли китапханәсе**
**110** **Ядкәрләр табыла.** *Н.Фәттахова, Л.Харрасова*
**114** **«Иске Казан» дәүләт музей-тыюлыгы**

**116** **«Безнең мирас» хәбәрләре**
**118** **Мирасворд**
**119** **«Безнең мирас» елъязмасы.** *Март*

Заказ №О-803. Тираж – 2660 данә. Формат 70х108 1/16.
Басарга кул куелды: 25.03.2019.
Чыгу көне: 01.04.2019
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

**Чыганак-текстларда авторларның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.**
Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә юлланган язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела. Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми. Андый хаталар булса, техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин, Л.Лерон төшергән, авторлардан һәм Татарстан Милли музееннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан, Кукмара туган якны өйрәнү музееннан алынган фотосурәтләр, җиде томлык «Татар тарихы»ннан рәсемнәр файдаланылды. Тышлыктагы Ә.Тумашев рәсемнәре ТР Дәүләт сәнгать музее тупланмасыннан алынып бирелде.

**«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.**

Тышлыкның 1 нче битендә – **«Яңа Казан»**. 1957. ***Николай Кузнецов рәсеме***

# *Габдулла Тукай*
*(1886-1913)*

***

Ике юл бар бу дөньяда: берсе будыр –
бәхет эстәү;
Икенче шул: гыйлем гыйшкында булмак
– мәгърифәт эстәү.

***

Бар уем кичен-көндезен сезнең хакта
милләтем;
Саулыгың – минем саулык, авыруың –
минем авыруым.

***

Бик күңелсез бер начар журнал – гомер,
Анда, әлбәт, баш мәкалә мал ирер*.

***

Җиһанда үлми һәрбер ыңгырашкан
Вә юлны тапмый калмый һәр адашкан.

***

Ауру җанның бишмәте – тәнне дәваның төрлесе
Берлә һәр көнне ямыйм, иртән тагын ертык күрәм...

***

Укымак – ... гакыл пычагын гыйлем вә мәгърифәт кайрагына
чынлап кайрамак дигән сүздер.

***

Файдасыз бер ит кисәгеннән гыйбрәттер йөрәк,
Парә-парә кисмәсә гыйшык, мәхәббәт кайчысы.

***

Бер сүз әйтергә саранлансак гакыллы ярлыга,
Гөл кеби сүзләр чәчәбез акчалы ахмакка без.

***

Җир яшәрмәс, гөл ачылмас – төшми яңгыр тамчысы;
Кайдан алсын шигъре шагыйрь, булмаса илһамчысы. ■

---

*Ирер – бирер

# СӨЕМБИКӘ

Ольга Иванова

***Тәрҗемәчедән:***

*Сүземне башлаудан элек, аңа турыдан-туры мөрәҗәгать итүемне белдермәсәм дә, мәгълүм галимебез Мәсгуд ага Гайнетдиннең яңа заман рухында язылган хезмәтләренә (мәсәлән, «Гасырлар мирасы» китабына) игътибарыгызны юнәлтер идем. Андагы Казан-Кырым-Мәскәү хәлләрен тасвирлау һәм тәшвишләү бүген дә бибәһа...*

*Шул ук вакытта Сөембикә ханбикә шәхесен Кырым-Мәскәүдән, Сафагәрәйдән башка тулырак ачу мөмкин булмас иде. Сафагәрәй Казанга 1535 елда килә һәм ханлык белән яңадан идарә итә башлый. Нугай морзасының 24 яшьләрендәге кияве, Сөембикә (Сөенбикә) кебек асыл кошны – «атаклы бер бикәчне кулыннан ычкындырасы килмәенчә», үзенә хатынлыкка ала. Бикәнең агай-энеләре җизнине бигүк өнәп бетермиләр. Әмма Йосыф бәкнең гүзәл кызы үзе, булдыклы хан һәм бик хисчән ир-егет буларак, аны бик яраткандыр кебек. Җангали, әйтик, ирексез бер кол-хан сыйфатында, урыс кенәзе боерыгынча гына эш йөртә алса, Сафагәрәй, үзен олуг йорт хуҗасы итеп тойганлыктан, һәр тарафтан иреклe эш итә алган. Кыскасы, Һади Атласи сүзләренә кушылып, «бу еллар Казан ханлыгының иң куанычлы еллары – аның урыс боерындырыклыгыннан котылган, тынычлыкта калган бер чоры» булган, дип расларга мөмкин.*

...Әлеге токымнардагы күркәм сыйфатларның барысын да үзенә алган яшь айгыр сыгылма билле, җиңел аяклы, шул ук вакытта уенчак-шаян һәм рәхмәтле зат булып чыкты. Айнур ат чабышларына бәкнең шушы «егет»не алдыртуына шат, югыйсә, кем белә, ире, бәйгегә туры карабахта гына чыгып, хурлыкка да калган булыр иде. Кәкре танаулы кызу холыклы чабышкы исә морзаның нечкә күңелле хатынын өркетә, ул карабахлар турында: «Кем бөкре танаулы атка атланып чыга – менә шул адәм туп-туры ачып куелган кабергә юл тота», – дигән сынамышны кат-кат исенә төшергәләде. Айнурның бу туры аттан куркуын җиңәргә бары тик һәр төшкә барып кысыла торган җитез энекәше Хәйдәр генә ярдәм итте. Ул, көрәшкә чакыруларын ишетү белән, кушагын тыгызрак тартып, мәйданга ыргылды. «Мине көт», – дип, Айнур малайны йөгереп барган җиреннән эләктереп алган иде, тик тегесе, апасына күз кыры белән генә карап:

– Хатын-кызга ирләр күзләп, аларның эш-гамәленә тыкшынып йөрү килешми, әнә, балаң янында тор, – дигән булды.

Айнур көлеп җибәрде дә чая үсмернең колагыннан тартты:

– Минем улым йоклый, әле аны бала багучылар да күздән ычкындырмый. Ә син мондый кыланмышың өчен җавап тотарсың!

---

[1] Дәвамы. Башы журналның 2019 елгы 3 нче санында.

Безнең мирас №4 апрель 2019

**«Сөембикә».** Билгесез рәссам эше

Хәйдәр, ничектер җайлы гына борылып, балык кебек шуып чыкты да апасының кул ятьмәсеннән ычкынып, эзсез югалды. Ә Айнур, үз-үзен онытып, яшь кыз кебек, аның артыннан ташланган иде, шул тирәдә болганып йөргән бер эре түрәгә килеп бәрелде. Көлеп, башындагы авышкан калфакны төзәткән булды, тик гафу үтенү сүзләре аның ирененә ябышып калган кебек иде. Айнур агарынды, өнсез калды, әмма Мөхәммәд бәкнең чекерәеп кысылган күзләреннән карашын һичничек яшерә алмады. Ул сусыл иреннәрен, коеп куйган кебек ияген юкка гына япмасы белән каплап маташты, ир аны шунда ук танып алды. Ул, яшь хатынның өстендәге бай кием-салымына тиз генә күз йөртеп чыккач, аның кулыннан тотып, кайнар сулышына кабып пышылдады:

– Син миннән менә кайда качып ятасың икән, гүзәлкәем, дәрт чүлмәгем! Барыбер кочагыма керерсең, Мөхәммәд бәктән, мәшһүрлек вә кодрәтлелек бусагасы артында да, һичберәүнең яшеренеп кала алганы юк әле...

Хатын, аның кулыннан ычкынып, чатырга йөгерде, күкрәгендә дөп-дөп килеп тыпырчынган йөрәккәен басарга тырышып, калын чаршау артына кереп посты. Ефәккә төренгән бүлмәдә тынычлык хөкем сөрә, бала караучы хатын бизәкләп-сырлап эшләнгән матур бишекне тирбәтә, үзе бик ягымлы-йомшак итеп әлли-бәллине көйли иде. Бусагадан ук Айнурга бәбие Акморзаның кара чәч белән төренгән кечкенә башы күренде. Малайның дөньяга килүенә әле ярты гына ел, әмма Тәңрекол бәк хәзердән үк аны данлы борынгы нәселне дәвам итүче углан дип атый. Айнур, олы илченең өендә яши башлагач, үзенә куркыныч янап торган Мөхәммәд бәк турында да онытты. Тәңрекол көндәше булган куәтле түрәнең ач көчекләрен – нукерларны якын-тирәдән куып җибәрә алды, Айнурны исә, энекәше белән бергә, үз биләмәсенә яшерде. Алар күптән түгел генә Казанга кайттылар, курку-өркүләр дә инде читләтеп узгандыр кебек тоелды. Ә бәла әллә ни ерак китмәгән булып чыкты, бары тик барысы да тынычланганын көткән, баш очында гына әйләнеп йөргән икән ул тилгән һәм менә ваемсыз корбанын кабат иснәнеп тапты. Айнурның күзе ачы яшьләр белән мөлдерәп тулды. Ул бу хәлне иренә ничекләр җиткерергә икәнен әлегә белми, мәгәр әйтү-белдерү мотлак тиеш иде. Ә, бәлки, бөтен хатын-кыз дөньясын комсыз күзләре, тыелгысыз шәһвәте белән айкаучы бу мәлгунь мәхәббәт карагыннан кабат олуг илченең биләмәсенә кереп яшеренергәдер? Айнур ефәккә төрелгән оясыннан борынын төртергә дә бүтән базмады, улының бишеге янында тик кенә утырды, моңсуланды, авыр хисләргә бирелде. Ә җилдә тирбәнеп торучы чатыр диварлары артында тиздән батырларның бил алышу авазлары ишетелә башлады.

Халык төркеменең шау-гөр килүе астында мәйданга байтак ир-егет чыккан иде. Киң чалбарлар гына киеп алган ялан тәнле, таза күкрәкле, тулышкан беләкле, нык бәдәнле көрәшчеләр, беркадәр билдән бөгелә төшеп, кулларындагы киң билбауларны ныклап кыскан көе, сөзешергә җыенган үгезләр кебек, маңгайларын текә тотып, бер-берсенә каршы киттеләр. Тамаша кылучылар исә аларга соклануларын белдереп, исемнәрен атап: «Синнән көчлесе юк!», «Батыр асты калма!» – дип, төрле яктан кычкырдылар, кулларын изәделәр, үзләренең күңеленә һуш килгән көрәшчеләргә шул рәвешле дәрт биреп, көч өстәргә ашкындылар. Беренче бил алышу бик гайрәтле, ярсулы булды, мәгәр тиз кабынып, тиз сүнде. Батырлар мәйдан уртасында калды, җиңелгәннәр исә тамаша караучы гына булырга мәҗбүр иде. Янә бер көрәштән соң, билен биргәннәр мәйданнан читкә чыккач, батырлар түгәрәге тагын яртылаш кыскарды. Бер сәгать тә узмагандыр, уртада ике баһадир – Казан көрәшчесе Корычтимер белән нугай тумасы Айтуган гына калды. Болар бер-берсен шактый сынап карадылар: түгәрәк буйлап озаклап әйләнделәр, яшендәй тизлек белән, алдаучан ыргылыш-

лар да ясаган булдылар, әмма үзләре шунда ук читкә тайпылырга өлгерәләр иде. Халык, тыелып кала алмыйча, колакларны тондырырлык итеп сызгырды да, үкерде дә. Ниһаять, даладан килгән кунакның түземе төкәнде, Корычтимернең өстенә ташланып, аны коточкыч нык итеп билбавына кысып алды. Айтуганның муенындагы кан тамырлары зәңгәр төерләр булып кабарды, йөзеннән һәм аркасыннан борчак-борчак булып тир ага башлады. Нугай батыры инде тәмам җиңүгә ирешкән кебек иде, шул мәлдә аның кочагыннан Корычтимернең шома еланбалык кебек шуып чыгуын берәү дә абайламый калды шикелле. Нугай егете күз ачып йомган арада аркасына барып төште. Халык төркеме гөр килде: хәтта мәйдан хуҗаларының көр тавышы да Казан кешеләренең сөенеп кычкыруын, даладан килгән кунакларның көенеп әрнүен баса алмады.

Ә шул вакытта ерактан ук инде яңа бәйгегә дәшеп добулбас-барабан кагулар, авазкярләрнең күкләрне күкрәткән әче тавышы яңгырады. Тиздән ат чабышлары башланырга тора, халыкны хәзер Җыенның шул иң мөһим тамашасына чакыралар икән...

Казан ханбикәсе сарайга ялгызы гына кайтты, чөнки, чабышкылар бәйгесен карау белән, Сафагәрәй кабат Кабан-Сарайга китеп барган иде инде. Сөембикә ачык тәрәзә каршына килде. Җәйге чәчәкләргә чумган бакча утыргычларының күләгәле салкынча һавасы, серле борылышларга кереп югалучан таш җәюле сукмаклары белән сихерләп, үзенә тартып тора. Анда, кайдадыр, чит ил осталарының кулы белән эшләнгән, үрмә гөлләрнең куе яшел япмасына кереп яшеренгән мәгарә-куыш та бар бит әле. Сафагәрәй, ул серле почмакны, сөйгәнен шаккатыру өчен, осталарның өсләрендә үзе торып ясатты.

Күзләрен йому белән, хәрәм агасының аңа күптән көтелгән эндәшү сүзе алып килгән көн ап-ачык булып күз алдына килеп басты. Аерылып тору түзеп булмастай озак тоелды шул. Сафагәрәй яз җиту белән даругаларны тикшерергә дип киткән иде. Кайтуга ук, Сөембикәне төнге бакчага чакырды.

Сөйгәнен һәрвакыт таң калдырырга хыялланган хан төрле уйлап чыгаруларга маһир иде. Хатын, бакча сукмагына аяк басу белән, әсәрләндерә торган моңлы курай тавышын ишетте. Төрле төстәге утлар, җем-җем итеп, мәгарәгә бара торган юлны яктырта. Хәләл җефете белән очрашасы мизгел җиткәнен тою-сизү куанычыннан дулкынлануын көчкә генә тыеп, Сөембикә шул сукмактан алга таба атлады.

– Сөеклем, – дип пышылдады ул, – мин сине шундый сагындым, сөеклем.

Ханым, кытай фонарьлары белән яктыртылган мәгарәне күргәнче, адымын ешлата барды. Ә курай һаман тынмады, ул, елый-елый, үзенә дәшә-чакыра иде. Әмма пәрдә ярыгыннан бары курайчыны гына күреп – ә куышта бүтән кеше юк булып чыкты – Сөембикә бик ачынды. Күрәсең, ул ашыгыбрак килгәндер, ә хаким әнә бер дә ашыкмаган. Ханым, аптыраган кыяфәт белән, бусагада туктап калды. Курайчы ага, аны күреп, бил сонды, пәрдәне ача төште һәм эчкә керергә чакырды. Таш мәгарәгә уртада янып торган учак – бу якларга хас булмаган камин җан керткән иде. Идәнгә түшәлгән озын йонлы йомшак тиреләр дә хатынны гаҗәпкә калдырды. Гадәти сарай тормышына хас берни дә юк иде биредә, бары тик курайчының йөз-чырае һәм башына уралган ак чалмасы белән генә Сөембикәгә диңгезләр аръягында түгел, ә хан бакчасында булуын исенә төшерде. Көйче кураен шунда ук аска төшерде, башын иде, гәрчә ханбикә аңа таба карамаса да, тегесе кинәт калын, хисле тавыш белән сөйли башлады:

*«Йөз мең сөю хәнҗәре тәнем телгәләде,*
*Аерылышу йөз мең тикәнгә ташлап хурлады.*
*Тик шул чәнечкеләр арасында бер роза күргәч,*
*Шуның нәфис исен тоеп, күңелем хозурланды».*

Сөембикә, ачуланып, кашын җыерды, әрсез курайчыны тыймакчы гына иде, иренең елмаеп-көлемсерәп торган ягымлы карашын күреп, тукталып калды. Анысы тагын, кураен бер читкә куеп, күкрәгенә капланган хатынны куллары белән тотып күтәрде:

– Мин фәкыйрьне, бәхетсез мәхәббәт колын җәзага тарт, ханбикә! Йөрәген шушы учак утына сал, бәгырен көлгә әйләнеп беткәнче көйдер-яндыр, тик, Сөем, иреннәреңнең балын тоеп кинәнергә рөхсәт ит...

Сөембикә тирән сулап куйды. Теге күрешү җәй башында ук булган иде, инде җәй кояшы батуга таба бара, ә ханымның хәтерендә мәхәббәт мәгарәсендә иренең шул чактагы кайнар иркәләүләре әле дә суынып өлгермәгән. Ике ай да узарга өлгермәгән, тик Сафа аның ягына борылып та карамый кебек. Ханбикә яшертен генә сынап карады, хәрәм аталарыннан, кәнизәкләрдән сораштырды, әмма аларның берсе дә Сөембикәдән бәхетлерәк көндәшен атый алмады. Хуҗалары янында хатын-кызлар озак тоткарланмый иде, хаким аларны аерып куймады, аерып назламады. Нибары бер көндәш калды, ул – Сафагәрәй югалтудан иң курыккан хакимлек иде. Иренең көтмәгәндә суынуын Сөембикә үз-үзенә бары шуның белән генә аңлата алды. Әйе, бер борылышта баш күтәреп тәхетеннән бәреп төшерүләреннән өреккән хакимнең күңеле хәзер мәхәббәт уен-уйнашларында түгел. Ханбикә Казан байгураларының куштанланып-ялагайланып йөргән булулары артында үзенә каршы фетнә корулары торуын сизенгән Сафагәрәйнең никадәр хаклы икәнлеген әлегә белми.

Яшерен эшләр белән идарә итүче Мөхәммәд бәк исә уйлар чоңгылына чумды. Аны инде өлгереп җиткән фетнәдә катнашу ихтималы гына борчымый, ул төн йокыларын алган, әле очына чыгып җитмәгән эшен кайгырта. Бәкнең югары дәрәҗә биләгән булуы аңа күп тапкырлар мәкер, хыянәт юлына басып, кара гамәлләрен башкарып чыгарга булышты. Ул аларны «бөек ханлык мәнфәгатьләрен кайгырту өчен эшләнде», дигән күбек очыртулар белән каплый килде. Сарай хадиме шәхси дошманнарын кәкре каенга оста гына терәтә барып, аларның мөлкәтен үзләштерде, үз хәзинәсен зур ришвәтләр һәм мескен сәүдәгәрләрдән тартып алынган мал хисабына баетты. Олы карачы Булатширин үз канаты астына алган, «менә мин!» дип шәбәеп торган Мөхәммәд бәккә кем каршы сүз әйтә алсын да, кемнең, шымчылык итеп, Казан ханлыгына хыянәттә гаепләнәсе килсен?! Бәк теләсә нинди мәкер тозагын оста уйлап чыгара. Аның үткен акыл белән тулы йөгерек миендә беркайчан сынатмый торган гамәлләр беркайчан өзелмәс тоташ чылбыр булып туа тора. Ул бай сәүдәгәрне, яисә ерак авыл морзасын җиңел генә кысып хәерчегә калдыра ала. Әмма хәзер аның алдында танылган нәселдән чыгышы, куәте һәм хакимгә көчле йогынты ясый алуы, – кыскасы, бер ягы белән дә Мөхәммәд бәктән ким булмаган дошманы пәйда булды. Мөхтәрәм олы илче Тәңрекол яшерен эшләр белән идарә итүченең күптән үзенеке дип санаган корбанын алып китә алды, шулай итеп аңа чакыру ташлады. Мөхәммәд бәкнең, чүлмәкче бабасы куышында яшәп яткан мескен ятимә Айнурны күреп (елдан артык булыр инде), аңа нәфесе төшкәнлектән, шул гүзәлкәйне биләргә өметләнеп йөргән чагында юлын берәү дә кисә алмас кебек тоелды. Казанның иркле кызы, ярлы

булуына карамастан, һичкемнең дә колы яки кәнизәге язмышына дучар түгел, әмма кодрәтле бәккә бу чик була алмый иде, чөнки аңа «закун нипачум». Комсыз түрәгә нәмәгълүм юллар аша узып, Тәңрекол бәк чүлмәкче карт оныгын буй җитмәслек биеклеккә күтәрде, шулай итеп, Айнурны азгын түрәнең сөяркәсе булып калудан коткардым, дип уйлады.

Мөхәммәд бәк, тиз генә барып чыкмаган бу эше турында уйга бирелеп, кына белән буялган сакалын сыпырды; ә бит олы илченең хаклыгын инкяр итеп тә булмый. Әгәр Тәңрекол бәк хакимнең аягына егылып яшерен эшләр белән идарә итүче өстеннән шикаять итсә, Сафагәрәй күптән көтелгән очрактан ике дә уйламый файдаланыр иде. Мөхәммәд бәк олы карачы Булатширин куйган бөтен кешегә хакимнең өнәп бетермичә каравын тоя, әлбәттә, моңа гына аның акылы җитмәслек түгел. Хан ачыктан-ачык көрәшкә чыкмый, Казан диваны белән килешенгән, әмма тиз уалырга торучы тынычлыкны саклый. Тик олы илче Ширин әмиренең иң якын бер кешесе өстеннән шикаять белән керсә, бу – ханга каршы оешып килгән төркемне таркату өчен бер сәбәп булыр иде. Корбан тәкәсе итеп бер аны – Мөхәммәд бәкне чалырлар. Диван башлыгы хакимнең үзе белән каршылыкка керсә, ул ике арада үзенең гайрәтен югалтмас, дип кем әйтә ала?!

Мөхәммәд бәк әлегә шыпырт кына ятканда, Тәңреколның да аңа зыян саласы килмәстер, шәт.

Яшерен эшләр белән идарә итүченең шымчылары Айнурның тагын Казаннан китеп югалганын җиткерделәр.

Мөхәммәд бәкнең төрле тарафка баккан күзе пайтәхеттәге бер кыл селкенүен дә күрми калмавын Тәңрекол бәк беләидеме икән? Бу хатынны Итил сулары да яшереп кала алмастыр! Һай, ничекләр үзенә тартып тора ул! Мөхәммәд бәк, сулышы кысылганын сизеп, якасын чишеп җибәрде. Айнурның үзенә әсир иткән һәм яклаучысыз якты чырае аның хыялыннан беркайчан да китми. Ул инде, өлгереп җиткән җимеш кебек, тагын да чибәрләнә төшкән, түрәнең тыелгысыз шәһвәтен кузгата иде. Ләкин Мөхәммәд бәк үзен тыеп яши, акылсыз адымнар ясамый, бу адымнардан аңа куркыныч янавын, хан җәберенә дучар итәсен, алардан зиндан, хәтта мәет исе килгәнен аңлый. Шуңа күрә яшерен эшләр башлыгы башын «комга тыгып» тора, Тәңрекол бәк йортына исе китмәгән кыяфәт чыгарып, Чүлмәкчеләр бистәсе кызын күптән оныткан булып кылана. Аның күздән югалып торуы Айнурны да тынычландыра, ул элеккечә яши башлый. Ә бәк, өметен әле һаман да югалтмыйча, җае чыкканын көтеп ята.

Бу айларда пайтәхеттә дә Мөхәммәд бәкне әле утка, әле суга салган дәрт-теләкләр көчәйгәнлеге аермачык сизелә. Ханлык, көмеш табактагы каклаган каз кебек, бөтен дөньяны йотарга торган хакимият ияләренең борынын кычыттыра, күзләрен кыздыра. Казанга инде әнә үз чапанын кидерергә, шималь төрекләре мәрҗәнен кесәсенә бөтереп тыгарга хыялланган төрек солтаны кулын суза. Бөек госманлының ихтыярына каршы килергә курыккан, аңа бу ниятендә булышырга әзер булып билен бөккән Кырым ханы Сахибгәрәй: «Боерыңыз, әфәндем», – дип кенә тора. Казан өстеннән хакимлек итәргә өметләнгән Себер һәм Нугай олысларындагы күпме «кап та йот»ның төн йокылары качкан вакыт. Мәскәү кенәзләре Касыйм тәхетенә күтәргән Шаһгали дә, кичтән таңга кадәрле, үзен Казан хакиме булганмын икән дип төшләнеп ята. Сафагәрәй аяк астындагы туфракның ныклы булмавын тоеп яши, ул инде Кырымнан үзенә ярдәмгә яңа көчләр чакыра башлады. Тегеләре исә Итил ярларына гаиләләре һәм вак-төяк мөлкәтләре белән килергә ашкынып тора, тик алар бабаларының данлы исемен һәм элеккеге шөһрәтен генә алып килә ала. Кырымлылар Казанга майлы калҗа өмет итеп килә, ә Сафагәрәй аларны үз янына сыендыра бара, һәркайсына Ка-

зан бәкләреннән тартып алынган биләмәләр һәм җирләр бүләк итә. Ханның мондый кыланмышлары инде әлегәчә сабырлыгын җуймаска тырышып, әдәп саклап торган кыюсыз казанлыларны да баш күтәрергә этәрде.

Шулай итеп, башкала галәмәт зур казан кебек кайнарга кереште, бу канәгатьсезлекнең чиктән ашып, әлеге уттай кызган казанның кырларыннан ташып чыкмый торуы мөмкин дә түгел иде. Ә сарай тирәсенә оялаган түрәләр түнтәрелеш башлау өчен шуны гына көтеп тора. Олы карачы Булатширин, үзенә нинди куркыныч янавын аңлавына карамастан, Мәскәүгә яшерен илчелек җибәрергә вакыт җиткәнлеген аңлады. Гәрәйләр баскынчысын тәхетеннән бәреп төшерергә ярдәм сорадылар, ә Мәскәү шуны гына көтеп тора иде. Митрополит Макарий көн саен яшь кенәзне кыздыра, бай күршеләренә яу чабарга кыстый, вәгазьләре белән оста итеп үз вәсвәсәсенә бирелергә өнди, тегесе исә көрәшкә ташланырга җиңнәрен сызганып куйган иде. Кенәзлекнең көнбатыш чикләрендә Литва белән солых төзелгәч, Мәскәү хуҗасының куллары чишелде. 1545 елның язында Иван IV яу кылычын Казанга таба юнәлтте.

Әйе, Казанны олы тетрәнүләр көтә. Моңа сөенеп, учларын уып йөргән Мөхәммәд бәккә олы илче Тәңреколның үз гаиләсен, пайтәхет баскынчылар камалышында калганчы, Нократ буендагы биләмәсенә яшерергә ниятләвен җиткерделәр...

Бәкнең озак көтелгән сәгате сукты.

Хуҗасы чакыруын ишеттеме-юкмы, каршында, «ә» дигәнче, йөзбашы Тимер җир астыннан калкып чыккан җен шикелле пәйда булды.

– Хәзер синең чират, – дип, кыска гына, әмма кистереп әйтте Мөхәммәд бәк.

Тимернең тирән яра эзе калган чыраен караңгы елмаю яктыртып җибәрде. Күпме көтте бит бу мизгелне Тимер, әмма бәк каршында югалган ышаныч-абруен барыбер кире кайтаруга иреште! Югыйсә, чүлмәкче кызы Айнурны күздән ычкындыруы аның тамагына сөяк булып кадалган иде, хуҗасының канәгатьсезлеген шул көннән башлап кат-кат тоярга туры килде. Ә менә хәзер асыл кош үзе аягыннан килеп эләгергә тора!

Нөкәрләр[1] башлыгы бәк каршында тагын бер кат бил бөгеп:

– Ничә яугир алыйм? – дип сорады.

– Олы илченең никадәр сак җибәрүе сиңа мәгълүм булса кирәк. Шулардан икеләтә күбрәк кеше ал! Берсен дә исән калдырма, миңа ул хатын гына кирәк, калганнарны...

Мөхәммәд бәк туктап калды, бары тик усал күзләре генә Тимернең сөаль белән катып калган чыраен бораулады. Ул тугрылыклы «башы бозык» сүзен дәвам итеп китәр дип уйлаган кебек иде, әмма йөзбашы нindидер сан әйтергә кыенсынды, шуннан соң бәк, авыр сулаган булып:

– Мондый болгавыр чакта уенның ахыры теләсә ни белән бетәргә мөмкин, – диде.

– Бик ихтимал, хуҗам, – дип, аның тел төбен төшенгән кыяфәт белән, баш какты ир. – Урыслар якынлашып килә бит.

Дәвамы бар

*Урысчадан **Мөдәррис Вәлиев** тәрҗемәсе* ■

[1] Нөкәр (нүкәр, нокыр) – ханга гына буйсынган гаскәриләр, хан гвардиясе (А.Тимергалинда, Р.Әхмәтьяновта төрлечә язылыш).

Безнең мирас №4 апрель 2019

# Төрки халыкларның гомуми тарихы

Хәсәнгата Габәши

## Туран кавеме

Яфәс нәселеннән монгол кыяфәтле бер адәм (тарихчылар әйтүенчә, төрек), кавем вә кабиләсе илә, Азия урталарына, Ысык-Күл вә Алтай таулары тирәсенә килеп җирләшмештер. Заман күп узу берлә болар да, әлбәттә, күбәймешләр. Табигый, әүвәлге урыннарына сыймый, төрле тарафка сачелергә мәҗбүр булмышлардыр. Болар да арий кавеме кеби бик күптөрле тармакларга бүленделәр. Һәркайсы бер тарафка китеп җирләштеләр йә күчмә мәгыйшәт иттеләр. Туран кавеменең күбрәге күчмә мәгыйшәтле булганлыктан, аерылулары, кабиләләргә бүленүләре дә бик тиз булыр иде. Әмма араларында береннән куәтле хан чыкса, бергә җыелулары да бик тиз булыр иде. Куәтле ханның куәте илә янә бүленерләр иде.

Дәвамы. Башы журналның 2019 елгы 2 нче санында. Текст хәзерге телгә берникадәр якынайтылып бирелә.

Тарих вә гыйльме кыяфәт (антропология. – ***Ред.***) голәмәсенең тикшерүе илә туран кавеменнән ошбу кавемнәр саналадыр: кытай – чин, һиндукытай – мачин, тибет, япон кавеме, Корея халыклары, фин ыруглары, төрек халкы, аннамнар, татар вә монголлар, тунгуслар, бурятлар, малай ыруглары, Төньяк диңгезе тарафындагы гипербури халыклары – юкагир, гыйлак, аен, камчадалы, чукот, коряк, нумулус, эскимус, алеут, теленгут вә гайреләр.

Бу гыйлем илә бик озак вакыт шөгыльләнмеш немец голәмәсеннән антрополог Фридрих Мюллер туран кавеменнән илле ике кавем саныйдыр. Искә алынганнардан кайберләре янә күп кавемгә бүленәләр. Мисал: төрек ыруы 17 олуг фиркагә бүленмештер.

Ошбу кавемнәр барчасы Төркестан сахрасыннан сачелмеш халык булганнары өчен туран кавеме дип аталмышлардыр. Төп урыннары Алтай таулары булганлыктан – алтай кавемнәре, халкының күбрәге угыр вә уйгыр исемендәге кабиләдән таралдыгы өчен, угыр-алтай төркеме дип аталмышлардыр.

Һәрберсенең йөз-кыяфәтләрендә монгол кыяфәте булганлыгыннан, монгол йә монгол рәвешле кавемнәр аталмышлардыр. Төрек ыругларының да барча төркемнәрендә монгол кыяфәте ачык беленер. Башка кавемнәр илә катышмаган саф төрекләр монголлардан да артыграк монгол кыяфәтендә табылмышлардыр. Моның өчен монгол рәвешле кавемнәрнең барчасын, ягъни туран кавемен «төрек ыругы кавемнәре» атамышлардыр.

## Кытай-чин халкы

Арий кавемендә күрелмеш хәл туран кавемендә шулай ук күрелмештер. Ягъни халык үрчү вә күбәю сәбәбеннән, туранилар да урыннарына сыймамышлардыр. Төркемнәр үзләренең максатларына муафыйк урын тапканчыга кадәр вә артларыннан икенчеләре куудан туктаганчыга кадәр китәр иделәр. Туранилардан бәгъзеләре ошбу көннәргә кадәр күчмә мәгыйшәт итмәктә булсалар да, араларыннан кайберләре бик иртә утырма мәгыйшәт итә башламышлардыр.

Туран кавеменнән иң элек чин-кытай вә япон халкы шәрык вә җәнүб-шәрык тарафына юнәлмешләр. Әүвәлдә Тибет кыйтгасында берничә вакыт киченеп, беразы шул җирдә калмыш һәм «тибет халкы» аталмышлар. Күбесе янә шәрык тарафына китеп, Һуанһе илә Янцзы елгасы арасына җирләшмешләрдер. Соңрак океан ярларына вә утрауларга кадәр сачелделәр. Кытайлар үзләрен дөньяның иң иске кавеме хисап итәләр. Ике йөз мең ел элек бабаларыннан калмыш әсәрләр күрсәтәләр. Утырма вә мәдәни мәгыйшәт, гыйлем вә мәгариф, һөнәр вә сәнагать җәһәтеннән, дөрестән дә, кытайлар бик иске халыклардыр. Дөнья тереклеге өчен хаҗәт һәрнәрсә үзләренә җитеш. Гыйлем вә мәгърифәт, һөнәр вә сәнагать тә аларда бик иртә баш күтәрмешләрдер. Бу сәбәптән аларның башка кавемнәргә ихтыяҗы төшми, алар илә һич аралашмый, катышмый, үзләре бармый, үз эчләренә башкаларны җибәрми, үзләре генә тереклек итәр иделәр. Бу сәбәптән искедән мәдәниятле, мәгарифле кавемнәр – сәмиләргә, арийларга боларның дөньяда барлыклары да мәгълүм түгел иде. Соңрак барлыклары беленсә дә, аралашулары аз булдыгыннан, болар хакында мәгълүмат янә бик аз иде.

Соңрак, аралашу заманнары җиткәч, хәлләре беленде, тарихлары укылды. Ата-бабаларына бик мәхәббәтле вә алар әхвәлен белергә бик һәвәсле булдыкларыннан, аларда тарих бик искедән языла килмештер. Төрек ыругы кавемнәре илә һәрвакыт күршелектә булып, алар илә катышулары вә тарихи вакыйгалары бик күп булдыгыннан, аларның тарих китапларында безнең төрки кавем хакында да бик күп хәбәрләр язылмыш табылды.

Чинлеләр, төрек ыругларыннан татарлар илә каннарын катыштырдыкларыннан, монгол исемендә кавем хасил булмыштыр. Бу монголлар бервакыт бөтен җир йөзендә булган төрки кавемнәргә хаким кавем буларак катышып аралашмышлардыр.

Кытайлар соң заманга кадәр саф вә пакь холыклы, хыянәт вә ялган сөймәс, һөнәр вә мәгарифкә тырыш, аз илә канәгать итүче халыклардыр.

## Кытайларда мәдәният вә дин

Кытайлар бик иске заманнардан бирле шәрыкның иң һөнәрле, мәгарифле вә иң куәтле халкы иде. Ләкин, иске заманнарга бик мәхәббәтле вә искелекләрендә фанатик булганлыктан вә моның илә горурланганлыкларыннан, заманның вә аның яңалыкларын танырга теләмиләр. Заман да моның өчен аларның колакларын каты итеп борды. Үткен кытайлар тиз көннән уяндылар. Һәр хосусларын заманның теләвенә күрә яңартырга керештеләр. Әүвәлдә хур вә түбән санаганнарын бүген үзләренә остаз иттеләр. Кавемнәренең сәламәт вә дәвамы өчен кирәк булган гыйлемнәрне укый башладылар. Бу кеби кавемнәрнең алдагы көннәре ничек булачыгы үзеннән-үзе мәгълүм. Күрәзәлек итү хаҗәт түгел.

Кытайлар әүвәлдә будда динендә иделәр. Соңрак ислам дине гадәттән тыш тизлек илә эчләрендә сачелде. Бу көндә җитмеш миллион кадәрле кытай ислам динендә. Пекинда гына да 32 җәмигъ мәчет бар. Хөкүмәт даирәләрендә вә югары вазыйфаларда да күбрәк мөселманнар. Бу ел бер мөселман кытай генералы Петербургка да килгән иде. Кытай мөселманнарының киләчәге хакында олуг өмидләр бирердәй хәбәрләр сөйләмеш, милли вә дини, гали фикерләр бәян итмештер.

Кытайны ничә мәртәбәләр төрек кавемнәре яулап алсалар да, мәдәни вә мәгърифәтле кавемнәр арасында мәдәниятсез вә мәгърифәтсез кавемнәр, кирәк җиңүче, кирәк җиңелүче булсын, яши алмадыгыннан, үзләре кытайлашып, кытайларның күбәю вә куәтләнүенә вә төрек кавеменең азаюына вә зәгыйфьләнүенә хезмәттән башка нәтиҗәсе күрелмәмештер.

Пекин шәһәре – кытайларның пайшәһәрләредер. Падишаһ сарае шәһәр уртасындадыр. Моның әйләнәсеннән ике кат шәһәр чолгамыштыр. «Эч шәһәр» яки «Татар шәһәре» аталмышында татарлар тереклек итәләр. Тыш шәһәрдә башкалары тереклек итәләр. Падишаһлары манҗур нәселеннән төрек углы бер татардыр.

## Япон кавеме

Япон яки җапун халкы туран кавеменең бер тармагы булуын югарыда күрмеш идек. Японнар да Алтай вә Ысык-Күл тирәсеннән китеп, шимал-шәрык тарафына, хәзерге урыннары – Тын океанга кадәр җитмешләрдер. Япон халкы нәселе хакында төрле фикерләр вә бәхәсләр күп булса да, асыл дөресе будыр: чин, төрек (манҗур-монгол), аен кеби турани кабиләләрнең катнашуыннан хасил булмыш бер кавемдер. Б.э.к. 660 елларга кадәрге хәлләре ачык мәгълүм түгел исә дә, шул вакытларыннан игътибарга алырлык тарихлары башланадыр. Б.э.к. 585 елда бөтен Япония бер мөстәкыйль дәүләт сурәтенә кереп, микадулалар дәүләте төзеделәр. 1600 ел дәвамында чин-кытай мәдәнияте йогынтысында булып, гыйлем вә мәгариф, язулары вә башка гореф-гадәтләре чиннан алынмыш иде. Чыңгыз хан углының углы (Коблай хакан), Чин-Кытайны алганнан соң, дүрт мең көймә илә Япониягә гаскәр җибәрмеш иде. Ләкин япон хакимиятенең тырышлыгы вә бер куәтле елның ярдәме илә Коблай хакан хакимиятенә керми калдылар. Аурупа исә Япониянең дөньяда барлыгын мәшһүр сәяхәтче Марко Полоның Япониягә сәяхәтеннән соң гына (XIII гасырда) белде.

## Японнарда мәдәният

Япон халкы, кытайлар кеби, искедән мәдәни, ягъни гыйлем вә мәгариф, һөнәр вә сәнәгать, сәүдә илә мәшгуль кавем иде. Кытайлар кеби, ата-бабаларына вә аларның гореф-гадәтләренә, мәгарифләренә бик мәхәббәтле иделәр. Бу сәбәптән, заман вә әхвәл теләгән шәйләрдән бигрәк, ата-бабалары юлына игътибар итәрләр иде. Япониядә гореф-гадәт күбрәк вакыт бер рәвештә, искечә барса да, заман вә әйләнәтирәләрендәге әхвәл бер тәртиптә бармас, бәлки, һәр җирдә күрелдеке кеби, һаман алышыныр иде. Әүвәлдә Япониянең дөньяда барлыгын да белмәгән ауропалылар вә америкалылар 1853 ел тирәләрендә, дошманнарыннан саклау вә аларга хәерхаһлык итәр өчен, дигән сылтау белән Япониягә килеп җиттеләр.

Бу вакыйга японнардан күбесенең күзен ачтырды. Япон кавеменең сәламәт вә сәгадәтләре өчен ни нәрсәләр кирәк идекен колакларына укыды. Мәдәниятләрен заман теләвенә күрә яңартмыш – һәр кавемдә күрелдеке хәл – боларда да күрелде. Сәламәт вә сәгадәтне барчасы теләделәр. Ләкин төрле юлдан эзләделәр: кайберләре, сәламәт вә сәгадәтне ялгыз ата-баба гыйлемен өйрәнүдә күрделәр. Кайберләре, заман вә әхвәл теләүләрен яхшы танып, кирәгенчә яраклануда вә коралларнуда күрделәр. Бу ике фикер арасында низаг озак вакыт дәвам итте. Әмма, соңгыларының нык вә сабыр эш күрә белмәкләре сәясендә, гомумнең фикере болар тарафына авышты. Соңрак ауропалы вә америкалыларның химая вә хәерхаһлары да нидән гыйбарәт идеке ачык беленә башлады. Дөньябызның да бер күңел ачу мәйданы түгел, бәлки иске-искедән кавемнәрнең бере икенчеләре өстенә чыгар өчен низаг вә һөҗүмнәр итмешләр, һөҗүм вә буйсындырулар мәйданы идеке японнарга аңлашылды. Алар, үзара бетмәстөкәнмәс ызгыш вә низагларга аз игътибар итә башлап, сәламәт вә сәгадәт юлын бигрәк тә тырышып эзли башладылар. Таптылар! Ләкин Ауропа модаларына ияреп тә түгел вә ата-баба юлыннан бөтенләй чыгып бетмәктә дә түгел, бәлки өсләренә килгән вә киләчәк дошманнарының күңелләрендәге вә кулларындагы коралларын гаять дикъкать илә тәфтиш итеп, аның илә коралланмакта таптылар. Әмма, аз санлы халыкка күп санлы дошман аяк астында изелүдән котылыр өчен, бу кораллар дошманнарыныкыннан күпкә яхшы вә куәтле булу шарт идекен белделәр. Японнар бу юлда бар иҗтиһадларын сарыф иттеләр. Тырышлыклары бушка китмәде. Бу сәбәптән хәзерге көнебездә Япония Ауропаның иң куәтле державалары сафына керде.

## Японнарда әхлак, гореф вә гадәт

Япон халкы гомумән саф вә пакь холыклыдыр. Хыянәт, угрылык кылмас, ялган сөйләмәс. Җәбер вә золым вә җинаять итмәс. Исерткеч эчмәс, тиз ачуланмас, никадәр ачуландырылса да, фәхеш вә усал сүзләр сүгенмәсләр. Һичкемнән мыскыл итеп көлмәс. Гыйлем йә мал вә хиссият илә үзен бөек куймас вә мактанмас. Буш күстәрелешләр (күз буяу. – ***Ред.***) илә шөгыльләнмәс, хирыс вә комсызлык кылмас. Мал исраф итмәс, файдасыз вә мәгънәсез матдәләргә алданмас. Һәркем илә күркәм вә туганнарча мөгамәлә итәр. Шулай да саклыкны кулыннан ычкындырмас, ягъни башкалардан үзен алдатмас. Аз илә канәгать итәр. Эшкә бик тырыш, гыйлем вә мәгарифкә чамасыз иҗтиһадлы, һөнәр вә сәнәгатькә бик һәвәсле халыклардыр.

Японнарда гаять яхшы вә үрнәк булырлык бер-ике эш бардыр. Әүвәле, гыйлем вә мәгариф, һөнәр вә сәнәгать бабында ата-баба эше илә канәгать итмәдекләре хәлдә, боларга тел тигермәсләр. «Заманалары шулай булмыш, фикер куәтләре дә шул микъдар булмыш», – диярләр. Киресенчә, япон кавемен вәхшәттән – бәдәвияткә, бәдәвияттән

мәдәнияткә чыгардыклары өчен, ата-бабаларына тәшәккер итеп, рәхмәт укырлар, анларны хөрмәт илә яд итәрләр. Икенчедән, Ауропадан файдалы вә зарур гыйлемнәр вә һөнәрләр үгрәндекләре хәлдә, зарарлы вә киракмәс гореф-гадәтләрне нигездә кабул итмәмешләрдер. Ауропаның исраф вә бозыклыгы читтә торсын, файдасыз гореф-гадәт вә модаларын эчләренә бөтенләй кертмәмешләрдер. Зарурәте булмаганда ата-баба горефен вә милли гадәтләрен алыштырмамышлардыр. Лондон вә Париж профессорларына тиң бер япон профессорының мәгыйшәт вә тереклек рәвеше иске вә аз мәгърифәтле, урта хәлле бер японнан аермалы түгелдер. Мәгарифтә Лондон вә Берлин студентларына тиң бер япон студентының төс вә кыяфәт, кием-салым вә тереклек рәвеше көч-хәл илә укый-яза белә торган бер япон яшеннән аермалы түгелдер. Университетларда югары фәннәрдән дәрес бирелер. Әмма профессор һәм студентлар арзанлы, ләкин пакь милли кием вә кыяфәттә, пакь идәннәргә тезләнеп утырдыклары хәлдә, дәрес бирерләр вә тыңларлар. Фәкыйрь студентлар милли киемнәрендә үзләре өчен милли рәвештә аш та хәзерләрләр.

Япониядә фәкыйрьлек мәгарифтән, хәтта университеттан чикләми. Мәгариф бабында дөньяның һич җирендә күрелмәмеш хәл японнарда күрелер: студент-кучер, студент-извозчик, студент-лакей, студент-повар, студент-поденщик башка җирдә булмас, Япониядә булыр. Болар өчен хезмәттән буш вакытларына тугры килтереп, университетларда иртә вә кичләрдә махсус дәрес вакыты булыр. Имди бу рәвештә булмыш кавемнең киләчәкләре алдагы көннәрдә ничек булачагы үзеннән-үзе мәгълүм, бәян итү хаҗәт түгел.

## Япониядә – дин

Япониядә искедән бирле будда дине гомуми диндер. Будда дине – дин вә игътикад бабында инсаннарга тәмам хөррият вә тигезлек бирдеге хәлдә, әхлак юлында бик гүзәл нәсыйхәтләр итәр, ислам диненә охшаган бер диндер. Игътикад вә гамәл бабында кайбер хакыйкатькә хилаф эшләр, әлбәттә, ахырдан барлыкка килгән. Япониядә бу көндә дә диндә тәмам хөррияттер. Японнар дин хосусында Ауропа халкының тәмам киресеседер. Ауропада галимнәр вә мәгариф тәрәккый иттеге сәбәбеннән динсезлек тә шулкадәр артыр, Япониядә исә, киресенчә, галимнәр вә мәгариф тәрәккый итү нисбәтендә хак дингә мәхәббәт шулкадәр артадыр. Хак дин кайсы дин? Моны тикшерү өчен рәсми сурәттә махсус комиссия тәгаен ителмештер. Һәр дин әһеле махсус адәмнәр күндермешләрдер. Аңлашылуынча, японнарның ислам диненә мәхәббәтләре куәтледер. Әгәр будда диненнән башка дингә күчсәләр, әлбәттә, ислам диненә күчәчәкләрдер.

## Төрек вә япон мөнәсәбәте

Госманлы кардәшләребездә кайбер мөхәррирләрнең госманлы төрекләрендә аерылып торган бер хиссият күрдекләреннәнме яисә Ауропа халкының пантюркизм (иттихаи-төркия) илә гаепләүләреннән хәвеф итепме вә башка бер сәбәптәнме, башка төрки кавемнәр хакында бик игътибарсызлык илә яздыкларын күрәбез. Төркиләрнең госманлылар илә карендәшлек мөнәсәбәтен бәян итү читтә торсын, төрек исемен дә күп төркиләр илә уртаклашасылары килми, күп төрки кавемнәрне «татар кавеме» дип атарлар. Бабалары илә тәмам бер дәрәҗәдә булган бәдәви төркиләр хакында «вәхши кавемнәр» гыйбарәсен куллананалар. Бу көндә төрки тел илә сөйләшеп, үзләрен төрек таныганнарны, борынгыдан бирле Төркестан сахраларында яшәмешләрне гүя хаксыз төрек аталмышлар, имеш кеби күрсәтмәктәләрдер. Японнарны да диңгез утраула-

рыннан килгән бер кавем кеби күрсәтеп, телләрен тураннан чыгарырга газапланырлар. Киресенчә, дөреслекне тикшерүдән башка һичбер ниятне белмәгән, каләмнәрен һичкемнең кәефенә ияртмәгән, салкын канлы немец голәмәсе, озак тикшерүләр соңында, япон илә төрек кавемнәренең бере-беренә карендәш идекләрен, телләре дә төрек-татар теленә нистәбәтле идекләрен исбат итмешләрдер. Без бу хакта үз тарафыбыздан сүз әйтми генә хөкемне укучыларыбызга калдырабыз. Фәкать, мисал өчен җөмләдән бере буларак, бер немец хатын тәкъдим итәм.

***

«Берлин тагенблат»ның Истанбул мөхбире мәктүбләренең берендә язадыр: «Ерак шәрык вакыйгаларында төрекләр японнар тарафына якынаялар. Бу якынаюның сәяси сәбәбеннән башка янә бер сәбәбе бардыр. Ягъни бу якынаю сәбәбе – бу ике кавемне берен-беренә баглаган карендәшлектер. Ошбу карендәшлек мөнәсәбәтен ун ел элек Мюнхен (Бавария) профессоры Науман күрсәтмеш иде. Профессор Науманның фикере, әлбәттә, бик игътибарлыдыр, чөнки ул Японияне бик дикъкать илә тәфтиш кылмыш, хәлләренә бик дөрест итагать кылмыштыр. Японияде озак вакыт геологический институтның мөдире булмыштыр. Моның соңында Якын Шәрык (Төркия) илә дә бик тәфсыйл илә дөрест хезмәттәшлек әйләмештер. Өстән караганда бөтенләй башка күрелгән бу ике кавем күп хосусларда бере-беренә охшаган, карендәшлекләре дә шөбһәсез табылмыштыр.

Барчасыннан элек Науман телләрен күрсәтәдер. Төрек вә япон телләре, гомуми рәвешләренә карганда, төрек-татар телләренә карый. Бу ике тел кәлимә вә җөмләләр тәшкилендә генә түгел, бәлки кулланылыш рәвешләрендә вә лексик сыйфатларында да бере-беренә бик охшашлылардыр. Бу охшашлылык шулкадәрдер ки, Науман үзенең Анатоли сәфәрендә төрекчә әйтелмеш сөальләргә японча җавап бирмештер. Күп хосусларда, гәрчә лөгатьләре бөтенләй башка булсалар да, мәгънәләрендә бу телләрнең карендәшлеге һаман да мәгълүмдер. Мисал өчен, һәр ике тел тәмәке тартмак мәгънәсен «тәмәке эчмәк» дип әйтәләр. Моннан соң Науман бу ике кавемнең гореф вә гадәтләрендә дә күп охшашлык барлыкны күрсәтәдер: һәр ике кавем холкы вә табигате белән дипломатлардыр.Төрекләрне без бу тарафтан күптәннән таныйбыз. Әмма хәзер без японнарда да бу табигать барлыкны танырга мәҗбүр булабыз. Һәр ике кавем тугмышларыннан гаскәриләрдер. Бу ике кавемнең бере-беренә охшашлыгы мәгыйшәт рәвешләрендә вә башка бик күп гореф-гадәтләрендә дә күреләләр. Науман үз әсәрендә, дәлил өчен, боларны бик гүзәл исбат итүче күп мисаллар китерәдер. Науман әсәрендә моңа да дикъкать итәдер ки: төрек илә японнар Аурупа мәдәниятенә һәр икәвесе бер ноктаи назардан (караштан. – ***Ред.***) карыйлар. Аурупаның гореф-гадәт, тормыш, модаларын бөтенләй кирәкмәскә вә алар өчен файдалы түгелгә саныйлар. Японнар, Аурупа гыйлем вә мәгарифен бик олуг рәвештә алдыклары хәлдә, мәгыйшәтләре хакында булган ноктаи назарларын бу көнгә кадәр алыштырдыклары юктыр. (Ягъни Аурупаның йөреш-торышы хакындагы модаларын һаман да кабул кылмыйлар)». «Берлин тагенблат»ның бу мәкаләсен «Петербургские ведомости» газетасы да 1904 елның 16 июнендә нәшер кылмыш иде. ■

# ТӘРҖЕМАН-ӘЛ-ӘНҖЕРӘИ НӘСЕЛЕ

Алсу Нәҗми

### Тәрҗеманиларның Түбән Майна авылына килеп төпләнүе

Авыл картлары хәтерендә Тәрҗеман бабайның Әнҗерә авылыннан Түбән Майнага күченүе турында хәбәрләр сакланган. Ул заманда укымышлы муллаларга ихтыяҗ зур булганлыктан, Тәрҗеман хәзрәтнең дә, имам вазыйфасын башкару өчен, безнең авылга чакырылуы бик мөмкин. Ләкин бу хәл аның яшь вакытында булуы ихтимал, чөнки 1816 елда Тәрҗеман (Тәрҗи) Шәриповның үз гаиләсе белән Әнҗерә авылында яшәгәне билгеле.

Тәрҗеманнар нәселен Түбән Майна авылында таратучы Шәрәфетдин хәзрәт була. Ул, 1857 елда, Казандагы дамелла Габделгалләм хәзрәт Апанай мәдрәсәсен тәмамлап, имам-хатыйп һәм мөгаллимлек итүгә указ алганнан соң, мулла эшенә керешә. Ләкин рәсми рәвештә бу авыл кешесе булып 1867 елдан гына исәпләнә. Шуннан чыгып, Шәрәфетдин мулла Түбән Майнага түрәләр боерыгы буенча түгел, ә үз теләге белән килгәндер, дип әйтә алабыз. Шәрәфетдин Тәрҗеманов кырык бер ел дәвамында Түбән Майнада гына түгел, ә күршедәге Шәмә һәм Чуаш Ялтаны, Наратлы Елга авылларында да мулла вазыйфасын башкара. Халык телендә аның полковник дәрәҗәсендә саналуы һәм корал йөртергә хокуклы булуы турында да хәбәрләр бар.

Шәрәфетдин хәзрәтнең 13 баласы була. Шуларның җидесе генә, үсеп җитеп, үз гаиләләрен булдыра. Кызлары Гөлфрүз – Такталы авылы мулласына, Вәсимә – Гаделшә мулласына, Кәшифә Баганалы кешесенә кияүгә китеп, шул авылларда гомер иткән.

Ир балалары барысы да, аталары кебек үк, Казандагы Апанай мәдрәсәсен тәмамлый. Олы улы Минһаҗетдин 1889 елда, указ алып, авыл мәчетенең икенче имамы итеп тәгаенләнә. Кәшәфетдин 1906 елда мәдрәсә тәмамлап авылга кайта һәм агасы Бәдретдин хәзрәт янында икенче имам булып эшли башлый. Шәрәфетдин мулланың бу улы иҗтимагый актив кеше дә була. Аның Думага сайлауларда катнашуы турында да мәгълүмат бар. Мөхәммәтзәки 1901 елда күршедәге Иске Адәм авылының мәхәлләсенә имам итеп чакырыла. Аның дүрт баласы була. Хәзрәт вафат булганнан соң, алар Пермь һәм Урта Азия якларына китеп урнаша.

### Октябрь революциясеннән соң авыл тормышындагы үзгәрешләр

Минһаҗетдин, Бәдретдин һәм Кәшәфетдин Тәрҗемановларның гаиләләре турында сөйләгәнче, аларның язмышларында текә борылыш китереп чыгарган Гражданнар сугышы вакыйгаларын бәян итеп узу урынлы булыр.

1917 елгы революциядән соң, көчле инфляция башлану сәбәпле, авыл халкы үзе җитештергән товарларны дәүләткә тапшырмый башлый. Безнең авыл халкы да булган икмәкне Казанга илтеп, төрле кирәк-яракка алмаштыра. Биләр волосте идарәсе, бу эшне туктатыр өчен, авыллардагы активистларга икмәкне чыгармаска, дигән күрсәтмә бирә. Бер төркем куштан юлга чыгып, Казанга баручы икмәк олауларын тоткарлый башлый. Бу кешеләргә исә конфискацияләнгән икмәкнең чиреген үз файдаларына калдыру хокукы бирелә. Әлеге куштаннар, шул икмәкне сатып, эчеп,

---

Ахыры. Башы журналның 2019 елгы 3 нче санында.

төннәрен күңел ачарга керешә. 1918 елның февралендә староста Йосыф Әюпов, бер төркем байларны һәм яшьләрне җыеп, әлеге активистларны кыйната. Нәтиҗәдә, куштаннарның берсе һәлак була, уналты кеше тән җәрәхәте ала. Бу вакыйгалар халык хәтеренә «погром» дигән исем белән кереп кала.

«Погром»нан соң икенче көнне халык җыены вәкилләре Йосыф Әюповны эштән алалар. Аның урынына авыл советы рәисе итеп Кәшәфетдин хәзрәт Тәрҗеманов сайлана, ә абыйсы Бәдретдин сәркатип итеп тәгаенләнә. Әмма алар бу вазыйфада озак эшли алмый. Дүрт көннән соң авылга, погром ясаучыларга җәза бирү максаты белән, кызыллар отряды килә. Бу вакытта барча күренекле кешеләр Минһаҗетдин мәзиннең өендә оештырылган мәҗлестә була. Кызыллар авылның бер башыннан пулемёттан ут ачып килә башлагач, мәҗлестәге халык, нәрсә бар шуның белән коралланып, каршылык күрсәтергә җыена. Атыш нәтиҗәсендә ике кеше үтерелә, берничә кеше тән җәрәхәте ала. Кызыллар тагын биш кешене Мөслим авылына алып китеп, шунда атып үтерә.

Бу вакытта Минһаҗетдин мәзин авырып урын өстендә ята торган була. Гаиләсе, кызыллар алып китмәсен өчен, аны базга төшереп качыра. Шуннан соң авыруның чире тагын да көчәеп, аяк-куллары хәрәкәтләнми башлый. Минһаҗетдин, авырудан дәва таба алмыйча, 1921 елның сентябрендә вафат була.

Бәдретдин мулла егерме ел буе мөгаллим-укытучы, мулла вазыйфасын башкара. Ул имамлык иткәндә авыл халкы гөнаһ эшләүдән, хәмер эчүдән ерак булып, урак өстендә, көн буе кырда эшләп тә ураза тота, намаз укый. Заманында Казанның «Госмания» мәдрәсәсен бетергән указлы мулланы һәркем ихтирам итә. Репрессия чорында Бәдретдин мулланың да бар мал-мөлкәтен конфискациялиләр. Истәлекләргә караганда, ул, атарга дип тезеп бастырылган сафтан качып, хатынының туган авылы Баганалыда яшеренә. Берникадәр вакыттан соң гына авылга кайтып, 1922 елның кышында тиф чиреннән вафат була.

Кәшәфетдин мулланың атышлар вакытында кулы яралана. Җәрәхәте төзәлмәү сәбәпле, Кызыл тау авылында аның кулын кисәләр. Әмма ампутациянең файдасы тими, бу хәзрәт тә бакый дөньяга күчә.

## Минһаҗетдин һәм Бәдретдин Тәрҗемановлар нәселе

1922 елда Түбән Майнада муллалар калмагач, имам-хатыйп итеп Такталы авылыннан атаклы Коръән хафиз Зариф хәзрәт Камаловны чакыралар. Мәзин вазыйфасын Минһаҗетдин мәзиннең улы Хәнәфия алып бара. 1930 елда Зариф мулла кулга алына. Хәнәфия Тәрҗеманов та, кулаклар категориясенә кертелеп, кулга алу куркынычы килеп тугач, әнисе Мәгъзурә, хатыны Фатыйма һәм сеңелесе Сатига белән Себер якларына качып китә. Алар Чита һәм Ангара шәһәрләрендә төрле хезмәт башкара. Хәнәфия мәзиннең балалары булмый, үзе юл фаҗигасендә һәлак була.

Минһаҗетдиннең кызларына да дөньяның төрле тарафларына таралырга туры килә. Олы кызы Зәкия Чистай баенда кибетче булып эшләүче Габдулла Хәкимовка кияүгә чыга. Гражданнар сугышы башлангач, бай киңәшен истә тотып, Габдулла белән Зәкия Себергә китә һәм Иркутск шәһәрендә яши. Себерне кызыллар алгач, Японияга качып, аннан Төркиягә күченәләр. Төркиядә яшәгәндә Зәкия әбинең ире үлә. Ул өч баласы белән Америкага күчеп китә һәм шунда кала. 1985 елда 94 яшендә вафат була. Аның кызы Рәисә Хәким Икенче Бөтендөнья татар конгрессы җыенында АКШ татарлары вәкиле буларак катнашкан иде.

Минһаҗетдин бабайның Галимә исемле кызы Чирүле Шонталы авылының Әхмәтшакир Әхмәровка кияүгә чыга. Бохара әмирендә сәркатип хезмәтен башкар-

ган әлеге укымышлы зат шактый гына мал-мөлкәт тупларга да өлгергән була. Галимә әбинең дүрт баласы, алардан туган онык-тураннар Бохара якларында яши.

Камәрия исемле туганнары Түбән Майнаның күренекле бае Фәхретдинов Бәдретдиннең улы Хәбетдингә кияүгә чыга. Колхозлашу чоры башлангач, аларның гаиләсен Себергә сөрәләр. Сугыштан соң Камәрия әби улы Исмәгыйль белән Бохарага китә һәм шунда вафат була. Исмәгыйль гаиләсе белән Үзбәкстандагы Җизак шәһәрендә яши. Икенче улы Ибраһим Чаллыда яшәп, шунда үлә.

Минһаҗетдин мәзиннең Сатига исемле кызы Чаллы районының Биклән авылы кешесе Әхмәтвәлиев Барига кияүгә чыга. Зәйнәп исә үз авылларындагы Мостафин Гарифуллага хатын булып, Себердәге Зея шәһәренә китә һәм шунда яшиләр. Балалары яшли үлгәнлектән, нәселе калмый.

Бәдретдин мулла Тәрҗеманов белән Ләмига абыстайның тугыз баласы була. Әтиләре 1930 нчы елларда үлгәнгә күрә, аларның берсе дә кулакларны сөрү һәм репрессияләү чорында зыян күрми. Ризаэтдин һәм Гыйсметдин исемле уллары Бөек Ватан сугышында хәбәрсез югала, ә Хисмәтулла 1943 елның 17 декабрендә Псков өлкәсенең Копачёв авылы янындагы сугышларда алган яралардан һәлак була. Авылда гомер иткән кызлары Заһидә һәм Мәтлүфәнең дә ирләре сугыштан әйләнеп кайтмый.

Бәдретдин мулланың кызы Мәтлүфә Нәсибулла бабайның улы Габдуллага кияүгә чыккан була. Аларның Рәхимә исемле кызлары туа. Рәхимә апаның Түбән Майна кешесе Әдип абый белән никахыннан биш кыз бала дөньяга килә: Рәшидә, Мөршидә, Рокыя, Рузалия, Рушания.

## Заһидә абыстай нәселе

1908 елның сентябрь иртәсе. Ләмига абыстайның тулгагы башлана. Кендек әбисе килеп, бисмилласын әйтеп башлаган эш озак бармый – дөньяга йөзлек кигән кыз туа. Йөзлеген ачкач, зур зәңгәр күзләре белән якты дөньяны күрә ул. Өч малайдан соң туган бу кызга Бәдретдин мулла да бик сөенә. Җиде яшь тулганда ул әнисе белән янәшә басып намаз укый, ураза тота. Әтиләре балаларына гарәп, латин алфавиты өйрәтә. «Кызым, мөгаллимә булырсың, балаларга сабак укытырсың», – ди.

18 яшендә әтисе аны 25 ел солдат хезмәтен үтәп, халыкта «солдат Нәҗметдин» дип аталган кешенең оныгы Хәсән Хөснетдин улына кияүгә бирә. Зур бабам һәм зур әбиемнең бер-бер артлы өч кызы дөньяга килә: Рәхбәр, Фатыйма, Хасимә. Дүртенче булып туган малайга Мидхәт исемен бирәләр. Ике кызы дөньядан яшьли китә, Мидхәт белән Хасимә генә кала. Ире Хәсән сугышка алынып, 1943 елның 10 февралендә Ленинград өлкәсенең Тосно районындагы Кородыня авылы янында һәлак була.

Кызы Хасимә Пермь өлкәсенә урман кисәргә китә, шунда Фәнәви исемле башкорт егете белән тормыш корып, Гаяз, Фаяз, Мәснәви, Фатыйма, Фәридә исемле биш бала дөньяга китерә. Шуларның өчесе үсеп, үз гаиләләрен кора.

Мидхәт күршедәге җырга-моңга бай, биюче кыз Тәнзиләгә өйләнә. Аларның бер-бер артлы Тәзкирә, Раилә, Энҗе, Алсу исемле дүрт кызы туа.

Олы кыз Тәзкирә Казан дәүләт финанс-икътисад институтын тәмамлап, «Татнефтехиминвестхолдинг» компаниясендә эшли. Ире Әсхат улы Албир белән Казанда яши. Раилә Казандагы төзүчеләр техникумын тәмамлый. Күлбай-Мораса егете Шәүкәткә кияүгә чыгып, уллары Илдар һәм Айдар белән Чаллы шәһәрендә гомер итә. Өченче кыз авылдашы Фәнис Хөснуллинга кияүгә чыгып, кыз һәм ир бала үстерә, гаилә җылысын балалар йортыннан алган малайлар белән дә бүлешәләр. Хәзерге вакытта Энҗе Мидхәт кызы Хөснуллина Түбән Татар Майнасы, Иске Татар Адәмсуы, Яңа Татар Адәмсуы, Такталы авылларының җирле үзидарә башлыгы булып тора.

Заһидә әби (уңда), оныгы Алсу, кызы Хасимә белән

Заһидә әби 81 яшенә кадәр янындагы оныкларына догалар, әдәп-әхлак өйрәтә, уразасын, биш вакыт намазын калдырмый. Ак әби булып, улы, килене, оныгы Алсу кулында якты дөньядан китә.

***

АКШтан Бөтендөнья татар конгрессы съездына делегат булып килгән Рәисә Хәким: «Нәселем кешеләрен барысын бергә җыеп булса, тулы бер конгресс җыены килеп чыгар иде», – дип әйтте.

Нәселдә безгә билгеле булган мулла, мөгаллим, азанчылар һәм башка укымышлылар турындагы мәгълүматны Мәскәү, Казан архивларыннан алынган чыганаклар, әүвәлгеләрнең сөйләп калдырган истәлекләре, Түбән Майнаның мулласы һәм мәктәп директоры, тарих фәннәре кандидаты Рафик Гомәр улы Насыйров ярдәмендә тупладык.

Әлеге хезмәтемдә нәселемне кыскача гына тәкъдим иттем. Тәрҗеман-әл-Әнҗерәи – халкыбызга бик күп иманлы, зыялы, милләтнең йөзен күрсәтерлек шәхесләр биргән нәсел. Анда татар халкының соңгы 200 еллык тарихы чагыла. Хәзерге вакытта Тәрҗеманилар дөньяның төрле тарафларында – Япония, Төркия, Кытай, Франция, АКШ, Россия, Урта Азия илләрендә гомер сөрә.

***Редакциядән:*** *Заһидә әбинең хыялын, дөресрәге, Бәдретдин мулланың теләген әлеге мәкаләнең авторы Алсу Нәҗми гамәлгә ашыра. Иске Татар Адәмсуы мәктәбен бик яхшы билгеләргә генә бетергән кыз, КДПУның тарих-филология факультетын тәмамлап (1995 елдан), Алексеевскида татар теле һәм әдәбияты укыта. Шигъри һәм чәчмә әсәрләрдән торган «Күңел гөлләре», «Йөзем тәлгәше», «Кояш җилләре», «Йолдызлар балкышы», «Мерцание звезд» исемле китапларын бастырып чыгара. Татар яшьләрен җыеп, «Сөембикә театры» оештыра. Казанда Сөембикә һәйкәлен торгызу эшләре белән дә янып йөри. «Ак калфак» Бөтендөнья татар хатын-кызлары иҗтимагый оешмасының Алексеевск районы буенча җитәкчесе вазыйфасын башкара.*

*Алсуның кызы Зөһрә Алексеевскиның беренче мәктәбен алтын медальгә, КНИТУның нефть һәм нефтехимия факультетын кызыл дипломга тәмамлап, КФУның геология факультеты аспирантурасына укырга керә, фәнни эш белән шөгыльләнә.* ■

ТАССР

*ТАССРда Җир эшләре халык комиссары булып Юныс Нуриман улы Вәлидов (1889-1925) эшләгән чорда, ә төгәлрәге 1923 елдан, татарларны эре елга буйларына, беренче чиратта, Идел ярларына һәм Казан янына күчереп утырту сәясәте башлана. Шул чорның матбугатында моны Явыз Иван сәяси золымыннан соң тарихи гаделлекне торгызу, милли республика биргән зур мөмкинлек, дип кабул итәләр. Шулай итеп, Арча кантонындагы җир кытлыгыннан тилмергән татар крестьяннары Идел буена күчеп китеп, хәзерге Югары Ослан районындагы Кызыл Байрак, Бакчасарай, Нариман авылларына, Казан янындагы Чыңгыз бистәсенә нигез сала. Соңрак, олуг каһан исеменнән куркып булса кирәк, әлеге бистәне «Нагорный» дип үзгәртсәләр дә, халык телендә «Чыңгызтау» атамасы хәзерге көнгә кадәр сакланып кала. Шундый дистәләгән авыллар барлыкка килү белән бергә, төрле сәбәпләр аркасында эре һәм вак шәһәрләргә күчеп килүче татарларның да саны арта. 1552 елгы һәлакәттән соң тәүге мәртәбә, ислам динен кабул итүнең 1000 еллыгы уңаеннан, Кабан күленең руслар гына яши торган ягында «Кабан арты» мәчете салына. Алда тәкъдим ителә торган мәкаләдә дә ТАССРның беренче елларындагы җир сәясәте чагылыш таба.*

***Редакция***

# ЯҢА БОЛГАР ПҮЧИНКӘСЕ

З.Әхмәд

1923 елда Татарстан Җир эшләре халык комиссариатының күчерү бүлегеннән чыккан инструкторларның яңа җирләргә хөкүмәт тарафыннан бирелә торган ярдәмнәр, яңа җирләргә күчүнең файдалы якларын кантоннарда халыкка аңлатып йөргәннән соң, аз җирле, мәдәни яктан артта, үзәк, су, тимер юлларыннан эчтә калган татарлар арасында күчү эшләре турысында кызу-кызу сүзләр сөйләнә, киңәшләр ителә башлады. Сүзнең, киңәшнең иң куерган җире бигрәк тә бөтен Татарстанда аз җирле булган Арча кантонында һәм Тәтеш кантонында яшәгән татар крәстиәннәре арасында булды. Чөнки бу кантоннарның кайсыбер волостьларында җирнең иң күп булганы җан башына 1 дисәтинә, иң киме 0,5 дисәтинә төшә. Бу районнарда җирнең азлыгы, тормышның кысанлыгы крәстиәннәрне Татарстанда булган буш җирләргә генә түгел, киләчәктә ерак Себер далаларына күчеп китәргә дә мәҗбүр итәчәге көн кебек ачык күренә иде.

Хәзерге көндә Татарстанда 120гә якын яңа төзелгән пүчинкәләр арасында беренче мәртәбә төзелгәне Яңа Болгар пүчинкәсе. Бу пүчинкәнең күбрәк әгъзалары Арча кантоны авылларыннан җыелган крәстиәннәр. Калганнары Тәтеш һәм башка кантоннардан да бар. Боларның башында Зиннәт абзый Заһидуллин тора.

Пүчинкәгә Зөя кантоннарындагы буш җирдән Волгага һәм Казанга якын, тирәягы урман булган Сәет авылы белән Матюшин авыллары арасындагы әүвәлге алпавыт Маркис Паулович җире кисеп бирелде. Алар 1924 елның язында шунда күченеп килделәр.

Ул чакта әле бу җир япан кыр булып, килүчеләргә яңгырдан башны яшерергә

Яңа Болгар пүчинкәсенең иң беренче фотосы. «Игенче» журналының 1926 елгы гыйнвар санында басылган

урын булмаганга, өмә белән барысы өчен бер лапас эшләп, шул түгәрәк лапаста яңа тормыш башлыйлар.

Менә шушы лапаста Яңа Болгар пүчинкәсе гражданнарының 1924-1925 елгы эш планы төзелә. Планнарында: җир кистерү, паҗмаларны *(утар, йорт урыны. – Ред.)* план белән бүлү, атсызларга ат алу, чәчүгә орлык алу, каралтылар өчен агач алу, мелиорация эшләре, нәселле хайваннар үрчетү һәм башка эшләр тора.

Яңа Болгар гражданнары, шул килгән көннән башлап, бертуктамый, армыйталмый лапас, землянкаларда яшәүне авырлык, хурлык санамый яшәп, җирләрен кистерделәр. Җирләре барлыгы 412,48 дисәтинә булып, бу җиргә 187 җаннан төзелгән 30 йорт сыя.

Килгән вакытта бөтен пүчинкәдә 9 гына баш атлары булса, хөкүмәттән алган 9 һәм үзләре сатып алган атлар белән хәзер 24 башка җиткерделәр.

Һәр йорт башына 150шәр төп эшкә ярарлык агач, 50шәр төп киртәлек алып, барысы да диярлек төрле каралты кора башладылар.

Мелиорация эшләре эшләтелгән. Аның өчен көтәчәккә акча алынган. Хөкүмәт ике кое, бер күл казытып биргән. Үз суммаларыннан ике кое казытканнар. Һәр кешенең бакчасына су кертү җиңел булсын өчен, каралты артларыннан су агарга улаклар ясалган.

Чәчү орлыкларының яхшы нәселлеләре: швед солысы, альп арышлары белән тәэмин ителгәннәр. Тирә-күрше авылларда простой арыш йөзенә 4-5 пот бирсә, Яңа Болгар гражданнары йөзенә 10-11 пот арыш алалар. Солы да шулай ук. Иске авылларыннан бернәрсә алып килмәгән ярлы крәстиәннәр күп кенә авыл хуҗалыгы коралларына хуҗа булганнар. Суктыру, ургыч, өч чәчү машинасы, суыргыч, егермеләп сабан һәм башка кораллары күп. Өч яхшы нәселле атлары бар. Башка хайваннарны да шулай яхшырталар. Барын бергә җыеп әйткәндә, түгәрәк лапас эчендә корылган планнарын Яңа Болгар пүчинкәсе гражданнары 100 проценты белән эшкә ашырганнар.

| .1926 يىل | 15 مای | № 9-10 |
|---|---|---|

بو نومیرده:

«Игенче» журналында татар крестьяннарын Идел буена күчәргә өндәгән мәкаләләр басылган

**1925-1926 ЕЛДАГЫ ЭШ ПЛАНЫ**

Яңа Болгар гражданнарының киләчәк елдагы эш планнарында шулар бар:

1. Киләсе яздан калмый, биш басуга күчәргә. Төрле кантоннардан, төрле авыллардан булып, барысы да берьюлы килеп бетмәгәнлекләреннән, алар беренче елда ук күп басуга күчә алмаганнар.

2. Киләсе яздан калмый, һәрбер йортка 100әр төптән өч мең төп алма агачы, урамга дүле агачы (груша. – ***Ред.***) утыртырга, диелә.

3. Алма агачларына коелардан арык-улаклар аркылы су кертүне җиңел юлга куяр өчен, коеларга тегермән куярга, ул тегермән җил булганда җил белән, җил булмаганда кул белән әйләндереп чыгарга җиңеллек китерә торган формада эшләнергә тиешле, диелгән.

4. Авыл башында зур күл казу өчен яраклы урын булу сәбәпле, ул чокырны казып, тирә-яктан җыелган суларны җыеп, анда балык үрчетү чарасын күрергә, диелгән.

Берничә баш умарта алып, умартачылык ширкәте төзү чарасына керешелгән. Планда болардан башка да күп кенә авыл хуҗалыгын күтәрергә файдалы булган эшләр дә бар. Киләчәктә трактор алу, уку йортлары салу, тагын да башка зур суммалар сорый торган эшләрне эш тәртибенә керткәннәр.

***

Соңгы елларда крәстиән хуҗалыгын алга җибәрүдә үрнәк булырлык авыллар – пүчинкәләр күренгәли башлады.

Шуның өчен дә крәстиәннәрнең: «Күчү – авыр эш ул, борынгы бабалар аны «күчү – очу» дип әйткәннәр», – дип әйтүләренә каршы, киләчәкне уйлап: «Күчкән – көн күргән, күчмәгән – ни күргән?!» – дип кайтарырга туры килә. Һәм, Яңа Болгар пүчинкәсе гражданнары эшләреннән үрнәк алып, яңа җирләргә, һич булмаганда, үз башларына күчеп, вак-вак пүчинкәләр төзергә ашыгырга киңәш бирергә туры килә.

*Игенче. – 1926. – №2. – 15 гыйнвар.*

*Текстны басмага* ***Ленар Гобәйдуллин*** *әзерләде.* ■

# Тукаев кәнфитләре

Ләлә Мортазина




Габдулла Тукай 1908 елда «Яшен» журналында басылып чыккан «Мин шулар илә милләтче» дигән әсәрендә, җиңелчә көлеп: *«Шакир Хәмитев шырпысы илә генә тәмәке тартам, «Исмәгыйль Гаспринский сабыны» илә битемне юам. Шул кешенең үк кәнфите илә чәй эчәм»*, – дип яза. Шагыйрь вафат булганнан соң, аның рәсеме дә сабын кабында урын ала. Казан шәһәрендә кәгазенә Тукай сурәте төшерелгән конфет җитештерелә башлый, төрле открыткалар дөнья күрә, күпләп китаплары бастырыла. 1913 ел дәвамында гына да Г.Тукайның биш китабы укучыларга килеп ирешә. Болар, беренчедән, реклама, коммерция, табыш алуны күздә тотса, икенчедән, әлбәттә, сөекле шагыйребезнең исемен саклау, күз уңында тоту, популярлаштыру һәм аның образын мәгърифәтчелек идеяләрен җәелдерүдә файдалану максатыннан да эшләнгән. Бу исә милли тәрәккыят фикерләрен таратуда көтелмәгән, хәзерге заманча әйтсәк, креатив алымнарның берсе була.

Казан шәһәрендәге Г.Тукай музеенда **«Альфа» фабрикасы**нда чыгарылган, шагыйрь рәсеме төшерелгән конфет этикеткасы саклана. «Вакыт» газетасының 1914 елгы 21 июнь санында: «Казанда «Альфа» фабрикасы, мәрхүм шагыйрь Габдулла Тукаевның рәсемен куеп, Тукаев кәнфитләре ясап чыгара», – дигән хәбәр басылып чыга. Бу конфетларны җитештерүче «Шамил йорты» (хәзерге Тукай музее бинасы) белән турыдан-туры бәйле. Йортның хуҗасы Мәрьямбану Ибраһим кызы Апакова, ире Мөхәммәдшәфи Шамил 1906 елда вафат булганнан соң, балалары белән Петербургка китә. Ә аның йортын татарның атаклы конфет короле, беренче гильдия сәүдәгәр **Вәлиулла Ибраһимов** сатып ала. Кайбер мәгълүматлар буенча, ул хәтта әлеге бинаның аскы өлешендә кондитер кибете дә ачып җибәрә. Анда, әлбәттә, «Тукаев кәнфитләре» дә сатылгандыр.■

# Тау Иленең ташъязма истәлекләре

Ирек Һадиев, Раиф Мәрданов

*Республикабызның Питрәч районы Тау Иле авылы борынгы тарихи истәлекләргә бай. Бу очракта без авыл зиратындагы һәм аерым каберлекләрдәге гарәп язулы кабер ташларын күздә тотабыз.*

*Авыл зиратының көнчыгыш тарафында сакланган, Казан ханлыгы чорына караган ташъязма ядкәрләрнең икесе турында Шиһабетдин Мәрҗани язып калдырган[1]. Бишесенең мәгълүматлары күренекле галим, ташъязмалар белгече Һарун Йосыпов хезмәтләрендә урын алган[2]. Татарстанның археологик истәлекләренә багышланган белешмәлектә, шушы зираттагы дүрт таш һәм таш кисәкләре кыскача тасвирлану белән беррәттән, авыл эчендәге И.Вәлиев ихатасында торучы тагын бер ташъязма барлыгы күрсәтелгән[3]. Зиратның төньяк тарафында, юл буенда урнашкан аерым каберлектәге XVII гасыр ахыры ташъязмасы текстын һәм фотосын галим Марсель Әхмәтҗанов бастырды[4].*

Без, Тау Иле авылы эпиграфик истәлекләренең хәзерге халәтен тулырак күзаллау һәм кайбер мәсьәләләргә ачыклык кертү максаты белән, 2018 елның 29 апрель һәм 11 октябрь көннәрендә аларны җентекләп тагын бер өйрәндек. Зираттагы 10 ташъязманың (даталанган иң борынгысы – 1488 елгы, ә соңгысы – 1550 елгы), элекке Исламморат Вәлиев, хәзерге Гайнетдиновлар-Абдуллиннар ихатасындагы 1603-1608 елларга нисбәтле кабер ташының һәм зират каршындагы аерым каберлекнең 1684 елгы ташының текстларын укып теркәдек, фоторәсемгә төшердек һәм үлчәмнәрен алдык. Югарыда исемнәре аталган галимнәр тарафыннан элек укылган текстларның күбесенә безнең тарафтан әһәмиятле төзәтмәләр һәм өстәмәләр кертелде. Түбәндә 3, 4, 7, 8, 10, 11 номерлары белән бирелгән ташъязма текстларының моңарчы матбугатта чыкканы юк иде.

Сәнгать тарихы өчен әһәмиятле чыганак буларак ташъязма истәлекләрнең эшләнеш-бизәлешләренә аерым тукталыйк. XV гасыр ахыры ташлары (№№1-4) уйма һәм чагыштырмача гади язулы булулары, охшаш геометрик орнаментлары белән үзенчәлекле. Гомуми карашка әллә ни катлаулы булмаган бизәк, батырып вак өчпочмаклар һәм дүртпочмаклар төшерү нәтиҗәсендә, күпертмә һәм бер-берсенә тоташ ромблардан торган каймалар хасил иткән. Тик шунысы да бар, алар һәрберсендә дә бер үк төрле түгел. 1497 елгы таш (№3) өслегенең язулы юллары да шундый ук бизәк белән аерылган. Әйтелгән ысул 1518 елгы кабер ташының да (№6) кайма бизәген төшерүдә кулланылган, әмма ул бүтәнчәрәк. Гомумән, 500 еллык тарихка ия, хәзергәчә бик яхшы сакланган бу ядкәрнең күпертмә тексты да, өске юлларының аеруча нәфасәт белән язылышы да – милли сәнгатебезнең матур бер үрнәге.

[1] Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. – Казан: Татар. китап нәшр., 1989. – Б.77.
[2] Юсупов Г.В. Татарские эпиграфические памятники XV в.: к вопросу о происхождении казанских татар // Эпиграфика Востока: сб. статей. Вып. V. – Москва-Ленинград: изд-во АН СССР, 1951. – С.83-84, 89-90; Юсупов Г.В. Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. – М.–Л.: изд-во АН СССР, 1960. – Приложение: табл. 53, табл. 56, табл. 59, табл. 66.
[3] Казаков Е.П., Старостин П.Н., Халиков А.Х. Археологические памятники Татарской АССР. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1987. – С.186.
[4] Әхмәтҗанов М.И. XVII-XVIII гасыр татар ташбилгеләре. – Казан, 2011. – Б.63, 191.

XVI гасырның беренче яртысы ташъязма истәлекләрендә очрый торган, аларның арткы тарафына төшерелгән штамп-бизәк Тау Иле кабер ташларында да (№№7, 8) бар. Берсендә ул начар сыйфатта, әмма тулырак сакланган булса, икенчесенең ватык кисәкләреннән дә гаҗәеп төгәллек белән уелган бизәк элементларын күрергә мөмкин. 1550 елгы затлы таш (№9) исә Казан ханлыгы чоры эпитафияләре өчен хас булган аеруча камил язылыш һәм бизәлеш үзенчәлекләрен кабатлый. Унынчы номер белән бирелгән ташъязма XVI гасыр ахыры һәм XVII гасыр башына караган башка ташлар белән нигездә охшаш.

## ТАУ ИЛЕ АВЫЛЫ ЗИРАТЫНЫҢ КӨНЧЫГЫШ (БОРЫНГЫ) ӨЛЕШЕ

№1*. ***Исхак шәех Мәхмүд ага улына куелган таш**. 1488 ел***

Алгы ягында *(1-2 юллар күпертмә язулы; 3-13 юллар уйма язулы)*:

1) ... лә йәмүт

2)... [әд-дөнья сагатүн фә-әҗгальһа тагатән]

3) [каләән-нәби галәйһис]сәлам вәлмөәминунә

4) лә йәмүтүнә вә ләкиннә йәнкыйлүнә

5) мин дарел-фәна илә дарел-бәка

6) тарих сикез йөз туксан

7) өчдә мөбарәк рабигыль-ахир

8) аеның унсикезенче көн***

9) ирдекем Мәхмүд ага у-

10) -гылы шәех Исхак дару фәнадин да-

11) -ру бәкага рихләт кыйлды****

12) ... сиксән яшендә [Аллаһ]

13) Тәгалә [рәхмәт] кыйлсун

Үлчәмнәре: 120 х 59 х 15 см.

* Бу ташның сынганнан калган төбе аерым, өске өлеше дә берничәгә ватылып җирдә ята.

** Бу ташның тексты һәм график рәсеме басылган: Юсупов Г.В. Татарские эпиграфические памятники XV в.: к вопросу о происхождении казанских татар // Эпиграфика Востока: сб. статей. Вып. V. – Москва-Ленинград: изд-во АН СССР, 1951. – С.83. Тексттагы 1-3 һәм 12-13 юлларның укылышы анда юк.

*** Һиҗри 893 елның 18 рабигыль-ахир көне милади 1488 елның 1 апреленә туры килә. Һ.Йосыповта бу дата 1487 елның 2 апреле дип ялгыш бирелгән.

**** Таш текстында бу сүз алдындагы «къ-л-д» хәрефләре, безнең фикеребезчә, уючы тарафыннан ялгыш язылып, шунда ук дөресләп кабатланган. Һарун Йосыпов бу ике сүзне «кыйлып котылды» (переселившись, избавился) рәвешендә укыган. Мөселман кешесенең мәңгелек дөньяга күчүен «котылу» дип атау шәригать өйрәтмәләренә һич тә туры килми.

№2*. ***Тәвәккәл Сәедәхмәд мулла улына куелган таш**. 1492 ел***

Алгы ягында *(уйма язулы)*:

1) Көллү хә[йийүн сә-й]әмүт вә Һуа әл-Хәййү [лә йәмүт]

2) көллү нәфсин заикател-мәүт ...

3) калә ән-нәби галәйһиссәлам ...

4) калә ән-нәби галәйһиссәлам әлмөәминунә лә йәмүтүнә вә ләк[иннә]

5) йәнкыйлүнә мин дарел-фәна илә дарел-бәка тарих

6) сикез йөз туксан йитедә шәгъбан аеның

7) унбишенче көн*** ирдекем Тәвәккәл

8) [бине] мулла Сәедәхмәд йикерме өч яшендә

* Таш, ике кисәккә ватылып, җирдә ята.

** Бу ташның өлешчә тексты басылган: Мәрҗани Ш. Әл-кыйсьмел-әүвәл мин китаби Мөстәфаделәхбар фи әхвали Казан вә Болгар. – Казан: Домбровский матб., 1897. – Б.27; Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – Б.77. Шулай ук тулы булмаган тексты һәм сынык өске өлеше кермәгән фотосы, график рәсеме басылган: Юсупов Г.В. Татарские эпиграфические памятники XV в.: к вопросу о происхождении казанских татар // Эпиграфика Востока: сб. статей. Вып. V. – Москва-Ленинград: изд-во АН СССР, 1951. – С.83-84; Юсупов Г.В. Введение в булгаро-та-

9) ... а төшеп дару фәнадин дару

10) [бәкага рих]ләт кыйлды Хакъ Тәгалә рәхмәт кыйлсун

11) ...

Үлчәмнәре: 108 х 66 х 14 см.

тарскую эпиграфику. – М.–Л.: изд-во АН СССР, 1960. – Приложение: табл. 53. Тексттагы 1-3 юлларның укылышы Һ.Йосыпов хезмәтләрендә юк.

*** Һиҗри 897 елның 15 шәгъбан көне милади 1492 елның 12 июненә туры килә. Һ.Йосыповта бу дата 1491 елның 12 июне дип ялгыш бирелгән.

№3*. ***Сәедәхмәд Исхак шәех улына куелган таш**. 1497 ел***

Алгы ягында *(уйма язулы)*:

1) ... фә-әҗгальһа ... калә ән-нәби галәйһиссәлам

2) әл-мөәминунә лә йәмүтүнә вә ләкиннә йәнкыйлүнә мин дарел-фәна илә

3) дарел-бәка калә ән-нәби галәйһиссәлам ...

4) ... тарих тукуз йөз икедә җөмади-

5) -ел-ахир аеның*** ахырында ирдекем шәех Исхак угылы

6) Сәедәхмәд утуз ике (алты-?) яшендә дару фәнадин дару бәкага

7) рихләт кыйлды Хакъ Тәгалә рәхмәт кыйлсун амәнна билләһи Тәгалә

8) әрә әд-дөнья хәрабән [би-игътибари] фә-лә йәбка мәдамән бил-карари

9) [күрәрмән дөньяны вәйран бары һәмишә] бакый ирмәс юк [карары]

Үлчәмнәре: 93 х 63 х 16 см.

* Кабер ташы өч өлешкә сынган, өске өлеше табылмады. Янәшәдә шул чор кабер ташының зур аскуймасы ята, ләкин аны биредәге аерым бер ташка нисбәт итү мөмкин түгел.

** Ташъязманың тексты беренче тапкыр басыла. Ул аерым кисәкләрдән укылды.

*** Һиҗри 902 елның җөмадиел-ахир ае ахыры милади 1497 елның февраль ае ахырына туры килә.

№4. ***Кемгә куелганы билгесез таш*. XV гасырның ахыры***

Алгы ягында *(уйма язулы)*:

1) ...

2) ... фә-йа ли-шәваһиде Раббил-галәмин

3) әрә әд-дөнья хәрабән би-игътибари фә-лә йәбка мәдамән бил-карари

4) күрәрмән дөньяны вәйран бары һәмишә бакый ирмәс юк карары

Үлчәмнәре: 40 х 50 х 18 см.

* Кабер ташының өске өлеше юк.

№5*. ***Кемгә куелганы билгесез таш**. XVI гасыр башы***

Алгы ягында *(күпертмә язулы)*:

1) Һу әл-Хәййү

* Таш зиратта табылмады, аның кайда икәнлеге безгә билгесез.

2) әл-ләзи лә йәмүт вә көллү хәййүн сә-йәмүт

3) калә Аллаһу Сөбханәһә вә Тәгалә вә ма тәдри

4) ...

** Ташның тексты Һ.Йосыпов хезмәтләреннән (Юсупов Г.В. Татарские эпиграфические памятники XV в.: к вопросу о происхождении казанских татар // Эпиграфика Востока: сб. статей. Вып. V. – Москва-Ленинград: изд-во АН СССР, 1951. – С.89-90; Юсупов Г.В. Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. – М.–Л.: изд-во АН СССР, 1960. – Приложение: табл. 56) алынды, аларда ташъязма истәлекнең тексты һәм фотосы басылган.

№6. ***Сәйдак Хәсән хаҗи улына куелган таш*. 1518 ел***

Алгы ягында *(күпертмә язулы)*:

1) Һу әл-Хәййү

2) әл-ләзи лә йәмүт вә көллү хәййүн сә-йәмүт

3) калә Аллаһу Сөбханәһә вә Тәгалә көллү нәфсин заикател-мәүт сүммә иләйна түрҗәгунә

4) калә Аллаһу Тәгалә вә ма тәдри нәфсүн би-әйи арди тәмүтү иннә Аллаһә Галимүн Хәбирүн

5) калә ән-нәби галәйһиссәлам әл-мөәминунә лә йәмүтүнә вә ләкиннә

6) йәнкыйлүнә мин дарел-фәна иләдарел-бәка калә ән-нәби галәйһиссәлам әд-дөнья сагатүн

7) фә-әҗгальһа тагатән тарих тукуз йөз йекерме түртдә

8) җөмадиел-ахир аеның әүвәлендә** ирдекем хаҗи Хәсән угылы Сәйдак

9) алтмыш түрт яшендә дару фәнадин дару бәкага рихләт кыйлды

Үлчәмнәре: 107 х 64 х 25 см.

* Бу ташның өлешчә тексты басылган: Мәрҗани Ш. Әл-кыйсьмел-әүвәл мин китаби Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. – Казан: Домбровский матб., 1897. – Б.27; Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – Б.77. Шулай ук тексты һәм фотосы басылган: Юсупов Г.В. Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. – М.–Л.: изд-во АН СССР, 1960. – Приложение: табл.59. Һарун Йосыпов тарафыннан 8 нче юл ахырындагы Сәйдак исеме Шәйдулла дип ялгыш укылган, 9 нчы юл башындагы «алтмыш түрт» сүзләре танылмый калган.

** Һиҗри 924 елның 1 җөмадиел-ахир көне милади 1518 елның 10 июненә туры килә.

№7*. ***Кемгә куелганы билгесез таш**. XVI гасырның беренче яртысы***

Алгы ягында *(күпертмә язулы)*:

1-3) ...

4) калә ән-нәби галәйһиссәлам

5-6) ...

Арткы ягында*** *(күпертмә язулы)*:

1) ... ли

2) ...лугъның хәләле бина кыйлды

Үлчәмнәре: 137 х 45 х 16 см.

* Кабер ташы өчкә сынган.

** Ташның уң һәм сул якларында аеруча нәфис бизәкләр белән чорналган күпертмә язулар бар, ләкин танырлык түгел.

*** Язулар бизәкле штамп эчендә.

№8*. ***Кемгә куелганы билгесез таш**. XVI гасырның беренче яртысы***

Сул ягында *(күпертмә язулы)*:

1) әрә әд-дөнья хәрабән би-игътибари фә-лә [йәбка] ...

* Кабер ташы җиде кисәккә ватылган.
** Ташның арткы ягында аеруча нәфис штамп-бизәк фрагменты сакланган.

№ 9. ***Тәвәккәл хатыны Гәүһәр бикәгә куелган таш*. 1550 ел***

Алгы ягында *(күпертмә язулы)*:

1) каләә Аллаһу Тәбарәкә вә Тәгалә
2) көллү мән галәйһа фанин вә йәбка вәҗһи
3) Раббикә Зөл-җәлали вәл-икрам
4) калә ән-нәби галәйһиссәлам
5) тарих тукуз йөз иллик
6) йитедә Тәвәккәл гыялы Гәүһәр бикә рабигыль-ахир
7) аенда** вафат булды Хакъ Тәгалә рәхмәт кыйлсын нәүвара
8) Аллаһу кабриһи

Арткы ягында *(күпертмә язулы)*:

1) бу ләүхне ... угылы
2) Ишбула[т бик]
3) бина кыйлды

* Бу ташның алгы ягындагы тексты һәм фотосы басылган: Юсупов Г. В. Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. – М.–Л.: изд-во АН СССР, 1960. – Приложение: табл.66.
** Һиҗри 957 елның рабигыль-ахир ае милади 1550 елның май аена туры килә.

Уң ягында *(күпертмә язулы)*:

1) [калә ән-нәби галәйһиссәлам] әд-дөнья сагатүн фә-әҗгальһа тагатән

Сул ягында *(күпертмә язулы)*:

1) [калә ән-нәби] галәйһиссәлам әд-дөнья мәзрагатүл-ахирәти

Үлчәмнәре: 133 x 51 x 13 см.

№10. ***Кемгә куелганы билгесез таш*. XVI гасыр***

Уң ягында *(күпертмә язулы)*:

1) күрәрмән дөньяны вәйран бары һәмишә бакый ирмәс юк карары

Сул ягында *(күпертмә язулы)*:

1) әрә әд-дөнья хәрабән би-игътибари фә-лә йәбка мәдамән бил-карари

Үлчәмнәре: 110 x 48 x 21 см.

* Алгы ягының аскы өлешендәге күпертмә язулы өч юлда хәрефләр шәйләнә, әмма танырлык түгел.

### ТАУ ИЛЕ АВЫЛЫНЫҢ ГАЙНЕТДИНОВЛАР-АБДУЛЛИННАР ИХАТАСЫНДАГЫ ТАШЪЯЗМА ИСТӘЛЕК

№11*. ***Исеме билгесез ир-атка куелган таш**. 1603-1608 еллар***

Алгы ягында *(күпертмә язулы)*:
1) калә Аллаһу Тәгалә вә ма тәдри
2) нәфсүн би-әйи арди тәмүтү вә калә Сөбханәһә
3) вә Тәгалә көллү нәфсин заикател-мәүт
4) калә ән-нәби галәйһиссәлам әд-дөнья мәзрагатүл-ахирәти
5) тарих мең ел узуб ун...***
6) ...

Арткы ягында *(күпертмә язулы)*:
1) бу ләүхне хәләле Бикҗан
2) бикә бина кыйлды

Уң ягында *(күпертмә язулы)*:
1) ... мәдамән бил-карари

Сул ягында *(күпертмә язулы)*:
1) күрәрмән дөньяны вәйран бары ...

Үлчәмнәре: 119 x 47 x 18 см.

* Ташъязма истәлек тимер чардуган белән коймаланган. Тексты беренче тапкыр басыла.
** Бу таш турында мәгълүмат басылган: Казаков Е.П., Старостин П.Н., Халиков А.Х. Археологические памятники Татарской АССР. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1987. – С.186.
*** Биредә шушы юлның соңгы хәрефе буларак «әлиф» язылган. Моннан чыгып фикер йөрткәндә, 6 юлда дәвам ителә торган, әмма хәзергәчә сакланмаган санның «ике», «өч» яисә «алты» булганлыгы аңлашыла. Димәк, һиҗри 1012 ел булса, ул милади белән 1603/04 елга, 1013 булса – 1604/05 елга, 1016 булса, 1607/08 елга туры килә.

### ТАУ ИЛЕ АВЫЛЫ ЗИРАТЫ КАРШЫНДАГЫ АЕРЫМ КАБЕРЛЕК

№ 12*. ***Ишбирде Акман улына куелган таш**. 1684 ел***

Алгы ягында *(күпертмә язулы)*:
1) Һу әл-Хәййү [әл-ләзи лә йәмүт вә көллү хәййүн сә-йәмүт калә ән-нәби]
2) [галәйһиссәлам әд-дөнья сагатүн фә-әҗгальһа тагатән калә ән-нәби галәйһиссәлам]
3) әд-дөнья [сиҗнүн лил-мөэмин вә җәннәт лил-кяфир әд-дөнья җифәт вә талябиһа киляб]
4) тарих мең дә туксан бишдә*** дирләр ирде Ишбирде [морза]
5) Акман угылы үз вахытында бу билгене куйды ирәнләр
6) изгү дога берлә йад кылгайму тиб өмид өчүн

Уң ягында *(күпертмә язулы)*:
1) кәтәбә[һә] Килмөхәммәд Ишмән угылы

Сул ягында: *(күпертмә язулы)*:
1) ...

Үлчәмнәре: 97 x 45 x 17 см.

* Бу таш сакланган каберлек тимер чардуган белән коймаланган. Кабер ташы икегә сынган.
** Тексты өлешчә һәм фотосы басылган: Әхмәтҗанов М.И. XVII-XVIII гасыр татар ташбилгеләре. – Казан, 2011. – Б.63, 191.
*** Һиҗри 1095 ел милади 1684 елга туры килә.

* * *

Югарыда тасвирланган тарихи чыганаклар (шул исәптән, мәрхүмнәрнең ага, шәех, хаҗи, бик, бикә, мулла кебек титуллары да) Тау Иленең әле XV гасыр ахыры-XVI гасыр башында ук мөһим авылларның берсе булганын ачык раслый. Ә рәсми белешмәлекләрдән карасак, Тау Иленең 1602-1603 еллардан гына билгеле икәнлеген күрәбез[5]. Гәрчә элегрәк «Татар энциклопедиясе сүзлеге»нең русча һәм татарча басмаларында (1998, 2002 еллар) авылны Казан ханлыгы чорыннан мәгълүм дип дөрес белдергән булганнар. Үзебезнең татар эпиграфик истәлекләренә тарихи чыганак буларак әһәмият бирмәү еш күзәтелә. Әмма бу очракта Казан һәм Казан өязенең 1565-1568 еллардагы рәсми документында ук авылның исеме Тау Иле (Тавеля) буларак теркәлгәнен дә искәртик[6].

* * *

Тау Иле зиратында XIX гасыр ахыры-XX гасыр башына караган, гарәп язулы дистәләп кабер ташы бар. Шуларның алтысы Тау Иле авылының җир биләүчеләре морза Сөендекевләр нәселе вәкилләренә ул заманның иң оста таш уючылары тарафыннан ясап-язып куелган. Мәсәлән: «...мирза Фәтхулла, атасы Гобәйдулла Хәбибулла угылы Сундуков, Лаеш өязе Тау Иленең, туксан ике яшендә 1897 елда...», «...Тау Иленең могтәбәрләреннән мәрхүм мирза Гыйззәтулла мирза Фәтхулла угылы Сәвендекев, 74 яшендә... 1915 елда...». Болардан тыш имам, дамелла Әхмәдкәрим Хөсәен улына, аның җәмәгатенә һәм башка затларга куелган ташлар да сакланып калган.

Ташлардагы мәгълүматлардан морза Сөендекевләрнең берничә буын шәҗәрәсе ачыклана: Хәбибулла → аның улы Гобәйдулла → аның улы Фәтхулла[7] һәм Фәтхулланың уллары Гыйззәтулла, Хәсән, Хөсәен. Фәнни әдәбиятта басылып чыккан «Сөендек мирза нәселе шәҗәрәсе» вариантларының берсендә дә әлеге буыннар никтер күрсәтелмәгән[8].

Сөендекевләрнең борынгы бабалары Ишәй Хуҗаш улы һәм Мәскәү Хуҗаш улының 1602-1603, 1647-1656 елларда Норма елгасы буендагы Тау Иле авылында биләмәләре булуы теркәлгән[9]. Басылган шәҗәрәләрдән Сөендек мирзаның XVI гасыр урталарында яшәгәнлеге һәм аның атасы Шәйдәк (Сәед-Әхмәд) мирза, ә аның атасы Муса мирза икәнлеге күренә. Тау Иленең иң борынгы ташъязмаларындагы Тәвәккәл Сәедәхмәд мулла улы (1492 елда 23 яшендә), Сәедәхмәд Исхак шәех улы (1497 елда 32 яшендә), Сәйдак Хәсән хаҗи улы (1518 елда 64 яшендә) исемнәре шәҗәрәдәгеләргә күпмедер туры килсә дә, үзара бәйләнешмәгән бу затларның Сөендек мирза нәселе шәҗәрәсенә карау-карамавы аерым тикшеренүне таләп итә. 1684 елгы ташъязмада исеме уелган Ишбирде морза(?) Акман улының да шушы ук нәсел вәкиле булуы ихтимал.

* * *

Югарыда әйтелгән 1684 елгы кабер ташының уң ягында аны язган кешенең – Килмөхәммәд Ишмән улының – исеме күрсәтелгән. Әлеге мәшһүр оста XVII

---

[5] Татар энциклопедиясе. 6 томда. Т.5: Р–Та. – Казан ТР ФАнең Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты, 2016. – Б.687.

[6] Писцовое описание Казани и Казанского уезда 1565-1568 годов: публикация текста / сост. Д.А. Мустафина. – Казан: изд-во «Фән» АН РТ, 2006. – С.273.

[7] Авыл халкында «Пәтүш коесы» дип искә алына торган атама шушы Фәтхуллага бәйле булырга тиеш.

[8] Әхмәтҗанов М. Нугай Урдасы: татар халкының тарихи мирасы. – Казан: Татар. китап нәшр., 2009. – Б.134-150; Ахметзянов М.И., Шарифуллина Ф.Л. Касимовские татары: (по генеалогическим и этнографическим материалам). – Казань: Магариф, 2010. – С.177-192.

[9] Писцовая книга Казанского уезда 1602-1603 годов: публикация текста / сост. Р.Н. Степанов. – Казань: изд-во Казанского университета, 1978. – С.101-102; Писцовая книга Казанского уезда 1647-1656 годов / сост.: И.П. Ермолаев, Д.А. Мустафина. – Москва, 2001. – С.202.

гасырның икенче яртысында ясап куйган дистәләрчә ташъязма истәлек татарлар яши торган күп төбәкләрдә хәзерге вакытка кадәр сакланган. Килмөхәммәд Ишмән улының үзе һәм нәселе турында кызыклы мәгълүматлар ачыклап, аларны матбугатта бастырган идек[10].

Тау Иле авылы зиратының XIX гасыр ахыры- XX гасыр башы кабер ташлары арасында исемнәре билгеле тагын ике хаттат тарафыннан уелганнары бар. Шуларның берсе – хәзерге Мамадыш районы Кече Кирмән авылында туган, озак еллар хәзерге Кукмара районындагы Кенәбаш авылында имамлык вазыйфаларын үтәгән Фәллахетдин Шәмсетдин улы Кенәбаши (Юзкин). Икенчесе – хәзерге Алабуга районындагы Морт авылында мәзин булып торган Мөхәммәтзакир Әхмәтшакир улы.

**СҮЗЛЕКЧӘ:**

**амәнна билләһи Тәгалә** – без бөек Аллаһка иман китердек

**әд-дөнья җифәт вә талябиһа киляб** – дөнья – үләксә, аңа этләр мохтаҗ

**әд-дөнья мәзрагатүл-ахирәти** – дөнья – ахирәтнең иген кыры

**әд-дөнья сәгатүн фә-әҗгальһа тагатән** – дөнья бер сәгатьлек, аны гыйбадәт белән үткәр

**әд-дөнья сиҗнүн ли-мөәмин вә җәннәт әл-кяфир** – дөнья – иманлылар өчен зиндан, кяферләргә – җәннәт

**әрә әд-дөнья хәрабән би-игътибари фә-лә йәбка мәдамән бил-карари** – дөньяны җимерелеп бетә торган итеп күрәм, мәңгелек түгел – Аллаһның аңа әмере юк

**вә** – һәм

**вәл-мөәминунә лә йәмүтүнә вә ләкиннә йәнкыйлүнә мин дарел-фәна илә дарел-бәка** – иманлы бәндәләр үлми, бары тик вакытлы дөньядан мәңгелек дөньяга күчәләр генә

**вә ма тәдри нәфсүн би-әйи ардин тәмүтү иннә Аллаһә Галимүн Хәбирүн** – кеше үзенең кайсы җирдә үләчәген һич белмәс, бары тик Аллаһ бөтенесен белеп тора һәм бар нәрсәдән хәбәрдар

**гыялы** – хатыны

**дару фәнадин дару бәкага рихләт кыйлды** – вакытлы дөньядан мәңгелек дөньяга күчте

**иллик** – илле

**ирәнләр** – ирләр

**ирдекем (ирде)** – иде

**йад кылгайму тиб өмид өчүн** – искә алырлармы дип өметләнеп

**каләә Аллаһу Тәбарәкә вә Тәгалә** – мөбарәк һәм бөек Аллаһ әйтте

**калә Аллаһу Сөбханәһә вә Тәгалә** – һичбер кимчелексез һәм бөек Аллаһ әйтте

**калә ән-нәби галәйһиссәлам** – Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның сәламнәре булсын) әйтте

**кәтәбәһә** – моны язучы

**көллү мән галәйһа фанин вә йәбка вәҗһү Раббикә Зөл-Җәлали вәл-икрами** – җирдә булган бар нәрсә һәлак булачак, фәкать олуглык һәм хөрмәт иясе булган Раббыңның заты мәңгелек

**көллү нәфсин заикател-мәүт сүммә иләйна түрҗәгунә** – һәр җан үлем ачысын татыр, барыбыз да Аңа кайтарылачакбыз

**көллү хәййүн сә-йәмүт** – һәр тереклек үлә

**күрәрмән дөньяны вәйран бары бакый ирмәс һәмишә йук карары** – дөньяны җимерелеп бетә торган итеп күрәм, мәңгелек түгел – Аллаһның аңа әмере юк

**ләүхне бина кыйлды** – ташны куйды

**нәүвәрә Аллаһу кабриһи** – Аллаһ каберен нурласын

**фә-йа ли-шәваһиде Раббил-галәмин** – әй, Аллаһның шаһитләре

**хәләле** – хатыны

**Һуа әл-Хәййү әлләзи лә йәмүт** – ул (Аллаһ) үлемсез ■

---

[10] Мәрданов Р., Һадиев И. «... Мөселманлардин дога өмид өчен» // Чын мирас. – 2013. – №7. – Б.32-33; Һадиев И., Мәрданов Р. Мамадыш төбәгенең ташъязма истәлекләре. – Казан: Татар. китап нәшр., 2015. – Б.11-12.

# *Габдулла Тукай турында бер истәлек*

Ләлә Мортазина

Биектау районының Мәмдәл авылында яшәгән күршебез Габдрахман ага Вахитов – күренекле татар драматургы Хәй Вахитның якын туганы, әтисе белән бертуган абыйсы иде. Бөек Ватан сугышында булган, чолганышта калып, зур батырлыклар күрсәткән өчен «Кызыл Йолдыз» ордены белән бүләкләнгән хөрмәтле ветеран, сугышка кадәр Казанда авыл хуҗалыгы техникумын тәмамлап, озак еллар трактор бригадасы бригадиры булып эшләгән кеше. Бик зыялы, гыйлемле, татар мәдәнияте, әдәбияты, атаклы шәхесләр, гомумән татар дөньясыннан яхшы хәбәрдар, үзлегеннән скрипкада уйнарга өйрәнгән[1], бик матур, моңлы итеп татар халык көйләрен уйнаучы озын буйлы, горур кыяфәтле әлеге абыйның өебезгә керүен аннан күпкә яшь булса да, «серләре килешкән» әтием генә түгел, без – балалар да көтеп ала идек. Габдрахман аганың күп укыганлыгына, бик күп күренекле шәхесләрне якыннан күреп белүенә шакката идек без. Ул сөйләгән геройлар арасында атаклы җырчылар, шагыйрьләр, композиторлар күп була иде. Алай гынамы, ул бит хәтта Тукайны да үз күзләре белән күргән, аның белән сөйләшү бәхетенә дә ирешкән!

Габдрахман ага Тукай турында күп сөйли иде, аның шигырьләрен яттан кабатлый, тик хәзер искә алачак вакыйга, балалыгым беләнме, истә калмаган. Аның хакындагы истәлекне күптән түгел әтием – Тукайның  чын фанаты, аның турында бик күп укыган, күп белгән, Тукай белән бәйле һәр китапны, истәлекне җыючы, кадерләп саклаучы, кыска гына әйткәндә, тукайчы сөйләде[2].

Болай була бу. Габдрахманның әтисе Габделвахид абзый[3] Казанның Александр сыра заводына[4] чимал – агач әзерләү буенча заготовщик булып эшләгән. Улының сөйләве буенча, бик эшчән, булдыклы, бик ярдәмчел кеше булган, мәчет-мәдрәсәләргә ярдәм итеп торган. «Әтинең өс киемнәрен салып йоклаганын да хәтерләмим, гел эштә иде», – дип сөйли торган булган улы Габдрахман. Мәдрәсәдә укучы балаларының укуы белән гел кызыксынып, сорашып торган, китап-дәфтәрләрне дә үзе юнәткән. Бервакыт шулай Габдрахман, шәкертнең[5] дәфтәр тышындагы Тукай сурәтенең кара белән буялганын күреп: «Улым, моны ник буядың?» – дип сораган. Габдрахман хәлфәнең дәфтәр тышында кеше сурәте торуы дөрес булмау, Тукайның динсез булуы, шуңа күрә аны буярга кушканлыгы турында сөйли. Габделвахид абзый, бу хәлне ишеткәч, бик борчылган: «Аһ, оятсызлар», – дип, укытучыны сүккән. Аннары: «Улым, мин сине Тукай янына алып барырмын, син үзең аның белән танышырсың, аның нинди кеше икәнен үзең күрерсең», – дигән.

Күп тә үтми (бу якынча 1911-1912 еллар була), әтисе белән 11-12 яшьлек малай Ту-

---

[1] Вахитовлар гаиләсендә музыкага мәхәббәт көчле була, башка балалары белән беррәттән, кызлары Сара да скрипкада уйный белгән.

[2] Габдрахман ага Вахитовның (1900 елгы) Тукай турындагы хатирәләре Әхмәтов Рәис (1945) сөйләве буенча язып алынды.

[3] Габделвахид – Хәй Вахитның бабасы (әтисе Габделкаюмның әтисе). Габделкаюм белән Габдрахман бертуганнар.

[4] Сәүдәгәр И.В. Александровның Казан шәһәрендәге сыра заводы турында сүз бара. 1892 елда ул аны прус-сияле О.Петгольцтан сатып алган була. Россиядәге иң зур заводларның берсе, бик күп халыкара бәйгеләрдә призлы урыннар яулый. 1922 елдан «Кызыл Шәрык» («Красный Восток») исеме белән билгеле.

[5] Габдрахман туган авылында һәм Казан мәдрәсәләренең берсендә белем алган.

Габдрахман ага Вахитов



кай янына – Казан үзәгендәге Болгар номерларына килә. Икенче катка күтәреләләр, Тукай яшәгән бүлмәгә керәләр[6]. Габделвахид ага Тукай белән күптәннән таныш булган. Аның бертуган агасы Фәттах абзыйның элеккеге елга пристанендa харчевнясы бар икән. Габделвахид Казанга килгәндә еш кына туганы янына кергән. Шунда ук Х.Ямашев, Г.Тукайлар да йөри торган булган. Бәлки шундый очрашуларның берсендә танышкан булганнардыр.

Тукай, үзе янына килгән аталы-уллы кунакларны күреп: «Ә, Габделвахид абзый икән!» – дип куя. Үзе, бер төймәгә басып, хезмәтче малайдан пәрәмәчләр китерүен үтенә. Күп тә үтми, бөтен бүлмә эченә итле пәрәмәчнең хуш исе тарала. Сөйләшә-сөйләшә тәмләп чәй эчәләр. Кечкенә малай Тукайның нәрсә сөйләгәннәрен хәтерләми, тик: «Лампаның яктысы төбенә төшми, еракка китә...» – дигән сүзләрен генә гомергә истә калдыра. Габдрахман аганың фаразлавы буенча, бу шагыйрьнең Казан артының караңгылыкта булуына ишарә итүе, милләтебез өчен борчылуы була. Бәлки шагыйрь кунакларына үзенең данлыклы «Казан вә Казан арты» шигырен укыган булгандыр. Анда да бит тирә-юньгә нур чәчеп торган, шәмдәлләргә тиң Казан турында мондый юллар бар:

*«Бер борыл да, и Казан, син бу Казан артын кара:*
*Нур чәчәсең бар өязгә, үз өязең кап-кара.*
*«Үз төбенә төшми, ди, шәм-лампаның һичбер нуры», —*
*Шул мәкаль монда дөрест шул, ах, аны җен оргыры!»*

Киткәндә Тукай кунакларны: «Ярый, Габделвахид абзый, тагын күрешергә язсын!..» – дип озатып калган.

Ләкин аларга башка күрешү насыйп булмый. Күп тә үтми, танылган шагыйрь вафат була. Ә аның турындагы шушы кечкенә генә истәлек-хатирә бер татар малаеның күңеленә кереп урнашып, аны гомере буе озата барган... ■

[6] Тукай Болгар номерларында 40 нчы бүлмәдә яшәгән.

# «Кулыңда форсат вакытта укып кал»

*XX йөз башында татар хатын-кызлары өчен заманча мәктәпләрнең иң беренчесе – элеккеге Вятка губернасының Иж-Бубый авылында Мөхлисә Бубый тарафыннан ачыла[1]. Ул, алдынгы карашлы, тәвәккәл ханымнардан булып, хатын-кызларны белем һәм мәгариф юлына кертү өчен бар көчен куя. Кызлар мәктәбе иң алдынгы мәктәпләрдән санала, бирегә Уфа, Казан, Мәскәү, Сембер, Ташкент, Сәмәрканд, Семипалат, Төмән, Әстерхан, Пржевальски, Бишкәк, Касыйм, Зайсан һ.б. калалардан укырга киләләр.*

*Бубый мәдрәсәсендә укыган талибәләрнең хатлары күчерелгән кульязма җыентык Казан федераль университеты Фәнни китапханәсендә саклана[2]. Хатлар 1908-1912 елларга нисбәтле. Игътибарыгызга шуларның берничәсен тәкъдим итәбез. Алар арасында кызларның әти-әнисенә, дус кызына, кардәшенә, остазына язган хатлары һәм, иң мөһиме, Мөхлисә Бубыйның талибәсенә язган хаты да бар. Хатның беренче юллары ук, Мөхлисә ханымның укучысына «кызым» дип мөрәҗәгать итүе, аның үз эшенә бирелгәнлеге, талибәләре өчен чын күңелдән кайгыруы, үз баласыдай якын күрүе турында сөйли.*

*Башка хатлар да кызларның аң-белемгә омтылышы, милләт һәм аның киләчәге өчен борчылу хисе белән сугарылган. Аларда шулай ук хәзерге заман өчен дә актуаль булган әхлакый кыйммәтләрне – әти-әнине, остазыңны зурлау, ярату, хөрмәт итү кебек гүзәл сыйфатларның матур үрнәген дә күрергә мөмкин.*

*Бу хатлар берничә талибә тарафыннан язылган. Ләкин әлегә ачыкланып бетмәгән моментлар бар. Авторлары турында тулы мәгълүмат юк. Бары тик җавап булып килгән хатлардагы адрес буенча, аларның Яңапар[3] (хәзерге Актук авылы) авылыннан Бубый мәдрәсәсенә килеп укулары билгеле. Кайбер хатлар Рәйхана (Бәдрелбанат) Габдуллина исеме белән имзаланган.*

**СӘҮЕКЛЕ КЫЗЫМ ШӘРИФКАМАЛ!**

Бубыйга укырга килү хәбәрләрең язылган хатың да килеп җитте. Сине бәк күрәсем килдегеннән, бик мәмнүн *(шат)* улдым. Ләкин кыш көнендә бик дырышып укымыш идең, җәй көнендә дә бик дырышып, сихәтеңә зарар китермәсәң ярар иде. Ләкин Бубыйның һавасы сезнең авылның һавасы кеби юеш вә начар булмаенча, билгакес *(киресенчә)*, коры вә бик гүзәл булдыгыннан, дәресләреңә күп дырышмас шарты илә Бубины сихәтең өчен, бер тарафтан, түзмәссең, дәресләреңә дырыш[ыр]сын, дип Бубига килүдән курыксам да, икенче тарафтан, ничек булса да түздерергә дырышырмын, карап торырмын, диеп, Бубиның һавасыннан истифадә өчен күңелеңне нәсыйхәт күрмәктәмен. Иж буендагы ямьле йирләр, нарат урманнардагы гүзәл һавалар вә яшел палас кеби дулкынлап торган үләннәр арасында йөреп, кәеф-сафа кылу кеби адәмгә сихәт вә сәламәтлек вирән бернәрсә дә юк бит. Синең дә гәүдәң арык, каның аз, шуңа күрә Бубиның болын вә урманнарында йөрү сиңа бик зиядә файда вирәчәкдер, ләкин аңла, дырышмазлык шар[ты] илә. Анакаң[а] бәндән махсус сәлам сөйлә. Әгәр сине китерә ул килсә, аның илә дә күрешеп рәхәтләнәчәкмез. Һәрвакыт синең өчен хәер догада улан остазың **Мөхлисә Нигъмәтуллина**.

*Бубый*
*1908. – 27 октябрь*

[1] Бертуган Бубыйлар һәм Иж-Бубый мәдрәсәсе: Тарихи-документаль җыентык. – Казан: Рухият, 1999. – Б.6.
[2] Казан федераль университеты Фәнни китапханәсенең Сирәк китаплар һәм кулъязмалар бүлеге, «5992т» шифрлы кулъязма. 46 кгз.
[3] Яңапар тарихы. История Актукова. – Казан,. – 2008. – Б.4.

Мөхлисә Нигъмәтуллина хаты

**ВӘЛИ НИГЪМӘТЕМ ӘТКӘЕМ ВӘ ШӘФКАТЬЛЕ ӘНКӘЕМ!**

Бубый[га] егерменче сентябрьдә сәламәт килеп җиттек. Егерме икенче сентябрьдә беренче рөшдиягә *(урта сыйныф)* язылып, укый башладык, иптәшләрем бик ыспай, бик ягымлы булдыкларыннан, сыйныфта утыру һәм сабак уку бик хозур вә бик күңелле. Монда миңа мәктәпләр бездәге дәгел, бик күңелле, якты вә тору өчен сахралар бик йайлы, вә һавалар да саф вә тәмиздер *(чиста)*. Шуның өчен бунда бер ел артык торып укысам да, бер дә сагыныр кеби тимәймен. Ләкин хәзер кыш булды, карлар яуды. Һавалар салкынайды. Алып килдекем бишмәт белән генә түзеп булмаз. Шуның өчен бәңа тизлек илә бер тун тектереп җибәрүеңезне рижа идәмен. Бәңа бу тунны тизрәк җибәрә күреңез. Бәнем бундагы адресым мәгълүм булмадыгындан, бу хатымда язып маташуга хаҗәт юк.

Сабагына бик дырышан вә һәрвакыт сезең хис-тәүҗиһеңезне эстәйән **кызыңыз Рәйхана**.

*1908. – 27 октябрь*

**СӘҮЕКЛЕ КЫЗЫМ!**

Якшы хәбәрләр илә тулы хатыңны алдык. Беренче рөшдиягә керергә муафыйк булмаклыкыңыздан бик зиядә мәмнүн *(бик канәгать)* улдык. Һәрвакыт вә һәрбер намаз артларымыздан: «Алла сиңа файдалы гыйлем вә сәгадәтле гомер вирсен иде», – диеп, догалар кылмакдамыз. Сабагыңа бик дырыша күр, кызым. Безем ике күземез синең милләткә хезмәт идәчәкеңдәдер. Бик дырыш, бик укы. Иптәшләреӊ арасында кеше көлкесе була күрмә. Тун өчен бер дә хафаланма, озакламамыз, йибәрермез. Мехлар вә тышлыклар һәммәсе хәзер. Фәкать тегүчене генә көтеп торамыз. Тегүче өч-дүрт көннән тегәргә вәгъдә вирде. Ләкин үзең булмагачдин, үлчәү бик тугъры килеп җитәр микән? Үзеңнән үлчәү көтсәк, бик озакка калыр. Шуның өчен, Аллага тапшырып, тектерүгә карар вирдек. Бик килешмәсә дә, бик ямьсез дә булмаз. Кирәк нәрсәләреӊ булса, хат илә сорарсыӊ, җибәрермез. Ләкин нәрсәләреңне әрәм итмә, пычратма, саклап тот. Киемеңне зиннәтләп, тәмиз тотсаң, киемең үзе дә сине зиннәтләр, балакаем! Тышкы киемнәреңне таза вә ыспай тотарга иҗтиһад *(тырышлык)* кылдыгың кеби, гыйлем вә мәгърифәт илә зиннәтләүне дә онытма! Кеше кием илә дәгел, бәлки гыйлем-мәгърифәт

илә кеше буладыр. Гыйлемсез кешенең хайваннан аермасы булмадыгы кеби, сүзенең дады *(гаделлек, турылык)* вә кеше арасында кадере вә мәрхәмәте дә булмаз. Гыйлем кеби кадерле бернәрсә дә юк, балакаем! Кадер вә хөрмәт һәм милләтә хезмәт – гыйлем илә генә табыла торган шәйләрдер. Яшь вакытыңны ганимәт *(уңыш)* билә. Кулыңда форсат вакытта укып кал. Яшьлек уза, яңадан кайтмаз. Яшь вакытымда нигә укымадым микән, диеп соңыннан нәкадәр үкенсәң дә, файдасы булмаз, шуның өчен һәрвакыт дәресләреңдә иҗтиһадта була күр, балакаем!

Сәгадәтеңне эстәйән **анакаң фәләнә**.

*1908. – 3 ноябрь*

**ГЫЙЗЗӘТЛЕ ӘТКӘЕМ ВӘ ШӘФКАТЬЛЕ ӘНКӘЕМ!**

Мәрхәмәтләр вә шәфкатьләреңез янына бүләкләреңез илә тулы хатыңыз да килеп җитте. Нәкадәр сөенгәнемне сорамаңыз. Читдә укыган вакытда ата-анадан килгән хат вә җибәрелгән бүләкләр кеби шатлык вирә торган шәйнең юклыгыны шимди *(шулай ук)* бән бу сәнә аңладым. Вә сезне сагынып бик аптыраган, сабагына дырышып тәмам арган вакытымда хатыңыз килеп җитә. Яңадан сабакка дәртләнеп китәмен. Ләкин хатыңызы бик кыска язасыз, күп хәбәрләр илә тутырып, озынырак яза күреңез, әнкәем!

Тунны, иншаллаһ, тиз җибәрерсез, суыклар отыры куәтләнә, көннән-көн туңам. Тунның килешүе – бик килешмәсә дә ярар. Фәкать суыктан сакламак өчен бик лязем. Белмәм, бәңа бу сәнә нигә суык тиз тәэсир итә микән? Хәтта бу көн тәнем кызып ятарга мәҗбүр булдым. Сабакларым калмаса, озакка сузылмаса ярар иде, диеп курыккан идем.

Хәмедләрем *(мактау)* улсын, сез виреп җибәргән хинаны[4] истигъмаль *(куллану)* кылдыгым соңында, икенче көн сабакка барырлык улдым, шимди, Аллага шөкер, бернәрсә дә калмады. Элекке кеби, бәлки элеккесеннән зиядә *(артык)* сабакларыма дырышмакда вә остазларымның хис-тәүҗиһләрене казанмакдамын. Әгәр Аллаһ Тәгалә сәламәтлекемне вирсә, имтихан вакытларында беренче булып, сезне бик шатландырмакны өмид итәмен.

Әткәем! Виреп җибәрдекеңез акчам илә китаплар вә кәгазьләр алгалап, шимди кулымда бик аз калды, акчага мохтаҗ булып тору кадәр мөшкел эш юк. Риҗа итәмен *(үтенәмен)*, әткәем! Бәне бу акча кысканлыкына төшерә күрмәңез, бәңа тизлек илә микъдаре кяфи *(җитәрлек күләмдә)* акча җибәрә күреңез. Исраф итә торгандыр, диеп исәпләмәңез, әткәем! Тотдыкым бер тиен мәсърафка *(тотылган акча)* кадәре бик ачык язып барамын. Кайтдыгым бу хисабымны сезгә күрсәтеп, бер тиен дә исраф кылмадыгымны сезнең хозурыңызда исбат идәчәкем, әткәем! Сезнең хис-тәүҗиһеңездән башка һичбер шәйгә мохтаҗ булмайан кызыңыз: **Рәйхана Бәдрелбанат**.

*1909. – 10 ноябрь*

**ГАЗИЗ ӘТКӘЕМ ВӘ ШӘФКАТЬЛЕ ӘНКӘЕМ!**

Дүрт күзем илә көтдекем тун, ниһаять, килеп җитте. Туңа-туңа, калтырай-калтырай чыгарга җиткән җаннарым тәмам рәхәтләнде. Белсәңез, бу тун килгәнче нәкадәре җәзалар чикде[м], хосусән иртә торып, ачы суыктан вә ачы буранда тунсыз сабакка бару нәкадәре кыен вә нәкадәр агыр бер хәлдер. Шуның өчен суык сугып, бик хаста була яздым. Имди хәмедләр *(мактау)* улсын, тун килде, суыктан котылдым. Туным бераз озын булса да, зарарлы дәгел. Күңелемә бик килеште, бәңа бу кадәр ингам *(яхшылык)* вә ихсаныгыз *(ярдәм)* өчен тәшәккердән гаҗизем, әнкәем!

Әнкәем! Бән бу хакларыңызы кайтара алмам, фәкать сезә мәхәббәт кылып, һәрбер сүзеңезе тыңлап, дәресләр йыйма һәм иҗтиһад итеп, имтиханда, иншаллаһ, берен-

[4] Хина – кына – хин агачының кабыгыннан алынган ак төстәге порошок.

че чыгарык сези шатландырырга дырышырмын. Затән *(нигездә)*, сез үзеңез милләт вә гыйлем-мәгърифәткә иҗтиһад вә милләтә хезмәттән башка бер шәй итмәйез дә, вә эстәмәк исәбендә һәм дәкелсеңез. Бән дә сезең бу микъдарларыңызны вөҗүдә чыгарачагыма сүз вирәмен! Бик беләмен, мәктәпләрдә гыйлем тәхсил итмәк *(гыйлем алу)* бәк күп кемсәгә насыйп була торган шәй дәгелдер. Бән сезең арканызда вә сезең мәрхәмәтеңездә бу нигъмәтнең кадерене бик беләмен. Шуңа күрә, сабагыма бик иҗтиһад кылып, көн саен иптәшләрем арасында беренче буларак остазларымның һәрберсенең афәрин вә рәхмәтләрене алмакдамын. Мәгәр сезең саяңездә яңадан өч сәнә укып да, бу мәктәпне тәкмил әйләсәм *(тәмам итсәм)*, ул вакыт, бер тарафтан, сезең хезмәтеңездә булындыгым кеби, икенче тарафдан, балалар укытып, милләтемә хезмәт итмәйдә кальбемне беркетеп торамын. Сыйныфтагы иптәшләрем дә һәммәсе бу мәктәпне тәкмил идекендә балалар укытып, милләтемезә хезмәт итү исәбендә торалар. Әгәр без һәммәбез дә бу мөкатдәс фикерләремезне вөҗүдә чыгарсак, иншаллаһ, безнең милләтемезә тәрәккый табар вә җәһаләт *(наданлык)* вә сәфаләтдән *(хурлыктан)* чыгар. Менә без дә шулвакыт сәфарәт кояшлары *(тулы хокук)* астында рәхәт күрермез. Һәрвакыт тәмам ихлас кальбе илә сезә гарыз гобудиять идән *(тугры буйсынган)* кызыңыз **Бәдрелбанат**.

*1912. – 10 февраль*

**БИК СӘҮЕКЛЕ, ШӘФКАТЬЛЕ АНАКАЕМ!**

Шәфкатьләр вә күңелеңезнең иң эченнән кубып килгән мәрхәмәтләр илә тулы хатыңызны көчкә менә бүген алып укыдым. Бән Яңапарга чыгып киткәндә: «Кайгырма, балакаем! Сәңа атна саен бер мофассаль *(тулы, җентекле)* хат язармын, үдәге кеби безнең хәлемезне белеп торырсың», – диеп әйткән сүзеңез буенча бән сездән менә өч ай булды, атна саен хат көттем. Бу көнгә кадәр бер данә хатыңызы аламаюп, нәкадәр кайгырдым вә нәкадәр яшьләр агыздым, анакаем! Бәнем сезә мәхәббәтем вә сәдакәтем бик ачык мәгълүм улдыгыннан, сез бу хәбәрсезлекеңезнең никадәр яман әсәр вирдегене үзеңез бик ачык беләсез бит, анакаем! Бән монда бик ялгыз, күңелләрем бик юка: зинһарлап әйтәм, анакаем! Моннан соң бәни хатсыз куеп, буйлә хафаланырга вә бик күп яшьләр түгәргә мәҗбүр итә күрмәңез, анакаем! Сездән хат килсә, сезнең үзеңезне күргән кеби булып, күңелләрем басыла вә сезнең әсәрле вәгазьләреңезне яңадан хатирә төшереп, өр-яңадан дәресләремә дырышасым килә башлайдыр. Әмма әгәр сездән хат килмәенчә, озак торса, ул вакыт күңелләрем бөтенләй төшә вә фикерләрем тарала, исәпләрем югала, күзләрем сабакларымны күрмәз уладыр. Бик беләчәк, бик ансат сабакларым хосусында остазларымнан тәкъдир вә орышулар ала башлаем: менә бәнем хәлем ошбудыр, анакаем! Минем бу хәлемне бик якшы вә бик ачык беләсез, шуңа күрә риҗа кыламын, анакаем! Бәни сәүекле кызны кызганып, күңелләрем юбатачак хатларыңнан мәхрүм кыла күрмә. Нәгыймә илә Мәсгуд тә бәңа хат язгаласыннар. Язулары нәкадәр начар булса да, зарар юк. Бән анларның язуларыны күреп, үзләрене күргән кеби сүенәмен вә үбә-үбә рәхәтләнәмен. Бән анларны да бәк сагынамын, бәлки анлар да бәни сагына торганнардыр. Хуш, барчаңыз сәламәт улыңыз, хәзергә башка язардай хәбәрләрем юк. Ләкин бәнем язлык аяк киемнәрем улмадыгыннан, хәзердән үк бер бик тизлек илә бер ботинка илә бер резинка калуш җибәрсәңез, дәхи бер мәртәбә үзеңезә мөнтәзар *(көтелгән)* идәчәксеңез.

Анакаем! Сезне сагына-сагына хатыңызны көткән сәүекле кызыңыз **Банат**.

*1912 сәнә 15 февраль*

*Кереш мәкалә һәм текстны басмага КФУның Н.И.Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсе библиографы **Энҗе Сабирова** әзерләде.* ■

# ТУКАЙ ЖАНДАРМЕРИЯ ДОКУМЕНТЛАРЫНДА

***(Шагыйрьнең бер җыентыгы тарихына яңа материаллар)***

Лена Гайнанова

*Габдулла Тукай Уральскидан Казанга 1907 елның октябрь башында килә. Шул елның ахырында «Шәрәф матбагасы»нда «Шигырьләр көтепханәсе» сериясендә аның 3 нче һәм 4 нче дәфтәр булып, «Габдулла Тукаев шигырьләре» исеме белән ике китабы басылып чыга. Шуларның «4 нче дәфтәр» дигәне һәм, әлбәттә, авторы да бәлагә тарый. 1911 елда китапка Матбугат эшләре буенча Казан вакытлы комитеты, ягъни цензура тарафыннан арест салына. Бу турыда беренче булып тарихчы галим Х.Х.Хәсәенов язып чыга. Соңыннан кайбер башка галимнәр дә шул турыда мәгълүмат бирә. Әмма бернәрсә ачыкланмый тора: ни өчен цензура 1907 елда чыккан китапка дүрт елдан соң арест сала соң? Дөрес, моны реакциянең көчәюеннән дип тә аңлатырга була. Ләкин бу китапка карата реакция конкрет нәрсәдә чагыла? Китапны һәм авторын эзәрлекләү кайчан һәм нинди эзлеклелектә алып барылган? Бу сорауларга җавапны без Татарстан дәүләт архивындагы Казан губернасының жандарм идарәсе һәм цензура документларында таптык.*

Тукайның әлеге җыентыгы, без аны шартлы рәвештә «Дүртенче дәфтәр» дип атыйк, 1908 ел башында басыла. Титулда – 1907 ел, ә тышлыкта 1908 ел тора. «Матбугат эшләре буенча Казан вакытлы комитетының дөньяга чыккан барлык басма әсәрләрне теркәү» кенәгәсендә 1908 елның 6 гыйнвары, диелгән[1]. Җыентыкның цензоры дип Н.Ф.Катанов күрсәтелгән.

«Дүртенче дәфтәр» басылып чыккач, бер айдан соң, Казан жандарм идарәсенә Чистай охранкасының «Персий» кушаматлы агентыннан донос керә. Агент ул китапның үзен һәм андагы шигырьләргә аңлатмасын җибәрә[2]. 1986 елда документлар арасында мин ул китапның «Персий»дән килгән нөсхәсен күргән идем. Агент кулы белән кайбер шигырьләргә төрле тамгалар — крестиклар, өндәү билгесе куелган, «Переведите!» – дип тә язылган. Ул китап әле генә типографиядән чыккан кебек яңа килеш сакланган иде (хәзерге көндә ул


«شعرلر كتبخانه‌سندن»

عبدالله توقايف شعرلرى

٤ نچى دفتر.

قزانده، شرف مطبعه‌سى.

КАЗАНЬ.
ЭЛЕКТРО-ТИПОГРАФІЯ ШАРАФЪ.
1907.

«Габдулла Тукаев шигырьләре»ннән «4 нче дәфтәр»нең титул бите. 1907 ел

[1] ТРМА. 420 ф., 1 тасв.
[2] Шунда ук. 199 ф., 1 тасв., 3458 эш, 43 б.

китап урынында юк инде). Аңлатма язуында агент «Китмибез!», «Хөррият хакында» шигырьләрен русчага тәрҗемә итә һәм нәтиҗә чыгара: *«Это враждебного содержания, против правительства и вообще русских людей, читаются учениками медресе открыто»*. Шунда ук агент «Персий»нең тагын бер язуы да теркәлгән: *«За февраль месяц двенадцать рублей получил»*[3].

Донос, күрәсең, исәпкә алынган. Һәрхәлдә бу «Дүртенче дәфтәр»нең 1909 елда чыккан икенче басмасында шул ике шигырь — «Китмибез!» белән «Хөррият хакында» шигырьләре төшереп калдырылган. Гәрчә әлеге икенче басманың да цензоры Н.Катанов булса да.

Тукайның тормышын һәм иҗатын өйрәнүчеләр үз хезмәтләрендә шагыйрьнең бу җыентыгы һәм аңа бәйләнешле 1911 елдагы вакыйгалар турында әлеге документларны күрсәтү белән генә чикләнделәр. Хәлбуки жандармерия документлары арасында 1907 елгы «Дүртенче дәфтәр» язмышы һәм аңа бәйләнешле 1911 елгы вакыйгалар турында сөйләүче әле беркем тарафыннан тасвирланмаган «эшләр» дә бар икән. Вакыйгалар болай бара: 1911 елның февралендә Уфада «Шәрекъ» типографиясендә тентү була[4]. Алынган китапларның 14 исемдәгесен, шикләләр дип сайлап алып, 26 мартта Санкт-Петербургтагы жандарм идарәсенә җибәрәләр. Шул китаплар арасында Тукайның «Дүртенче дәфтәре»нең 1909 елда чыккан икенче басмасы да бар.

Санкт-Петербург жандармериясендә полковник Николаев Уфадан килгән китапларга тикшерү үткәрә[5]. Сафа Гатаулла улы Баязитов «Иттифакъ хакында», «Тавыш хакында», «Кичке азан» шигырьләрен тәрҗемә итә. Тәрҗемәләр беркетмәсе янында полковник Николаевның язуы да бар. Ул хәзерге көндә Тукайның Казанда Болгар номерларында яшәп ятуын хәбәр итә һәм, бик мәгълүматлы кеше кебек: *«Бу китаплар, мөгаен, таралмагандыр, чөнки татар китаплары бик әкрен сатыла, алар татар китаплары кибетләренең складларында ятадыр»*,— ди. Ягъни әгәр дә тиз генә конфискация ясасаң, ул китаплар укучыга барып җитмәячәк. Юл уңаенда шуны да әйтеп үтик: «Дүртенче дәфтәр»нең икенче басмасы 1909 елның март аенда чыга һәм кереш мәкаләдә бу китапның, 1907 елгы беренче басмасы сатылып беткәнгә күрә, укучылар соравы буенча, икенче кат басылуы хакында әйтелә.

Санкт-Петербург жандарм идарәсе документлары, беркетмәләре, Уфа, Вятка жандарм идарәләренең төрле хатлары, белешмәләре белән тулыландырылып, 1911 елның 30 июлендә Казанга, Казан жандарм идарәсе башлыгы, Казан округ судының аеруча мөһим эшләр белән шөгыльләнүче тикшерүчесе адресларына «совершенно секретно» грифы белән җибәрелә[6].

Бу досье әзерләнгән арада 1911 елның 22 маенда Эчке эшләр министрлыгының Казандагы җинаятьләрне тикшерү бүлегенә аноним хат килә[7]. Хатта университет типографиясе хезмәткәре Әхмәтвәли Әхмәдуллиннның «Сабах» көтепханәсе складында тыелган китаплар саклавы турында әйтелә: *«В жандармский отдилении прошу обыску дилить у типографий Университетскии живет Валиулла Ахмадуллин у его в квартири на этом же времни сохраняется конфисковни книги на татарском языке «Мин-бир-хадис» 100 экземпляров а потом три короб. разни конфисковни книги сохраняется на Евангелистовский ул. дом Мясникова в склади все эти книги отпускано для сохранити от книгоиздательство «Сабах» обыску в скором времни делайти а то*

---

[3] Шунда ук. 199 ф., 1 тасв., 3458 эш.
[4] Шунда ук. 199 ф., 1 тасв., 2086 эш, 189-191 б.б.
[5] ТРМА. 199 ф., 1 тасв., 2086 эш, 192 б.
[6] Шунда ук. 199 ф., 2086 эш. 19 б.
[7] Шунда ук. 2 тасв., 1237 эш. 29 б.


Протоколъ
1911 года 1 июля 10-18 дня, въ г. Казани. Я, Отдѣльного Корпуса Жандармовъ Подполковникъ Добродеевъ, въ порядкѣ Положенiя объ охранѣ, въ присутствiи нижеподписавшихся понятыхъ, черезъ переводчика учителя Русскаго Класса при Апанаевскомъ медресе г. Казани Миргаяза Хасанова Иманаева, производилъ осмотръ всего матерiала, взятаго по обыску 25 Мая сего года у проживающаго въ г. Казани по Черноозерской улицѣ въ домѣ Типографiи Казанскаго Университета [illegible] Казанскаго мѣщанина Абдулъ-Валея Мухаметсаттинова Ахмадуллина, при чемъ оказалось:
1/. брошюра въ 2-хъ экземплярахъ подъ заглавiемъ "Стихи Абдуллы Тукаева" 4-ая книжка изъ книжнаго магазина "Стихи". Электро-типографiя Шарафа 1/.
2/. брошюра въ 2-хъ экземплярахъ [illegible] "[illegible] на 22 [illegible]". 2-я часть

В.Әхмәдуллиннан алынган китаплар исемлегендә беренче булып Г.Тукайның «4 нче дәфтәр»е күрсәтелә

*они спрятут на другой место на той». Конверт с адресом: «Казань в жандармский сыскной отделиний от А. М. И. Почтовые штемпели: Казань, 18.5.11».* 26 майга каршы төндә В.Әхмәдуллинда тентү үткәрелә. Документлар, китаплар алына. Китаплар исемлегендә беренче булып Тукайның ике данә 1907 елда чыккан әлеге «Дүртенче дәфтәр»е күрсәтелә[8]. Яңа «Эш» ачыла. Ул «Эш» *«Переписка в порядке охраны по выяснению степени политической благонадежности служащего в университетской типографии Абдуллы Валея Ахмадуллина»* дип атала.

Бу вакыйгадан соң берничә көн үтүгә, Казан жандарм идарәсенә Санкт-Петербургтан Уфа һәм Вятка аша җибәрелгән әлеге калын досье килеп төшә.

Әхмәдуллиннан алынган китаплар арасыннан 6 китап сайлап алына.

Жандармерия подполковнигы Добродеев һәм тәрҗемәче – Апанаев мәчете каршындагы мәдрәсәдә рус теле укытучысы Миргаяз Иманаев тарафыннан алар «тенденциоз» дип табыла. Казан жандарм идарәсендә Санкт-Петербургтан килгән досьеда да, Әхмәдуллиннан алынган китаплар арасында да Тукайның «Дүртенче дәфтәрен»дәге шигырьләре сәяси яктан шикле дип каралуына игътибар итми калмыйлар, әлбәттә. Аларны квалификацияле тәрҗемә итү хаҗәте туа.

1911 елның 23 июнендә Добродеев болай яза: «*... переводчик ввиду двусмысленности... переводить затрудняется и поэтому не может дать своего заключения о направлении содеражания этих брошюр в политическом отношении, а потому я постановил: помянутые брошюры препроводить через начальника Казанского губернского жандармского управления председателю Казанского временного комитета по делам печати на распоряжение о переводе брошюр и дачи своего заключения, в чем именно может заключаться тенденциозность содержаний этих брошюр и могут ли быть эти брошюры дозволены к обращению в публике*»[9]. Шул көннән Казан жандарм идарәсе начальнигы Калинин белән Матбугат эшләре буенча Казан вакытлы комитеты рәисе Пинегин арасында бик кызу хатлар алышу китә. Хатларның барысында

[8] Шунда ук. 12 б.
[9] ТРМА. 199 ф., 2 тасв., 1237 эш, 16 б.

да «секретно», «совершенно секретно» грифлары тора. Жандарм идарәсе цензураны ашыктыра: *«... не отказать в распоряжении о переводе наиболее характерных мест и препровождении мне в возможно скором времени»*,[10] *«...имею честь просить Ваше превосходительство не отказать в распоряжении о скорейшем доставлении мне названных переводов и возвращении брошюр...»*[11]

Цензор Катановка «Дүртенче дәфтәр»дәге шигырьләрне тәрҗемә итәргә кушыла. Искә төшерик: үз вакытында бу китапны басарга рөхсәтне Катанов биргән иде. Ә хәзер ул анда җинаять билгеләре эзләргә мәҗбүр. Күренгәнчә, эзәрлекләүләрнең инициаторы булып жандармерия тора. Ул цензура рөхсәте белән чыккан китапларны тота, җинаять эшләре кузгата, цензурага басым ясый.

1911 елның 1 октябрендә цензурадан жандарм идарәсе сораган, Катанов башкарган тәрҗемәләр китә[12]. Ләкин жандармнарны мондый гына җавап канәгатьләндерми, алар нәтиҗәләр чыгаруны, «заключение» язылуын тели. Һәм 1911 елның 6 октябрендә Матбугат эшләре буенча Казан вакытлы комитетына конкрет тәкъдим белән мөрәҗәгать итәләр: *«... не будет ли Вами признана (необходимость) о привлечении авторов и издателей к ответственности Судебным парламентом и на брошюры наложить арест?»*[13]

Матбугат эшләре буенча Казан вакытлы комитетының 1911 елның 13 ноябрендәге утырышында Катановтан «Дүртенче дәфтәр»дәге шигырьләрнең ике данәдә тәрҗемәсен һәм аларга конкрет нәтиҗә – «заключение» язуны таләп итәләр[14]. 1911 елның 18 ноябрендә Катанов яза ул «заключение»не: *«Представляя при сем 4-ю тетрадь «Стихотворений Абдуллы Тукаева» на тат. языке, напечатанную в 1907 г. в г. Казани в электротипографии Шарафа на счет книжного магазина — «Стихотворения» и содержащую в себе 56 страниц... в 2 экз.... русский перевод 6-ти стихотворений, помещенных в брошюре на с 7-8, 23-24, 24-26, 30-32, 38-39 и 41-46, имею честь обратиться в Комитет с покорнейшей просьбой, не найдете ли нужным наложить арест на основании переведенных мною мест, встречающихся в арестуемых рукописях»*[15]. Бу «заключение»дә игътибарны җәлеп иткән нәрсә шул: биредә автор турында бер сүз дә юк, сүз бары тик инде күптән сатылып беткән китапка арест салу турында гына бара.

1911 елның 26 ноябрендә Матбугат эшләре буенча Казан вакытлы комитеты рәисе Казан суд палатасына язган отношениесендә болай ди: *«Комитет, рассмотрев брошюру на тат. языке «Стихотворения Абдуллы Тукаева», отпечатанную в 1907 г. в Казани в электротипографии Шарафа, обнаружил в некоторых стихотворениях признаки преступлений, предусматриваемых уголовными законами...» Во 2-м стихотворении «Не уйдем» («Китмибез») встречаются следующие слова: «Негодные позвали нас на неподходящее дело, говоря: Здесь нет вам воли, уходите в землю султана. Мы не уйдем – дело там для нас труднее здешнего, если здесь 10 шпионов, то там их – 15. Как и здесь, там есть казачьи войска, нагайки... Там есть казнокрады, ей-Богу, есть «ей-Богу и отнимающие у мужика последний кусок». При сравнении общественного строя России и Турции указывается, что в России только и есть что шпионы, нагайки и люди, отнимающие у мужика последний кусок. Указание на эти именно стороны общественного строя имеют целью вызвать в нем враждебного отношения... Ввиду этого комитет находит в этом стихотворении признаки преступления, предусма-*

---

[10] Шунда ук. 17 б.
[11] Шунда ук. 18 б.
[12] ТРМА. 199 ф., 2 тасв., 19 б.
[13] Шунда ук. 20 б.
[14] Шунда ук. 420 ф., 1 тасв., 179 эш, 15-16 б.б.
[15] Шунда ук. 179 эш, 143 б.

*триваемого 1037 ст., 3 п. Уложения о наказаниях... В 4-м стихотворении под заглавием «Относительно свободы» («Хөррият хакында») говорится о результатах достигнутый свободы: прекратились цензура, рабство, стеснение и унижение, сняты оковы и т. д. Далее указываются те средства, которыми добыта свобода. Умерло много молодых людей, и трупами наполнился мир, имена их остались навеки вплоть до всеобщего воскресения. Шагирды и студенты, вы этих львов не забывайте...» Ввиду того, что под молодыми людьми, умершими за свободу, деятельность которых так восхваляется и ставится в пример шагирдам и студентам, подразумеваются революционеры и восхваляется их кровавая борьба, то в этих стихах комитет усматривает возбуждение к ниспровержению существующего строя (129 ст. 2 п. Уголовного Уложения)...*

*В 5-м стихотворении под названием «Тавыш» («Голос». – Сүз 1907 елда Казанда Г. Исхакый чыгарган газета турында бара. – Л.Г.) говорится о плохом положении рабочего класса, в конце же указываются средства, как изменить это положение. Там говорится: «Подавайте рабочий народ, голос через «Тавыш»... братья рабочие, нужна борьба, нужна борьба... Светлое дело — бороться из-за права...» Ввиду того, что в этих стихах прямой призыв рабочих к борьбе, комитет находит здесь признаки преступления, проследуемого 129 ст. 6 п. Уголовного Уложения.*

*В 6-м стихотворении «Что говорят шагирды, вышедшие из медресе?» («Мәдрәсәдән чыккан шәкертләр ни диләр?») говорится: «Каких только презрений и каких только унижений мы не испытали от этой нации. Она... глумилась над нами несчастными точно над болезнью, мешающей ее глазам». Ввиду того, что под нацией, от которой татары терпели так много, могут быть или старометодисты — татары или русские, то подобное положение этого вопроса клонится к возбуждению вражды одной части населения против другой, что предусматривается в п. 6. 129 ст. Уголовного Уложения. Ввиду всего вышеизложенного Казанский временный комитет по делам печати имеет честь покорнейше просить Ваше превосходительство, во-первых, внести на уважение суда об утверждении ареста на означенную брошюру, и, во-вторых, о привлечении к судебной ответственности по указанным статьям закона автора брошюры Абдуллу Тукаева. При сем прилагается 1 экземпляр брошюры Тукаева и перевод инкриминируемых стихотворений, выполненный членом комитета Н.Катановым»*[16]. Күренгәнчә, цензура башлыгы Пинегин, Катановның «Дүртенче дәфтәр»гә арест салу турындагы «заключение»сенә өстәп, китапның авторын суд җаваплылыгына тарту турындагы үтенечен дә язып куя.

1911 елның 28 ноябрендә Матбугат эшләре буенча Казан вакытлы комитеты Санкт-Петербургтагы Матбугат эшләре буенча баш идарәгә (цензурага) җыентыкка арест салу һәм авторын хөкемгә тарту турындагы тәкъдимне хәбәр итә[17]. 1911 елның 30 ноябрендә исә Казан жандарм идарәсе дә Матбугат эшләре буенча Казан вакытлы комитетыннан китапка арест салу һәм Тукайны суд җаваплылыгына тарту турындагы зарыгып көтелгән тәкъдимне зур канәгатьләнү белән кабул итә[18].

Әмма 1911 елның 16 декабрендә Казан суд палатасы прокуроры Матбугат эшләре буенча Казан вакытлы комитетына мондый хәбәр җибәрә: *«Имею честь уведомить, что Судебная палата не согласилась с мнением Комитета, выраженном в отношении от 26 ноября с. г. ... и не утвердила ареста на брошюру «Стихотворения Абдуллы Тукаева», ввиду отсутствия в ней признаков преступления, предусмотренного Уголовным законом»*[19].

---

[16] ТРМА. 420 ф., 1 тасв., 179 эш, 171 б.
[17] Шунда ук. 199 ф., 2 тасв., 1237 эш, 22 б.
[18] ТРМА. 420 ф., 1 тасв., 179 эш, 172 б.
[19] Шунда ук. 1237 эш, 30 б.

Шулай итеп, Тукайның «Дүртенче дәфтәр»е буенча кузгатылган эш ябыла.

Ләкин «Дүртенче дәфтәр» авторы өстендәге кара болытлар таралмый тора әле. Биредә бер документны – Әхмәдуллинның Казан жандарм идарәсе башлыгы Калинин исеменә (әйтеп яздырылган) распискасын китерик: «*1911 елның 25 маенда тентү вакытында миннән алынган материалларның, 6 брошюрадан башкасын, барысын да кабул итеп алдым. 6 брошюраның икесе җинаятьчел эчтәлекле, дүртесе тенденциоз характерда булып чыкты һәм бу брошюралар хәзерге вакытта Казан шәһәренең икенче участогында округ суд палатасы тикшерүчесе кулында калды. 3 гыйнвар, 1912 ел*». Шулай итеп, Жандарм идарәсендә Казан суд палатасының «Дүртенче дәфтәр»гә арестны расламау турындагы отношениесенә хәтта 1912 елның гыйнварында да ышанмыйлар әле.

Әгәр Суд палатасы «Җинаятьләр турындагы законнар» һәм «Җәзалар турындагы законнар» җыелмаларындагы жандармерия тәкъдим иткән, цензура билгеләгән статьяларны раслаган булса, Тукайны нинди җәза көткән булыр иде? 129 нчы статья шактый киң шартларны эченә ала. Мәсәлән, Тукайга тагылган «Матбугат аша халыкны яшәп килүче стройны җимерергә өндәү» дигән статьяга өстәмәләр бар: «Җинаять кылган затның гаебе һәм шул гаебе өчен аны нинди җәзага тарту түбәндәге билгеләр буенча ачыклана: 1) җинаятьченең гамәлләре алдан уйлап, усал ният белән башкарылганмы; 2) ул зат нинди сословиедән, белем дәрәҗәсе; 3) күпме кешене шул җинаятькә тарткан һ.б. Барлыгы 10 шарт. Статьяга өстәмә итеп суд кайсы шартны сайлый, җинаятьчене шуңа туры килгән җәза көтә. Бу җәзалар: йә сигез ел каторга, йә сөргенгә җибәрү, йә штраф, йә төрмәгә утырту.

129 нчы статья буенча гаепләнгән Тукай «китабы белән күпме кешене хөкүмәткә каршы котырткан» булуына карап җәзасын алыр иде. Китап, әлбәттә, бик күп кешене «котырта». Шуңа күрә, әгәр дә Суд палатасында Тукайны гаепләү буенча цензураның, жандармериянең азартын алсалар, Тукайны иң зур җәза көткән булыр иде. Бу урында шунысына да игътибар итәргә кирәк: Тукайны каты җәзага тартырга омтылуның сәбәпләре тирәндәрәк ята. Әлеге «Дүртенче дәфтәр» бер сылтау гына булып тора. Тукайның прогрессив татар яшьләренең иң авторитетлы кумиры булуы, революционерлар белән дуслыгы, бөтен эшчәнлеге — жандармнарны сагайтып тора. Бу куркыныч инородец шагыйрьне изоляцияләү хәерлерәк... Тукай артыннан да бит Х.Ямашев артыннан күзәткән кебек күзәтү оештырылган. Аның һәр адымы турында «Житель» кушаматлы охранка агенты жандармериягә җиткереп торган. Бу турыда документлар сөйли. Мәсәлән, 1912 елның 31 июлендә Казан жандарм идарәсе начальнигының Саратовтагы жандарм идарәсе начальнигына җибәргән хатында болай диелә: «*Татарский литературный кружок (см. выписку 1911 г. за 719, 876 и 997) 26 сего июля собрался в доме Хасанова на Евангелистовской улице. Собрание решило в недалеком будущем начать издание литературно-политического журнала в объеме толстых русских журналов, причем журнал этот явится объединяющим звеном для молодых татар. На собрании по этому поводу принимали участие братья Гарай и Бари Хасановы, Абдулла Тукаев, Фатих Амирханов, учитель Гафур Кулахметов... Часть поименованных здесь лиц управлению известны; наблюдение за ними продолжается*»[20].

Хәтта үлеменнән соң да Тукай исеме жандармнарны өркетеп торган. Агентлар Тукайны күмү барышын күзәтеп, охранкага хәбәр итеп торганнар. Агент «Житель»нең 1913 елның 6 апрелендә язган доносында болай диелә: «*Казанда барлык татар яшьләре вафат булган шагыйрь Габдулла Тукаевны күмү мәрасимендә катнашты.*

[20] ОСОДА. 51 ф., 1 тасв., 44 эш, 59 б.

*Бүген «Сабах», «Гасыр», «Мәгариф», «Шәрәф һәм К.» кибетләре ябылды... Бөтен мәдрәсәләрдә укулар туктатылды...»* Ары таба агент Тукайны күмү мәрасимен оештырган һәм чыгыш ясаган кешеләрнең исемнәрен атый[21]. 12 апрельдә шул ук агент Тукай истәлегенә стипендия булдыру өчен иганә җыючыларның исемлеген язып бирә: Шиһап Ахмеров («Сабах» нәшрияты), Вәли Әхмәдуллин («Сабах»), Алиш Мостафин («Мәгариф»), Гәрәй Хәсәнов («Гасыр»), Әхмәт Урманчеев («Юл» нәшрияты), Гыйльметдин Шәрәф (бакалея кибете). *«Губернатор иганәне ачыктан-ачык җыярга рөхсәт итмәячәген аңлап, бу эшне бик яшерен алып баралар»*[22], – ди агент.

Хәтта Тукайны күмү мәрасимендә катнашу да гаепләү акты булып саналган. 1915 елда Казан жандарм идарәсендә «Мөселман съездлары», империянең татар халкы арасында милләтчелек идеяләрен таратучы, мөселманнар арасында хөкүмәтнең эшчәнлеге хакында ялган хәбәрләр таратучы кешеләр турында» «Эш»[23] ачыла. Шундый «милләтче»ләрнең берсе итеп Фәхрелислам Агеев күрсәтелә. Жандармерия документларында аның бу өлкәдә кылган гамәлләре санап кителә. Шулардан берсе – 1913 елның 4 апрелендә татар шагыйре Габдулла Тукайны күмү мәрасимендә катнашкан һәм мөселманнарның милли хисләрен кузгата торган чыгыш ясаган[24].

Тукай үзе өстендә зур куркыныч барлыгын, эзәрлекләүләрен белгәнме соң? Бу урында профессор Клячкинның сүзләрен укыйк: *«1912 елның ахырында миңа, авырып калган Тукайны барып карарга үтенеп, татар яшьләреннән берничә кеше килде. Исемдә калганча, Тукай ул вакытта Московский урамда номерларда тора иде. Мин анда, авыр неврастения күренешләре белән бергә, җитди авыру таптым. Иптәшләре аның мондый нервный хәлдә булуын буржуаз язучылардан кайберләренең һәм полиция агентларының эзәрлекләүләреннән килеп чыккан даими борчылулар аркасында булган, дип уйлыйлар иде»*[25]. Бу сүзләрдә җавап та бар. Тукай охранканың эзәрлекләүләрен белгән һәм моны бик авыр кичергән. Иптәшләре аңа Казаннан китеп торырга киңәш бирә. Һәм хәлсезләнгән, бетерешкән Тукай 1912 елның ахырында әнисенең туган авылы Өчилегә китә. Анда аны чанадан күтәреп алалар. Өчиледә әти бер, әни башка булган туганы Кәшфелкәбир өендә Тукай өч ай яши. Туганнарына үзенең монда икәнлеген беркемгә дә әйтмәскә куша, Казанга Әхмәт Урманчеевка, Галимҗан Шәрәфкә язган хатларында адресын беркемгә дә бирмәүләрен үтенә. Ул, бәлки, килеп кулга алырлар, дип тә курыккандыр.

Тукайны төрмәгә утырту – аны үлемгә хөкем итү булыр иде. Чөнки бу вакытта авыру шагыйрьнең нибары 1 ел да 4 ай гомере калган. Донослар, эзәрлекләүләр аның авыруын көчәйтә, гомерен кыскарта.

Казан суд палатасының «Дүртенче дәфтәр»гә арест салуны һәм авторын суд җаваплылыгына тартуны расламавы турындагы карарына кабаттан кайтып карасак, шундый сорау туа: ул чорда Казан суд палатасында кемнәр булган? Шагыйрь өстендә торган дәһшәтле «кылычны» – озак вакытлар төрле инстанцияләрдә бик тырышып, «нигезләп», җентекләп әзерләнгән җәза кылычын алып ташлар өчен бик көчле кул кирәк булган. Кем кулы бу? Бернәрсә ачык: Тукай өстендә нинди гайрәт белән кара болытлар куерган булса, аннан да зуррак көч белән шагыйрьне охранка җәзасыннан яклау оештырылган.

Әлегә Казан суд палатасы ишеге төбендә калабыз. Алда безне эзләнүләр, тикшеренүләр көтә.

---

[21] ТРМА. 199 ф., 1 тасв., 24257 эш, 204 б.
[22] Шунда ук.
[23] Шунда ук. 31–32 б.б.
[24] ТРМА. 199 ф., 1 тасв., 2248 эш, 32 б.
[25] «Казан утлары» . 1966, № 7, 129 б.

***

Моннан 33 ел элек абыем Рашат Гайнанов белән бергә, ул – төзүче, мин – аның ярдәмчесе сыйфатында, ниһаять, Тукайның биштомлыгын әзерләп бетердек. Шул вакыт Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының без эшли торган әдәбият бүлеге мөдире Н.Г.Юзиев миңа Тукайның кыскача тормыш һәм иҗат хроникасын язарга тәкъдим итте. «Әле генә Тукай буенча эшегез тәмамланды, бәлки ул хрониканы язу сезнең өчен бик авыр булмас, «Казан утлары»на ул бик тиз кирәк», – диде. Мин, бик теләп, бу эшкә тотындым. Ләкин Тукайны эзәрлекләү чорына килеп җиткәч, терәлеп калдым. Эш шунда: елъязма – бик конкрет жанр. Ул фараз итүләрне яратмый. Елъязмадагы һәр хәбәрне мин чыганак белән расларга тиешмен.

Мәсәлән, 1911 елда жандармнар Тукайны 1907 елда басылып чыккан «Дүртенче дәфтәр»е өчен эзәрлеклиләр. Ни өчен? 4 ел эчендә шагыйрьнең башка китаплары да чыккан бит. И.З.Нуруллин болай аңлата: *«...нәкъ шул китап турында 1908 елда агент «Персий» донос яза. Ләкин үз вакытында эш ни өчендер тукталып кала. Бу эш, күрәсең, Иж-Бубый авылындагы вакыйгаларга бәйләнешле рәвештә калкып чыга».* Мин галимнең мондый фаразларын чыганак итеп күрсәтә алмадым. Р.И.Нафигов та жандармериянең бу гамәленең сәбәбен ачык күрсәтми. Шуңа күрә, вакыт бик кысса да, Татарстан дәүләт архивындагы жандармерия документларына чумарга туры килде. Һәм әлегә беркем тарафыннан тасвирланмаган университет типографиясе хезмәткәре Вәли Әхмәдуллин турында зур гына «эш» килеп чыкты.

Жандармнарның 1907 елда басылып чыккан китап өчен Тукайны 1911 елда эзәрлекләүләренең сәбәпләрен ачу нәкъ шул «эш»тән башланды. Вакыйгаларның ничек барышы турында бу мәкаләнең беренче өлешендә язылды. Ә кыскача «Тукайның тормыш һәм иҗат хроникасы» «Казан утлары»ның 1986 елгы 4 санында басылып чыкты.

Игътибарлы укучы күрә килгәндер, Тукайның «Дүртенче дәфтәр»е буенча тикшерү барышында цензор буларак та, Тукай шигырьләренең тәрҗемәчесе буларак та зур роль уйнаган Катанов шагыйрьгә тигән һөҗүмнәрне бик саклык белән генә азайтырга, йомшартырга тырыша. «Дүртенче дәфтәр»нең беренче басмасы (1907) турында агент «Персий»нең доносын искә төшерик. Ул вакытта донос буенча бер чара да күрелми. (Ә бит 1907 елда да реакция котырына). Китап тыелмый һәм икенче басмасына юл ачык. Цензор Катанов икенче басмадан бары тик доноста күрсәтелгән «Китмибез!» һәм «Хөррият хакында» шигырьләрен генә төшереп калдыра. Әйтергә кирәк, бу юлы четерекле мәсьәлә аз гына «ташлама» белән хәл ителә. Ә 1911 елда шул ук җыентык буенча чын бер сугыш башлангач, Катанов жандармнар өчен китаптагы шигырьләрне тәрҗемә итү белән генә чикләнә. Ләкин Казан вакытлы матбугат комитеты (цензура) җитәкчелеге аңардан бәяләмә – «заключение» язуын да таләп итә. Һәм Катанов «заключение»не язарга мәҗбүр була. («Заключение» текстта курсив белән басылган). Бу «заключение»дә сүз җыентыкка арест салу турында гына бара. Соңыннан Матбугат эшләре буенча Казан вакытлы комитеты җитәкчелеге «заключение»не киңәйтә» — жандармерия тәкъдимен — Тукайны суд җаваплылыгына тарту турында өстәмә яза.

Кызганыч, әлеге «заключение» Катанов өчен хәтәр роль уйный. Совет чорында һәр елны Тукай көннәрендә республиканың дәүләт архивында, төпләмәдән Катановның шул «заключение»сен алып, архив коридорындагы стендка элеп куялар иде. Нигә элмәскә? Документ бер бит кәгазьдә генә, матур, ачык язулы, Н.Катанов дип имза куелган. Ә Матбугат эшләре буенча Казан вакытлы комитетының башлыгы М.Пинегин язган документлар бик озын, стендка куярга җайсыз...

Архивка килүчеләр «заключение»не күчереп алалар, төрле гәзит-журналларда, китапларда чыгаралар. Катановны, цензор буларак, жандармнарга Тукайны эзәрлекләргә булышкан, дип гаеплиләр. Хәтта дистә еллар үткәч тә, Катановның «заключение»сен онытмыйлар. Мәсәлән, аның турында менә нәрсә язалар: *«Төрки телләрне, әдәбиятларын өйрәнү-тикшерү эшенә зур өлеш керткән галимнәрдән берсе. Шуның белән бергә, бу галим сәяси карашлары ягыннан монархияче, шовинист миссионерлар юлын алга сөрүче. Җирле халыклар мәгарифенә, алар арасында шытып килгән прогрессив башлангычларга теләктәшлек күрсәтми. Цензурада эшләгән чагында, гомумән дә, татар язучыларының прогрессив юнәлештә язылган әсәрләренең басылуына төрле тоткарлыклар ясап килә. Гуманистик карашлы галимнәр тезмәсендә тормый»* (Әдәби сүзлек. И.Рәми, Р.Даутов. Казан, 2001).

***

Тукайны төрмәгә утыртудан кем коткарып калуын ачыкларга тырышып карыйк. Татарстанның милли архивында «Казанская судебная палата (1900-1917)» дип исемләнгән документ җыелмасы бар[26]. Казан суд палатасы 1887 елның 8 ноябрендә оештырыла. Казан, Вятка, Екатеринбург, Самара, Сембер, Уфа, Пермь губерналары округ судлары караган эшләр буенча аппеляция инстанциясе булып тора. Беренче инстанция сыйфатында иң куркыныч дәүләт җинаятьләрен дә карый. Казан суд палатасы 1917 елның 24 ноябрендә Суд декреты белән ябыла. Казан суд палатасында кемнәр эшләгән соң? Санап китик: Суд палатасы департаменты рәисе Л.С.Дравет – 1908-1917. Әгъзалар һәм кандидатлар: Топорпогрицкий – 1908-1911, Ю.Л.Лейх Спринг – 1909-1911, Б.Д.Сперанский, Н.С.Покровский, В.А.Богородицкий – 1910-1917, Н.Н.Краузе – 1911-1917, А.В.Фон Бранке – 1910-1914, И.И.Киргицель – 1913, И.И.Зедерштедт – 1913-1914, А.И.Шафир – 1913-1916, С.С.Дроздовский, Н.Ф.Дмитриев, К.П.Вишневский, Васильев, Дружинин, Архипов һ.б. (Мин караган документларда ник бер татар фамилиясе очрасын! Ә югарыда исемнәре аталган әфәнделәрнең Тукай шигырьләрен белүләре шикле).

Шунысы кызык, бу коллегиядә өлкән кандидат сыйфатында Василий Алексеевич Богородицкий (1857-1941) да хезмәт итә. Казан университетында ул тел, фонетика өлкәсендә эшли. Күп кенә хезмәтләре арасында аның «Введение в татарское языкознание в сравнении с другими тюркскими языками» (1934) дигән китабы да бар. Бу хезмәт югары уку йортларының филология факультетларында бүген дә өйрәнелә.

Ә иң кызыгы, Богородицкий Казан университетында, Россиядә беренче булып, эксперименталь-фонетик лаборатория төзегән. Катанов та шунда эшләгән. Безнең Тукай да шунда йөргән! Бу турыда Башкортстанның халык артисты композитор Л.Эйхенвальд яза: *«1911 елларда Н.Ф.Катанов белән бергә университетның эксперименталь-фонетика кабинетында эшләгәндә Тукай белән еш кына очраша идек»*[27]. Беренче очрашуда ук Тукайны композиторның «халык җырларын гармонизацияләү» буенча эшләве кызыксындырган. Катанов та, Богородицкий да Тукай белән менә кайда очрашкан булырга мөмкин.

Шунысына игътибар итик, Катанов Казан суд палатасында эксперт комиссиясе әгъзасы да булып торган. Укымышлы, киң эрудицияле профессорның коллегиядә абруе зур булган, әлбәттә. Андагылар өчен, бигрәк тә татар китаплары турында булган эшләрдә, төп эксперт булган, аның сүзләренә колак салганнар, аңа ышанганнар.

[26] ТРМА. 51 ф., 7 тасв.

[27] «Красная Башкирия». 1946, 27 апрель

Тукайга кагылышлы эшләрне исә ул яхшырак белгәнгә, бу мәсьәләдә аның фикеренә таянганнар. (Шунысын да искәртик, 1909, 1910 елларда гына да Тукайның 15 китабы басылып чыккан. Аларның барысының да диярлек цензоры Катанов. Бары тик 1909 елда (12 ноябрь) басылган «Исемдә калганнар»ның гына цензоры Н.Ашмарин була.) Катанов Суд палатасы әгъзаларын Тукайның талантлы шагыйрь булуына, аның шигырьләрендә хөкүмәткә каршы һичнәрсә булмавына, аның бары тик үз халкының тугрылыклы улы булуына ышандыра алган. Ахыр чиктә, аның җитди авыруын да әйтеп, Суд палатасының Тукай өстенә төшкән гаепләрне расламавына ирешкән. Тукайны яклаганда Катановка Богородицкий да теләктәшлек күрсәткән булырга мөмкин.

Шулай итеп, Тукайны охранка җәзасыннан, төрмәгә утыртылудан профессор Н.Ф.Катанов коткарып калган, дияргә тулы нигезебез бар. Янында талантын бәяли белүче цензор Катанов тормаса, Тукайның язмышы ни белән бетәр иде, билгесез.

Кызганыч ки, Тукайның Татарстандагы бер музеенда да әлеге «4 нче дәфтәр» шигырьләр җыентыгы (1907) куелмаган. Архив документлары да юк. Экскурсовод, иң күбе, Тукайны эзәрлекләгәннәр, дип кенә китә. Әйтерсең лә Тукайның котын алып торган ул еллар булмаган... Хәтта Тукайның Казандагы төп музеенда да шагыйрьнең бу чор тормышы турында начар беләләр. Фәнни эш алып барылмый, архив материаллары өйрәнелми, хәтта моннан 30 ел элек үк басылып чыккан «әзер» материаллар белән дә кызыксыну юк. Музей каршында фән докторлары җитәкләгән гыйльми совет эшләп торды. Әмма экспозицияне һәр яңартканда да Тукайны эзәрлекләү еллары онытылып килде.

2012 елда Татарстан милли музее татар, рус, инглиз телләрендә «Ядкярләрдә – Тукай рухы» исемле каталог бастырып чыгарды. «Каталог шагыйрьнең Татарстан милли музеенда тупланган шәхси ядкәрләре, үзе исән чакта басылган китаплары, фотосурәтләре һәм фотооткрыткаларының төп нөсхәләре мемориаль коллекциясен тәшкил итә». Кызганыч ки, эчтәлеге белән бик бай булган каталогта да Тукайның әлеге «4 нче дәфтәр» шигырьләр җыентыгын (1907) күрмибез. Гыйльми совет бу очракта да каталогны төзүчеләргә ярдәм итә алмаган...

***

Берничә ел ябылып торганнан соң, ниһаять, инде төзекләндерелгән мәһабәт Тукай музее 2018 елның 30 августында ишекләрен кабат ачты. Яңартылган экспозициядә безнең язманың темасына кагылышлы материаллар белән кызыксынабыз. Һәм ни күрәбез: бер почмакка Катановның әлеге дә баягы «мәңгелек» «заключение»се эленгән. Ә шул «заключение»гә сәбәпче булган «4 нче дәфтәр» шигырьләр җыентыгы (1907) экспозициядән тагын төшеп калган. Моны ничек бәяләргә? «Без белмәгән нәрсә дөрес түгел!» дип инанудан киләме бу хәл? Аңлашылмый.

Музейда Тукайның бер үк портретын берничә урынга элеп куюга караганда, гомеренең соңгы елларында тормышын агулап торган вакыйгаларга сәбәпче булган шул атаклы «4 нче дәфтәр» шигырьләр җыентыгын (1907) куеп, этикеткага кыскача тарихын язып, янәшәсенә эзәрлекләү турындагы документлардан иң характерлы берничәсен урнаштырып, тамашачыларга сөйләр өчен кимендә бер сәгатьлек махсус экскурсия тексты әзерләү отышлырак булыр иде. Музейга килүчеләр Тукай тормышындагы фаҗигале вакыйгалар турында да мәгълүмат алып китәргә тиеш.

Тукайның гомере бик кыска була. Ул бит әйтә: «*Минем һәр минутым бөтен дөнья бәһасенә тора*»,— ди. Без Тукайның шул кыска гомеренең һәр мизгелен ачыкларга, өйрәнергә, яктыртырга тиешбез. ■

# Татарлар Грузияне дә коткарган

Мәмлүк бәй

Бу факт турында автор беренче мәртәбә Төньяк Кавказда узган гасырның 90 нчы елларында чыккан «Кыпшак ае» – «Половецкая луна» журналында укыды.

Билгеле ки, КЫПЧАКлар – һуннардан (гуннардан) соң калган борынгы төрки халык.

Европадан килгән миссионерлар аларны «куман», «коман» дип атыйлар.

Европа монахлары төзегән Коман сүзлегендә бик күп төрки-татар сүзләрен таба алабыз.

Хәзер кыпчак халкы юк кебек, әмма ул башка халыкларга кушылган – Казан һәм Кырым татарлары, кумык, азәрбайҗан, карачай, нугай, казакъ, каракалпак, төрек, хәтта урыс һәм грузин халыкларына да.

Хәзерге Грузиядә бу тарихи фактны онытырга тырышалар, ә бит кыпчак-татарлар Грузияне дә коткарганнар иде.

Грузия вә Абхазия патшасы Давид IV Төзүче, төрек-сәлҗүкләрдән котылыр өчен, кыпчакларны, ягъни половецларны Гөрҗестанның БОРЧАЛЫ төбәгенә чакырган.

Карло Буззоло «Татарлар далада»




Татар яугире

Хәзерге тарихчыларның хисаплавы буенча, гаскәр саны илле меңгә җитә, шуңа күрә, гаиләләр белән санаганда, иң аз дигәндә дә 200000 кыпчак килеп чыга...

Шул ук вакытта Давид патша кыпчакларның Атрак хан кызына өйләнә.

Туганлашкан Давид патшага кыпчак-татарлар сәлҗүкләрне һәм фарсы-иранлыларны җиңәргә булышканнар. Бу турыдагы хәбәр «Картлис Цховреба» дигән борынгы грузин китабында сакланган. Кыпчакларның күбесе, сугышлардан соң Грузиядә калып, христиан диненә күчкән. Дәлил буларак, грузин телендә күп кенә төрки-татар сүзләре табарга мөмкин.

***Айрат Галимҗанов,***

*тюрколог, Чуашстан Республикасы Язучылар берлеге әгъзасы* ■

# ГАЛИМНЕҢ ИКЕ ҖИҢҮЕ

*2018 елның декабрендә Казанда күренекле галим, филология фәннәре докторы, Россия гуманитар фәннәр академиясе академигы якташым Марсель Бакировның 85 яшьлек юбилеенда катнашырга туры килде. Бик күп галим-голәмәләр, әдипләр белән аралашканда аның турында мифлар да туа башлаганын ишеттем. Аларның берсенә үземнең турыдан-туры катнашым, шаһит булуым сәбәпле, аны бөтен төгәллеге белән язып калдырмакчы булам. Бу эшкә мине галимнең костюм итәгенә ябышып булса да тарихта калырга омтылышым да сәбәпче булуын сездән яшерергә кирәк дип санамыйм. Дөнья күгендә һәркем үзенчә йолдыз булып янса да, янәшәңдәге зуррак йолдыз белән якын икәнлегеңне сиздерүнең файдадан башка зыяны тимәс, әлбәттә.*

Марсель Бакиров Мөслимдә туып үскән, сөйләп бетерә алмаслык мохтаҗлыклар, ятимлек кичереп, белем алып, фән тавының иң биек баскычларына күтәрелгән шәхес буларак барыбыз тарафыннан да хөрмәт ителә. Ул, елга бер мәртәбә булса да, аеруча Сабан туе көннәрен туры китереп, Мөслимгә кайтырга тырыша. Марсель абый былтыр да төянеп, күчтәнәчләр тутырылган олы сумкаларын күтәреп безгә кайтып төште. Аның кайтуын олы галимнең үзебезгә күрсәткән мөрәвәте дип саныйбыз һәм куанып каршы алабыз. Бу инде байтак еллар шулай кабатлана һәм безнең очрашулар чын бәйрәмгә әверелә. Марсель абый талымсыз: тегесе ярамый, бусы ярамый, дип борчымый, нәкъ үзебез кебек ашый-эчә, ял итә, йоклый һәм тора. Олы яшьтәге кешеләрне көйләү кайчакта түзеп булмаслыкка әйләнгәнен дә беләбез. Аларның бу ризык йә ашказанына зыянлы, тегесе аллергия бирә, өченчесе гомумән ярамый. Бу сүзләрне өлкәннәрне гаепләүдән әйтмим, үзебез дә олы яшьтә. Бик җайсыз хәл инде бу. Менә Марсель абый, ышансагыз – ышаныгыз, ышанмасагыз, юк – өлкәннәрнең андый гадәтләреннән азат булган бәхетле кеше. Кичтән ничек ятса, иртәнгә кадәр кымшанмыйча йоклап, сикереп тора торганнардан. Тарих өчен бу кирәк булырмы-юкмы – белмим, әмма райондашымның бу сыйфатын язмый кала алмадым.

Кыскасы, иртәгә авылларда Сабан туе, дип халыкның йөрәге җилкенгән көн. Без инде бу халәтне кунагыбыз белән бергә элекке

Марсель Бакиров (уңда) Фоат Садриев белән.

Мөҗәһит Әхмәтҗанов фотосы

елларда күп кичердек, минем туган авылым Олы Чакмак Сабан туйларында башыннан азагына кадәр катнаштык. Тик элеккеләре белән быелгысы арасында мөһим аерма гына килеп чыкты. Марсель абый авылдашларымны мәйдан уртасына чыгып бәйрәм белән котлый, үзенең истәлекләре белән уртаклаша иде. Аның әнисе 1941 елда Олы Чакмак мәктәбендә укытучы булган. Бу нәрсә аны авыл халкы белән гел якынайтып бетерде, Өлфәт Ахунов кебек туганнары да табылды, бәйрәм мәҗлесләрендә, табигать кочагында гөрләшеп утыра торган да булып киттек.

Ярар, 2018 елгы Сабан туена кучәргә дә вакыт җитмәдеме икән, дип уйлыйм. Сабан туе ул мавыктыра, сузыла торган бәйрәм булган кебек, аның турында сөйләү дә рәхәт, барлык чикләүләрне оныттыра, ахрысы. Югыйсә, әле мин М.Бакировның Олы Чакмак Сабан туендагы һәм аннан соңгы аралашулары, халыкның авызын ачтырып тыңлаткан үзе милли, үзе фәнни, үзе мәзәкләр белән бизәлгән чыгышлары хакында бик күп яза алыр идем. Каләмем кыстаса да, аек акылымны җигеп, үткән елларга нокта куеп, 2018 елга күчәм. Шушылай эшләвем шәхес буларак мине күтәрер, дигән өметтә калам.

Сабан туенда таныш-белешләр белән очрашу, авылдашлар белән күзгә-күз карап сәламләшү – ул инде иң зур мөрәвәт. Көрәшне, уеннарны карап утырганда, бервакыт кул көрәштерергә чакыра

башладылар. Марсель абый янәшәмдә кабарынкы чал чәчләрен җилфердәтеп дигәндәй утыра. Өченче ел Сабан туеннан соң Ык буенда туганы Фаил Ханов белән кул көрәштергәне келт итеп искә төште. Фаил абый кулыңны кысам, дип кысса, ике көн авыртып йөргәнен беләм. Марсель абый шуның белән кул көрәштерә башлады бит юан тирәк төбендә. Көрәштерделәр, көрәштерделәр – берсе дә ала алмады. Мин хәйран калып күзәттем боларны. Ә нишләп хәзер, Олы Чакмак Сабан туенда кул көрәштерергә чыкмаска тиеш соң ул? Мин моны акрын гына җайлап кыстарга тотындым:

– Марсель абый, синең кулың каты бит, чыгып көч сынашып кара әле, – дим.

Марсель абый көлеп баш тарткан була:

– Юк, сиксән биш яшьлек бабай кул көрәштерәмени инде, – ди.

Әмма күзеннән күреп торам, мәйданга чыгасы килә моның. Ә мин утка утынны өсти торам:

– Нинди 85 яшь! Әле сиңа декабрьдә генә тула бит ул! – дим. – Былтыр Фаил абый белән кул көрәштерүегезне күреп шаккаттым. Андый каты кул районда юк. Әйдә, чык әле, Сабан туе булгач, чын Сабан туе булсын инде. Киләсе елга әллә кайта аласың, әллә юк, – дип тагынниләрдер өстәгәч, Марсель абый мәйдан уртасына чыкты бит!

Халык шау-гөр килә, кайсы, әнә, ап-ак башлы бабай чыга, дип көлә. Шуннан ни булды, дип уйлыйсызмы? Ап-ак башлы бабаң терсәген өстәлгә куеп кулын күтәрде, аңа каршы бер әзмәвер адәм чыкты. Минем йөрәк төшеп китте, мин әйтәм, кыставым урынсыз булды, хәзер Марсель абый җиңелер дә, кәефе кырылыр, дип хафаландым. Хөкемдарлар белән янәшә мин дә җан атып торам. «Бер-ике-өч!» – дип команда бирүләре булды, Марсель абый тегенең кулын өстәлгә сылап кына куйды. Халык шаккатты! Аннан соң ул тирәгә кул көрәштерергә җыелган халык шактый сирәгәйде. Марсель абый тагын өч-дүрт ир-егетне җиңде дә куйды. Үзе, җиңүенә ышанмаган төсле, рәхәтләнеп көлә дә көлә. Шулай итеп ул кул көрәштерү буенча авыл Сабан туеның батыры булып калды һәм затлы плед белән бүләкләнде. Шундый өлкән яшьтәге кешенең җиңүе халыкны таң калдырды, барысы да гөрләтеп кул чаптылар. Бу – Марсель абыйның былтыргы беренче җиңүе иде. Үзенең 85 яшьлек юбилеен ул фән өлкәсендәге икенче зур җиңү белән каршылады. Татарстан китап нәшрияты Марсель Бакировның «Прототюрки: изначальная прародина, ранние племена и язык, история и этнокультура» дигән 464 битле китабын чыгарды. Галимнең юбилей көнендә Татарстан Мәдәният министрлыгының конференц-залында әлеге китапны тәкъдим итү булды. Галимнәр, мәдәни җәмәгатьчелек аны бөтен төрки дөньяны шаулатачак фәнни хезмәт дип бәяләде.

Галим Марсель Бакиров бүген дә физик һәм рухи яктан саусәламәт, һәр көн иҗади эштә кайный, яңа җиңүләргә омтылып яши. Аңа бетмәс-төкәнмәс уңышлар, озын гомер телисем килә.

***Фоат Садриев,***
*Татарстанның халык язучысы* ■

# Нәкыйп Каштанов: «БЕЗ – СЕРЛЕ ХАЛЫК»

Нәкыйп Каштанов исеме әдәбият сөючеләргә күптән таныш. Балалар аның төсле рәсемнәр белән бизәлеп дөнья күргән «Шәһәргә килгән аю», «Бүрекле багана», «Айгөлнең туган көне», «Кикрикле гөмбә», «Тылсымлы курай» кебек шигырьләр, әкиятләр тупланган китапларын укып кинәнсә, әдәбият сөючеләр «Күкләргә кунмый тузан», «Бөркеткә сәлам әйтегез», «Бушлыкта ут янмый» басмаларына кергән поэзия һәм проза әсәрләрен, очерк-зарисовкаларын яратып укый. Профессиясе буенча табиб-пульманолог булган язучы – үпкә авырулары буенча берничә фәнни хезмәт авторы да. Әмма тынгысыз әдип соңгы елларда тарих белән дә бик җитди кызыксына башлады. Әлбәттә, аның бу мәсьәләдә нәсел тамырларыннан – дин әһелләреннән килгән затлылык үзенекен итәдер. Алар нәселе гомер-гомергә белемгә, әдәбиятка, иҗатка омтылу белән аерылып торган. Хәзерге Чуашстан Республикасының Батыр районы

ны Кыр Бикшиге авылында гомер иткән бабалары да, аларның туган-тумачалары да имамнар булган, халыкка дини гыйлем биргән. Аның драматург, шагыйрь, публицист Фәтхи Бурнаш белән дә туганлыгы бар. Бу Нәкыйп Каштанов туплаган «Нәселебез җәүһәрләре» китабында да ачык күренә. Анда Каштановлар нәселеннән булган 21 иҗатчының әдәби әсәрләре туплап бирелгән. Нәкыйп Каштановның күптән түгел тагын бер тарихи хезмәте – «Татары – загадочный народ» дигән китабы дөнья күрде. Нәкыйп Фәсхетдин улы Каштановка шул уңайдан сораулар белән мөрәҗәгать иттек.

*– Соңгы елларда тарих белән ныклап кызыксынуыгыз нәрсәдән башланды?*

– Нәселебездә авыл тарихы белән кызыксыну зур иде. Мишәр бабаларыбызның авылга килеп урнашуы төрлечә бәян ителеп килде. Берәүләр аларны Курмыш яисә Нижгар ягыннан килгәннәр, дип әйтсә, икенчеләре төрле яктан җыелган халык, дип шәрехләде. Әйтик, өч гаиләне Пенза ягыннан күчеп килгәннәр, дип тә сөйлиләр иде. Мин аларны сеңдереп үстем. Аннары авылның өч тарихы булган икән, дигән сүзләр дә йөрде. Янәсе, авылны биш кеше килеп нигезләгән. Авылга кагылышлы риваятьләрнең берсе Мәхмүт муллада булырга тиеш, диделәр. Ул үзе Янтуганда гомер иткән, улы Вольнистан авылында яши. Мин анда үзем бардым. Чормалары китап белән тулган: аларның ниндие генә юк! Өеп куелган. Эзләдем, әмма кирәклесен таба алмадым.

Безнең әти Фәсхетдин белеме буенча агроном иде, күмәк хуҗалык рәисе һәм бригадир булып эшләде. Ул нәселебезнең һәм колхозның тарихын язып калдырды. Анда кемнең чыгышы кайсы авылдан икәнлеге барысы да теркәлгән. Әти аны миңа васыять итте. Мин ул тарихны бастырып чыгарырга уйладым һәм, аны тулыландыру ниятеннән, кайбер буыннарны архивлардан эзли башладым. Башта Ульяновск мирасханәсеннән барладым, аннары Мәскәү архивларына бардым. Казан архивында да эшләдем. Шул рәвешле мирасханәләрдә йөри торгач, нәселебез, авыл һәм авылдашлар тарихына кагылышлы шактый материал тупланды. Шулай итеп миндә, үз нәселебез тарихы гына түгел, авылдагы барча гаиләләрнең дә, хәтта мишәрләргә, гомумән, татар халкы тарихына кагылышлы мәгълүматлар җыелды. Шуннан мин, авылыбыз турындагы материалларны аерып алып, башта милләтебез турында тупланганнарын китап итеп чыгарырга булдым. Җитмәгән мәгълүматларны Татарстан Республикасы Милли китапханәсе һәм КФУның Фәнни китапханәсенең уку залларында утырып тулыландырдым.

*– Әйе, китапта татарлар һәм мишәрләр, аларның килеп чыгышы турында күп мәгълүмат бирелгән...*

– Мин үзем, мишәр буларак, татар халкының бу төркеме белән гел кызыксындым. Беркем дә мишәрләрнең кем булуларын, каян килеп чыгуларын төгәл генә аңлатып бирми иде. Алар турында маҗар да, бортас та, фин-угыр халкы дип тә әйттеләр. Архивларда мишәрләр буенча да мәгълүматларны барладым. Мишәрләр тарихы бик төгәл килеп чыкты. Архивлардагы документта алар турында «Служилые татары из Мещеры» дип язылган. Димәк, мишәрләр – Мещерадан килгән йомышлы татарлар. Аларны соңрак мещеряк, дип йөртә башлаганнар. Йомышлы татарлар да, мещеряклар да барысы да мишәр булып киткән. Бу инде, икенче яктан караганда да, мишәрләрнең шул ук татар булуын да белдерә. Әмма диалектлары, башкача әйтсәк, авазларны катырак әйтүләре белән генә аерыла. Китапта мин мишәрләр сөйләшендәге аерымлыкларны да күрсәтеп үттем.

*– Татарлар ни өчен серле халык?*

– Галимнәр Америкада яшәүче төп халыкның Байкал күле һәм Алтай таулары

тирәсеннән күчкән кешеләр икәнлеген исбатлаган инде. 25 мең ел элек күченә башлаганнар. Америка халкы үзара аралаша торган инглиз телендә төрки-татар сүзләре саклануы да моны ачык дәлилли. Миндә тупланган материаллар буенча фикерләгәндә, төрки халыкның ким дигәндә 25 мең еллык тарихы билгеле. Башка халыкларның берсенең дә шундый тирән тарихы юк. Җир йөзендә «Татар бугазы», «Татар даласы», Пермь краендагы «Татарская гора» табигать һәйкәле кебек атамалар хәттин ашкан. Татарлар Урта Азиядә дә, Гыйракта да булган. Борынгы фарсы шагыйрьләренең иҗатында татарлар телгә алына. Шагыйрь Әбү-н-Нәҗем Манучихри бик матур «төрки-татар» үсмере турында яза. Иң кызыгы да менә шунда: татарлар алар һәр тарафта да бар һәм шул ук вакытта алар беркайда да юк. Археологлар татарның бер генә сөяген дә таба алмыйлар. Заманында көчле дәүләт тотып яшәгән халыкның артефактлары да, археологик материаллары да тиешле дәрәҗәдә сакланмаган. Китапның исеме «Татары – загадочный народ» дип, шуннан алынган.

– *Китапта татар дигән халык «кұн» белән бәйләп аңлатыла...*

– Миндә Эренжен Хаара Даван дигән калмык галименең «Чингисхан – как полководец и его наследие» дигән китабы бар. Галим анда татарларны «тата-р» дигән. Кытайларда «Р» хәрефе юк. Алар да безнең халыкны «та-та», диләр. Бер кытай теле белгеченнән: «Татар дигән сүз иероглифта ничек белдерелә икән», – дип сорадым. «Аны бик төгәл тәрҗемә итеп булмый, «кұн» дигәнне аңлата, кұн белән шөгыльләнүче, аннан әйберләр җитештерүчене шулай атаганнар», – диде. Танылган тарихчы Фаяз Хуҗиннан да сораштым. Ул да «кұн» сүзенең бик борынгы гыйбарә, һуннар цивилизациясеннән үк килүен аңлатты. Болгар, болгари сүзләре дә «кұн эшкәртүче» дигән мәгънәгә ия. Моннан Болгари сүзе та-та-р дигәнне белдерә, дип нәтиҗә ясарга мөмкин.

Аннары скифларны өйрәнә башладым. Скиф сүзе дә грек телендә «кұн» мәгънәсенә ия икән. Шулай итеп татарлар кайчандыр скифлар исеме белән дә йөргән булып чыга. Тарихи мәгълүматлардан күренгәнчә, татарлар мәшһүр халык булган. «Төрки» дигән сүз дә башта шул ук татарларга гына кагылган, ул бу халыкның аристократиясен белдергән. «Төрки» сүзеннән алынган «түрә» гыйбарәсе бүген дә сөйләмебездә бар. Татарларның бер төркеме кыпчак, коман исемнәре белән дә йөргән. Кыска гына аңлатканда, алда әйтеп үткән скиф, болгар, төрки, коман-кыпчаклар – барысы да бер халык, әмма яшәгән географик урыннарына карап кына төрле исем белән йөргәннәр, сөйләмнәрендә дә беркадәр үзгәрешләр килеп чыккан.

*Әңгәмәдәш – **Сөембикә Кашапова*** ■

Безнең мирас №4 апрель 2019

# ИСЛАМ ДӨНЬЯСЫ

Габдерәшит Ибраһимов

### ШӘҺӘРНЕҢ ХӘЛ-ТОРЫШЫ

Владивосток – бик яхшы ныгытылган, порттан эчтәрәк урнашкан, таулар арасында сибелгән биек биналары һәм иркен кибетләре булган зур шәһәр. Мин бирегә килгәндә инде кыш булганга, як-якларын ап-ак кар, боз каплаган тау тезмәләре һәм табигатьнең бу гаҗәеп манзарасы Аллаһы Тәгаләнең чиксез кодрәтенә ишарә булып тоелды. Мин шәһәрне аркылыга да, буйга да гиздем, бөтен җирен күрдем. Зур урамнарының күбесе никадәр генә төзек, матур булса да, әлеге таулар арасыннан үткәндә, хәрабә хәлендә яткан ташландык җирләр дә шактый очрады. Киң урамнарда урнашкан зур кибетләрнең ишек өсләренә кайчак кытайча, кайчак русча язылган сузылып киткән кытай исемнәре – Тун-Фун-Тай, Чижан-Хун-Тун-Шин-Тай, Тун-Шин-Лун һәм шуларга охшаш атамалар әледән-әле игътибарымны җәлеп итеп торды. Шул ук вакытта, япон кибетләренең ишекләренә эленгән япон хәрефләре белән язылган такталар, француз, инглиз телләрендә язылган такталар күренгән һәм ара-тирә рус кибетләре дә очраган саен, Владивосток миңа үзенә бертөрле милләтләр күргәзмәсе булып тоела башлады.

Владивосток шәһәре

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2017) санында.

Берөзлексез, һәр почмакта, сыртларындагы теге гаҗәеп кәрҗиннәре белән кореялы йөкчеләр каршыга очрап тора – бер генә мәмләкәттә дә моңа охшаш нәрсәләр күргәнем булмады. Шуның өстенә, әле тагын ишек төбе саен зур кызыл чалмалы һинд мәҗүсиләре басканнар, каравылчы вазыйфасын башкаралар. Бу күренешләр адәм баласын ирексездән төрле-төрле тирән уйларга сала.

Владивосток матди байлыгы һәм икътисады белән Кытай мәмләкәтен хәтерләтә, чөнки кая карама – төзек кибетләрдә, банкларда, сәүдә үзәкләрендә, андагы хезмәтләрдә – гел озын чәчле кытай кешеләре очрый. Кайда авыр хезмәт, йөк ташу, кара эш бар – шунда гел корея кешеләре эшли. Кореялылар бөтенләй хәерчелеккә баткан кебек күренәләр.

Мин Владивостокка килеп тора башлаганда, кытайларның яңа ел башы бәйрәмнәре әле һаман дәвам итә иде. Ефәк, ару киемнәр кигән озын чәчле кытайлар, төркем-төркем булып, урамнар буйлап күңел ачып йөриләр; һавалар шактый суык торганга, колакларын бизәкләп чигелгән янчык сыман нәрсә белән каплыйлар иде. Кытайларның гореф-гадәтләре турында тулырак мәгълүматны Кытай иле буйлап сәяхәт иткәндә язачакмын, хәзергә исә, алда сөйләгәннәрем белән чикләнәм.

### ДАРЕЛФӨНҮН – УНИВЕРСИТЕТ[1]

Владивостокта русларның Шәрык телләрен өйрәтә торган университетлары (институтлары) бар. Кайчандыр институт исеме бирелгән булса да, бүгенге көндә ул кечкенә генә бер мәктәптән гыйбарәт. Бу уку йорты ачылуның төп максаты кытай, япон, монгол телләрен өйрәтү булса да, моны тәмамлап чыккан әфәнделәр, кытай хәрефләренең ботаклары-чыбыклары турында бик яхшы сөйли алсалар да, телен һич аңламыйлар.

Бу урында хөрмәтле укучыларымның, кытай-япон телләрен үзем белмичә торып, ул әфәнделәрнең дә белмәүләрен ничек аңлый алуым турында сорыйсылары киләдер. Әйе, үзем белмим, ләкин Токиога баргач, бу уку йортын тәмамлаган ике кеше белән очрашырга туры килде. Берсе белән ике атнага якын бер бүлмәдә яшәдек, Токионы бергәләп гиздек. Мин тәрҗемәче ярдәменә никадәр мохтаҗ булсам, ул да шулкадәр үк ихтыяҗ тоя иде. Вак-төяк өчен мин дә тәрҗемәче ярдәмен кирәксенми идем, ул да.

Әфәнделәрнең икенчесе кытай теле өйрәнә һәм соңгы сыйныфта укый иде. Беркөнне мин аннан минем исемгә килгән, кытай телендә язылган бер хатны укып бирүен үтендем. Хатның эчтәлеген якынча белә идем. Бу әфәнде телне шулкадәр өйрәнеп тә, хатның эчтәлеген түгел, хәтта минем исемемне дә укып аңлый алмады.

Шулай булса да, Шәрык телләре университеты бар һәм бу да бик зур эш. Әлеге уку йортында алда әйтелеп үткән телләр өйрәтелә, монгол һәм кытай телләре белгече танылган Цыбиков[2] җәнаплары – бу университетның профессоры.

Цыбиков – бурятлар арасында киң танылган шәхес. Тибетка сәяхәт иткән. Кытай телен белә, рус телен үзлегеннән өйрәнгән, бераз хаталы булса да яза ала. Христианлыкны кабул иткән өчен

---

[1] Владивостокта 1899 нчы елда ачылган Көнчыгыш телләр институты турында сүз бара. Институт эшчәнлеген 1918 нче елга кадәр дәвам итә, 1920 нче елда исә, шул елда оешкан Ерак Көнчыгыш дәүләт университетына кертелә (тәрҗ. иск.).

[2] Әсәрдә гарәп хәрефләре белән Сибоков рәвешендә язылган бу исем Цыбиков булырга тиеш. Владивостоктагы Көнчыгыш телләр институты тарихына багышланган хезмәтләрдә ул елларда институтта эшләгән кешеләр арасында Сибоков фамилиясе очрамый (тәрҗ. иск.). Цыбиков Гомбожаб Цэбекович (1873-1930) – профессор, сәяхәтче, этнограф, Тибет, Монголия һәм Будда дине белгече, тәрҗемәче. Милләте буенча бурят. 1899-1902 елларда Тибетка сәяхәте вакытында беренчеләрдән булып Тибетны һәм аның башкаласын Лхасны фотога төшергән фотограф буларак та танылган (тәрҗ. иск.).



# ДОБРОВОЛЬНЫЙ ФЛОТЪ

**содержитъ срочныя пассажирскія и грузовыя сообщенія по слѣдующимъ линіямъ.**

**А. ВОСТОЧНАЯ ЛИНІЯ.**

Отъ Одессы до Владивостока и обратно съ заходомъ въ попутные порты: Константинополь, Портъ-Саидъ, Джибути, Коломбо, Сингапуръ, Гонгъ-Конгъ, Шанхай и Нагасаки. Во время паломническаго движенія пароходы заходятъ въ обоихъ направленіяхъ въ Бейрутъ и Джедду. Пассажиры по этой линіи принимаются во всѣхъ указанныхъ портахъ. Грузы же кромѣ того принимаются и со всѣхъ станцій русскихъ желѣзныхъ дорогъ—въ прямомъ Южно-Заморскомъ и Русско-Китайскомъ сообщеніяхъ.

**Б. ДАЛЬНЕВОСТОЧНЫЯ И СѢВЕРНЫЯ ЛИНІИ.**

**1) Экспрессныя:**

а) Между Владивостокомъ и Цуругой (Японія) пароходы, согласованные съ поѣздами Китайской Восточной ж. д., отходятъ изъ Владивостока 2 раза въ недѣлю.

б) Между Владивостокомъ—Нагасаки и Шанхаемъ пароходы отходятъ изъ Владивостока одинъ разъ въ недѣлю.

**2) Линія Татарскаго пролива.**

Между Владивостокомъ и Николаевскомъ на Амурѣ съ заходомъ на Сахалинъ, 16 рейсовъ въ теченіе навигаціи.

**3) Сѣверныя линіи.**

а) Между Владивостокомъ и портами Охотскаго и Берингова морей съ Апрѣля по Октябрь 18 рейсовъ.

б) Между Владивостокомъ и Нижне-Колымскомъ (Ледовитый океанъ) одинъ рейсъ въ навигацію.

Агентства Добровольнаго Флота находятся во всѣхъ портахъ, посѣщаемыхъ пароходами Добровольнаго Флота.

Подробныя свѣдѣнія можно получить: по Восточной линіи въ Агентствахъ Добровольнаго Флота въ С.-Петербургѣ (Михайловская площадь, 4-5, Телефонъ № 454—72), Москвѣ, Одессѣ и Владивостокѣ.

По Дальневосточнымъ и Сѣвернымъ линіямъ въ Агентствахъ Добровольнаго Флота въ С.-Петербургѣ и Владивостокѣ.

**ПАССАЖИРСКІЕ ТАРИФЫ**

**Каютныхъ помѣщеній.**

**(Цѣны обозначены въ рубляхъ, включая продовольствіе).**

| Отъ Одессы до | Константиноп. | П.-Саидъ | Джибути | Коломбо | Сингапуръ | Г.-Конгъ | Шанхай | Нагасаки | Владивостокъ. |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Каютн. помѣщ. . . . . | 15 | 75 | 135 | 200 | 240 | 270 | 285 | 290 | 300 |

| Отъ Владивостока до | Зал. Св. Ольги | Императорская Гавань | Пилево | Александровскъ | Де-Кастри | Николаевскъ |
|---|---|---|---|---|---|---|
| I классъ. . . . . . . | 7.75 | 23.50 | 26.75 | 28.40 | 29.15 | 33.65 |
| II классъ. . . . . . . | 4.45 | 16.10 | 18.20 | 19.25 | 19.90 | 22,75 |

| Отъ Владивостока до | Цуруга | Нагасаки | Шанхай |
|---|---|---|---|
| I классъ . . . . . . . . . | 37 | 52 | 81 |
| II классъ . . . . . . . . . | 18 | 32 | 50 |

**Плата за проѣздъ на пароходахъ Сѣверныхъ линій взимается по слѣдующему расчету:**

| | |
|---|---|
| I классъ . . . . . . . . . . . . | 3 коп. за милю и 2 р.— въ сутки продовольствіе. |
| II классъ . . . . . . . . . . . . | 2 » » » » 1 » 50 » » » |

бирелгән профессорлык әллә ни зур бүләк түгел. Руслар мондый очракларда аннан да зуррак итеп бүләкләргә мөмкиннәр. Гомумән, Русиядә укый-яза белгән бер кеше христианлыкны кабул итсә, аның өчен бирелә торган беренче дәрәҗә – профессорлык. Казанда да әнә Катанов[3] шәрык телләреннән һәр тел буенча профессор булып санала. Рус теле начар булу белән бергә, шәрык телләреннән Минусия татарлары теле белән бурят теленнән башка тел дә белми. Шулай булуга да карамастан, гарәп, фарсы, төрек телләре буенча цензор булып тора.

## ВЛАДИВОСТОКТА ЯПОНИЯ КОНСУЛЛЫГЫ

Төп максатым моннан Япониягә китү булганга, анда бару юлын, пароходларның юлга чыгу көннәрен белешер өчен Япония консуллыгына килдем. Ишектән керүгә үк игътибар иттем: монда бөтен кеше эш белән мәшгуль. Бер яшь кеше миңа ерактан ук эндәште: «Рәхим итегез! Йомышыгыз ни?» Мин, аның янына килеп: «Мин Япониягә барырга уйлыйм. Пароходларның кайсы көннәрдә, кайсы пристаньнардан китүләрен белешергә тели идем», – дидем.

– Безнең пароходыбыз бүген Цуругага китә. Бер сәгать вакыт калды. Русларның пароходлары да атнада ике көнне юлга чыга – пәнҗешәмбе һәм дүшәмбе көннәрне.

– Мин Хакодатега яки Ниигатага китәргә телим. Ул җирләрне гизеп күрәсем, өйрәнәсем килә иде.

– Аңладым. Әлегә безнең эш бик тыгыз, теләсәгез, бүген кичке якта рәхим итегез. Сезгә җентекле мәгълүмат бирермен. Рәхим итеп, адресыгызны әйтсәгез, үзем дә килә алам. Кыш көннәрендә Хакодате якларына пароход сәфәре булмый, ул яклар боз астында.

Мин, адресымны калдырып, саубуллашып китеп бардым. Аннан чыгуга, музейга кердем. Кечкенә генә музей. Кызыксыну уятырлык берни күрмәдем. Аннары халык китапханәсенең уку залына кереп, бер сәгатьләп газеталар караштырдым.

Кичке алтылар тирәсендә кунакханәгә кайттым. Чәйләп алдым. Шул арада кунакханә хезмәтчесе килеп: «Сезне күрергә дип ике әфәнде килгән», – дип хәбәр бирде. «Рәхим итсеннәр», – дидем. Шәрык кешеләренә хас мөлаем йөзле ике яшь кеше кереп, сәлам бирделәр, исемнәрен әйтеп, таныштылар.

Икесе дә Япония консуллыгында эшли икән. Танышып, бераз сөйләшкәннән соң: «Язган булса, безнең Япониядә бик яхшы сәяхәт итәрсез, бернинди дә кыенлык күрмәссез», – диделәр. Чәй тәкъдим иткән идем, кабул итмәделәр. Берсе: «Кызганыч, безнең пароходыбыз белән китә алмадыгыз. Бик канәгать булыр идек. Әмма русларның «Добровольный флот» пароходлары

[3] Катанов Николай Фёдорович (1862-1922) – төрки телләр белгече, этнограф, филология фәннәре докторы, Казан университеты профессоры; милләте буенча хакас.

Шәрык институты

да яхшы. Безнең илебезгә мөселман сәяхәтче килгәнен һич ишеткәнебез булмады. Илебездә мөселманнар да юк. Иншаллаһ, моннан соң килерләр. Сез инглизчә беләсезме?» – диде.

– Кызганыч, чит телләр белмим.

– Безнең Япониядә инглиз теле шактый киң кулланыла. Илнең бөтен җирен бу тел ярдәмендә гизәргә мөмкин. Гарәпчә беләсез инде, әлбәттә.

– Беләм.

– Алай булса, без Сезгә бер дустыбыз белән күрешергә тәкъдим итәрбез. Сириядә укып кайтты.

Шәрык холкы. Шәрык мәдәнияте. Без бу әфәнделәр белән бик тиз уртак тел таптык. Ярты сәгатьләп сөйләшеп утырганнан соң: «Безнең бүген эшебез гадәттәгедән дә күбрәк. Кайчан, нинди ярдәм кирәк булса, ярдәм итәрбез. Хәзергә рөхсәт итегез, безгә китәргә кирәк», – диделәр дә саубуллашып киттеләр. Мин болардагы тәрбиягә, мөлаемлеккә карап, шаккатып калдым. Икесе дә шулкадәр тәрбияле иделәр ки, берничә еллык танышлар кебек мөгамәлә итсәләр дә, олы хөрмәт белән, иелеп, кулларымны кыса-кыса, аерылганда: «Безгә берәр йомышыгыз булса, бик теләп башкарачакбыз», – дип тагын кабатладылар.

## КАҺВӘХАНӘЛӘР ҺӘМ КЫТАЙ ТЕАТРЫ

Мин кичен вакыт үткәрер өчен урамга чыктым. Зур урам буйлап киттем. Урамның ике ягында да кинотеатрлар, чәйханәләр, каһвәханәләр бар. Мин андый нәрсәләр белән бик кызыксынмыйм, ләкин, нишләмәк кирәк, эч пошуны басар өчен, теләр-теләмәс кенә боларның берсенә кердем. Бер ярты сәгать утырдым микән, юк микән, янымда сөйләшеп утырган ике рус кешесеннән берсенең янындагы юлдашына: «Әйдә, кытай театрына барыйк», – дигәнен ишеттем. Шулвакыт: «Күргән нәрсәм түгел, ичмасам, бер яңалык булыр», – дип уйлап алдым да, мин дә кытай театрына киттем.

Чәйханәдән чыгуга атлы арбачы ял-

лап, кытай театрына кадәр килдем. Килүен килдем, ләкин театр дип килгән җир шулкадәр пычрак иде ки, сөйләп аңлатырлык түгел. Ишектән эчкә кердем: төтен, сарымсак исе, белмим, тагын әллә нинди зәһәр ачы исләр белән тулган зал. Көч-хәл ун минутлап түзеп утыра алдым. Уеннарын да һич аңларлык түгел. Артистларының хәрәкәтләреннән, кыяфәтләреннән күренгәнчә, ихтимал, ниндидер бер тарихи вакыйганы уйныйлар иде. Миңа файдалы булырлык берни дә күрмәдем. Монда озак утырып торырлык та түгел. Аннан чыгуга, туп-туры кунакханәгә юл тоттым. Вакытны бушка үткәргәнче, китап укып үткәрергә кирәк дип таптым. Барыннан да бигрәк, мәшһүр сәяхәтче Ладыгин җәнапларының әсәрләрен укырга тели идем.

### ЗИНДАН КӨННӘРЕ ЮЛДАШЫМ БЕЛӘН ОЧРАШУ

Иртәгесе көнне иртән гадәтем буенча китапханәнең уку залына киттем. Газеталар укып утыра идем, бер кешенең миңа бик текәлеп карап торуын хис иттем. Бер-ике тапкыр мин дә аңа карап алдым, беркемгә дә охшатмадым һәм шуңа күрә эндәшмәдем. Бер ярты сәгать вакыт үткәннән соң, бу кеше яныма килеп сәлам бирде

– Гафу итегез, – диде. – Әгәр ялгышмасам, мин Сезне таныган кебек булдым.

– Мин Сезне һич хәтерләмим, ялгышасыздыр, дип уйлыйм.

– Юк, ялгышмыйм, тик исем шәрифләрегезне искә төшерә алмыйм. Рәшид булып танылган идегез, ахрысы. Ә менә йөзегез бик яхшы исемдә калган.

– Кайда күрешкән идек?

– Одесса зинданында камераларыбыз янәшә иде. Аннары тәхет варисы дөньяга килү мөнсәбәте белән амнистия игълан ителде дә шул төнне үк берничә йөз кеше иреккә чыгарылды. Тик Сезне чыгармадылар. Ишек төбегезгә килеп, Сезнең белән саубуллашканымны хәтерлим.

– Одесса төрмәсендә утырганда, уң ягымда 16 яшендә булгандырмы, юктырмы, бер яшь кыз бар иде. Сул ягымда чыгышы белән румын студент бар иде. Тик Сезне бер дә хәтерләмим.

– Менә шул румын егете мин инде. Уйлыйм, бу кешене белә бит мин, дим. Ярты сәгатьтән бирле уйланып утырам, ниһаять, искә төште.

– Бик гаҗәп! Безнең бер мәкаль бар: «Тау белән тау гына очрашмый, кеше белән кеше очраша», – диләр. Чынлап та аптырарлык, тик мин Сезнең йөзегезне искә төшерә алмыйм. Бик нык үзгәргәнсез, мөгаен. Исемегезне дә хәтерләмим.

– Шулай булмыйча соң, сезнең сакалыгыз да, әнә, ап-ак булган. Ул вакытта әле карасы күбрәк иде. Минем исемем – Харламбо. Монда килгәнгә дә инде күп булды.

– Нәрсә белән шөгыльләнәсез?

– Мин – инглиз пароходында машинист, инде инглиз булдым, дисәм дә ярый. Англия ватандашы булдым, мин инде Русия гражданины түгел, сәясәт белән шөгыльләнүне дә ташладым. Хәзерге көндә бөтен уем – акча табу. Тик менә биредә – Ерак Көнчыгышта – Сезнең белән очрашу мине бик гаҗәпләндерде, күп кенә вакыйгалар яңадан исемә төште. Бик кызганыч, Сезнең белән тагын күрешеп булмаячак, чөнки пароходыбыз бүген юлга чыга, китәбез.

Шул арада аның янына бер кеше килде, үзара ни турындадыр сөйләшеп алдылар да саубуллашып китеп бардылар. Мин дә уку залыннан чыктым, Көнчыгыш телләр институтына киттем. Юлда бик уйланып бардым, кеше белән кеше кайларда гына очрашмый?! Институтка барып җиткәнче, Одесса төрмәсендә үткәргән көннәремне башыннан ахырына кадәр хәтеремнән үткәрдем. Институтка килеп җиттем, мәшһүр сәяхәтче Цыбиков белән күрешергә теләгән идем, урынында юк

икән. Шуңа күрә кытай теле белгече Гомбо-Жаб[4] белән күрештем. Бераз сөйләшеп утырдык. Бераздан Гомбо-Жаб: «Теләсәгез, әйдәгез, бергәләп шәһәр гизәргә чыгыйк», – диде. Мин бик шатланып кабул иттем. Без бергә институттан чыктык та кытай казиносына киттек.

## КЫТАЙ КАЗИНОСЫ ҺӘМ КЫТАЙ РЕСТОРАНЫ

Кытайларның бәйрәмнән бәйрәмгә генә уйнала торган Лан-Ту дигән бер комарлы уеннары бар икән. Уен карта уенына охшаган, ләкин «карталар» кәгазьдән түгел, агачтан ясалган. Казинода кеше бик күп иде. Алты кеше уйный, калганнары, бер читкә утырып, әлеге уйнаучыларның берсенә акча белән ярдәм итәләр һәм шул рәвешле уенда катнашалар. Кешесе уенда өстен чыкса, теге кешенең дә кулына бераз акча керә, отылса – ул да оттыра. Әлбәттә, бу минем өчен һич тә таныш булмаган уен иде. Кешеләрнең бик күп булуыннан нәтиҗә чыгарып, мин:

– Бу бик көчле комарлы уен булырга тиеш. Болай булса, бу кытайлар харап булачак, – дидем.

Минем бу сүзләремә Гомбо-Жаб шул җавапны бирде:

– Кытайларның холкын европалылар белән чагыштырырга ярамый. Боларда комарлы уеннар өчен дә, уйнаучылар үзләре үк куйган кануннар бар. Бу кануннарны, полициядән бигрәк, уйнаучылар үзләре саклый. Беренче шарт: уенга катнашучы кеше җиңелчә генә дә исерек булырга тиеш түгел. Алай булган очракта, каршысындагы уйнаучы аны уенга кабул итмәскә тиеш. Әгәр кабул итеп уйнаса, полиция аңа сәрхушнең акчасын кире бирдерттереп кенә калмый, үзенә дә акчалата җәза сала.

Моннан тыш, кытайларның, мәсәлән, русларның карта белән уйнала торган «уңга-сулга» дигән уеннары кебек, бик көчле комарлы уеннары бар икән. Мондый уеннарны бары тик бәйрәмнәрдә генә уйнарга рөхсәт ителә, ә башка вакытларда гел вак-төяк уеннар гына уйнала. Кеше никадәр генә азартлы булса да, бу төр уеннарда күп акча оттырмый. Шуңа охшаш кагыйдәләр, кануннар куелган һәм бик төгәл үтәләләр. Аннан соң, бу милләттә сәрхушлек гомумән юк. Болар дучар булган бер ләгънәт төшкән авыру бар – ул да булса – әфьюн куллану[5].

Казинодан чыккач, Гомбо-Жаб белән зур кытай ресторанына бардык. Гомбо-Жаб миңа: «Бөтен Владивостокта боларның ресторханнары кебек чиста һәм арзан ресторан юк. Болар һәрвакыт икътисадны истә тотып эш итәләр. Ашау-эчүдә дә икътисад беренче урында тора, ләкин шул ук вакытта чисталыкны да күз уңында тоталар. Кытайларның пычраклыклары белән даннары чыккан булса да, ризык мәсьәләсендәге чисталыклары искиткеч», – диде.

Шулай диде дә: «Менә карагыз», – дип, мине ресторанның аш хәзерләнә торган бүлеменә алып керде. Чынлап та, һәр җирдә күзгә ташланырлык чисталык иде. Бу ресторанда бер кеше 35 тиенгә өч төрле бик тәмле ризык ашый ала икән. Рус ашханәләрендә 50 тиенгә алып ашасаң да, туймый калырга мөмкин икән.

*Төрекчәдән* ***Асия Рәхимова*** *тәрҗемәсе*

Дәвамы бар ■

[4] Биредә бер буталчыклык күзәтелә. Цыбиков белән Гомбо-Жаб икесе ике кеше итеп бирелсә дә, мәгълүматлардан күренгәнчә, Гомбо-Жаб – Цыбиковның исеме һәм аның өч төрле язылышы очрый: Гомбо-Жаб, Гомбо-жаб, Гомбожаб (Гомбожав) (тәрҗ. иск.).

[5] Болар турында Пекин сәяхәтен язганда тәфсилләп сөйләрмен (Габдерәшит Ибраһимов искәрмәсе).

# «КҮҢЕЛЕМ ҺӘРЧАК СИНЕ ЭЗЛИ, КАЙЛАРДА СИН?!»*

Мәһмәт Акиф Өзтүрк

*«Шундый яралар бар тормышта, махау авыруы шикелле әкрен-әкрен һәм ялгызлыктан ашый торган, кимерә торган яралар...»*

***Садык Һидайәт***




*«Тәммуз» (Июль) журналы, – Истанбул, 2018 ел, декабрь саны. – 65, 66 битләр. Язманың исеме төрек чәчән-җырчысы Нәшәт Әрташның «Нәрәдәсен сән? – Neredesin sen?» исемле җырыннан алынды.

*Икенче Бөтендөнья сугышы – тарихтагы иң зур сугышларның берсе. Хәтта иң зурысы, дип тә әйтә алабыз. Әлеге сугыш җәмгыятьләргә генә түгел, романнарга, шигырьләргә, кыскасы, барлык әдәби жанрларга тәэсир ясаган һәм бөтен нәрсәне үзенчә формалаштырган. Дөнья әдәбиятында Икенче Бөтендөнья сугышы турында бик күп әсәрләр иҗат ителгән. Аларның бер өлеше турыдан-туры фронттан язылып, фронтта барган вакыйгаларны, хәлләрне яктырта. Икенче өлеше тылдагыларның хәлләрен, сугышның аларга булган йогынтысын, сугышның алар тормышын ничек җимергәнен, үзе белән күп нәрсәләрне аяусыз рәвештә ничек алып киткәнен тасвирлый. Әйтик, Эриха Марри Ремерканың «Мәгърип фронтында үзгәреш юк» («На западном фронте без перемен») романы безгә сугышта барган хәлләр турында фикер йөртергә мөмкинлек бирә. Бөек әдип Чыңгыз Айтматовның «Анам кыры» әсәре – сугышның тылга йогынтысын тасвирлый торган роман. Аяз Гыйләҗевнең «Яра» повестендә «Анам кыры» төркеменә кертергә мөмкин.*

Аяз Гыйләҗев – Татарстанның һәм татар милләтенең иң зур әдибе, дип әйтә алабыз. «Яра» повесте, Фатих Кутлуның төрек теленә гаять уңышлы тәрҗемәсе белән, «Палто» нәшриятында үткән февраль аенда халыкка тәкъдим ителде. «Яра» язучының төрек теленә тәрҗемә ителгән беренче әсәре түгел. Әдипнең аңа кадәр «Өч аршын җир», «Җомга көн кич белән...» повестьлары Төркиядә басылып чыккан булса да, хәзерге вакытта, китап кибетләрендә булсын, интернет сайтларында булсын, аларны табып булмый. Сатылып беткәннәр. Әлеге ике әсәрне букинистлардан эзләп тапсаң гына! Ә «Яра» повестена килгәндә, хәзерге көндә сатуда укучыларын көтә. Форсатны кулдан ычкындырмаска кирәк.

160 битлек «Яра» әсәре ун бүлектән тора. А.Гыйләҗев повестьтагы вакыйгаларга, бүлекләргә әсәрдәге каһарманнарның исемнәрен биргән. Вакыйгаларга ул каһарманнар күзлегеннән чыгып карый. Шәкүр, Мөхәммәт, Сөләйман, Зөләйха, Зәйтүнә – болар кайбер бүлекләрнең атамалары. Автор вакыйгаларга аерым караш белдерми. Вакыйгаларны кайчак алдан башлатса да хронологияне бозмый – дәвам иттерә, әмма моны һәр бүлектә аерым каһарманар күзлегеннән тасвирлый.

Вакыйгалар Икенче Бөтендөнья сугышы чорын колачлый. Әсәр 1941-1947 елларны үз эченә ала, дип әйтә алабыз. Алмания белән сугышта, бик табигый, татар милләте дә балаларын Совет иле өчен корбан итә. Менә шуларның берсе – Югары авылда гомер сөрүче Сөләйман карт белән Зөләйханың уллары Габдулла. Габдулла сугышка киткәннән соң, әти-әнисе аңардан бернинди хәбәр ала алмыйлар. Әсәр Габдулладан хәбәр көтүче әти-әнисенең өметләнүле вә өметсезләнүле кичерешләре арасында бара. «Яра»ны укыганда төрек драма фильмын караган төсле буласың, әсәрнең исеменнән үк елмаеп укый торган түгеллеген аңлыйсың. Балалары ягыннан бик үк бәхетле булмаган бер гаиләнең өмет белән өметсезлек арасындагы рухи халәтләрен әсәрнең юлларында күзәтеп барасың. Зарыгып көтү, өметләнү, өметсезлеккә төшү, тагын өметләнү... Әлеге хисләр кичерешендә укыйсың повестьны.

Сугышка киткән солдатлар берәм-берәм кайта, ә Габдулла исә һаман да кайтмый. Сөләйман карт, бик үк гыйбадәт кылмаса да, үзе мөселман кешесе. Шулай да, ничарадан-бичара дигәндәй кайчагында борынгы мәҗүси гадәтләргә сыена. Вакыт-вакыт, үпкәләү тонында булса да, намазлыгын җәеп, Йомры таштан сорауны дәвам итә Сөләйман: *«Юк-бар ырымнарга ышанмаган гадел Сөләйман карт, ике тапкыр ялынып, Йомры ташның мәрхәмәтен татымаган адәм, бүтән тагын нигә бара? Ялварырга барамы, үпкәләп каргарга җыенамы?»*

Дога кылып ялваруын бервакытта да калдырмаган Сөләйман, йә, намазлыгы өстендә Ходайга ялвара, йә, кайвакыт Чишмә анасына мөрәҗәгать итә, ләкин улы кайтмый.

Чыңгыз Айтматовның «Кызыл яулыклы Гүзәлкәем» әсәре буенча төрек фильмы төшерелгәне һәркемгә мәгълүм (1977 ел). Бик күпләр әлеге фильмны карагандыр. «Яра»дагы Зәйтүнә – авылның иң чибәр кызларының берсе. Габдулла, сугышка барганчы, Зәйтүнә белән сүз куеша – Зәйтүнә Габдулланың сугыштан кайтканын көтәчәк... Әлеге фильмда Асия ролен башкарган атаклы кино йолдызы актриса Түркан Шорай ирен көткән шикелле, Зәйтүнә дә Габдулласын көтә. Зәйтүнәнең ничек аны көткәнен укып барганда, кинәт күз алдыма әлеге фильм килеп басты. Автор да әсәрнең иң уңышлы көтү җөмләләрен Зәйтүнә өчен язган инде: *«Габдулланы көтәме? Көтмәде түгел, көтте. Җыламады, сыктанмады, зарланмады, күңелен ятларга ачмады, уен-моңын уртаклашмады, йомылып эчтән генә үзе янды. Ялгыз кичергән сагыш тирәнрәк тә, кадерлерәк тә була, ялгыз яна алганнар үз кадерләрен ныграк беләләр, ялгыз кичергән хәсрәт таралмый, ул ансат кына онытылмый».*

А.Гыйләҗәв арткы планда бер ата-ананың тормыш тарихын, беренче планда тулыланмаган бер мәхәббәтне, шул ук вакытта сугыш тормыштан алып киткәннәрне гаять тәэсирле итеп аңлатып биргән. Әсәрнең каһарманнары тормыштагыча, наять. Повестьта вакыт һәм урын-җир гаҗәеп осталык белән, бик уңышлы бирелгән. Иң мөһиме – укучы китапның эченә чын мәгънәсендә кереп китә һәм нык ышандыра.

Китапның ахыры көтелмәгәнчә тәмамлана. Алай да кайбер укучылар моны алдан чамаларга мөмкин.

Язучы, татар милләтенең йолалары, гореф-гадәтләре мул итеп бирелгән повестька, тематикасы белән бәйле рәвештә, бер эссе дә урнаштырган. Ләкин бу бер дә ямьсез тоелмый. Моны шулай итеп урнаштыру А.Гыйләҗәвнең нинди оста бер әдип икәнлеген тагы да яхшырак аңларга мөмкинлек бирә, язучы, моның бәрабәренә, укучыга тын алдыра, аны киеренкелектән ял иттерә.

«Яра» – соңгы вакытларда мин укыган иң шәп әсәрләрнең берсе. А.Гыйләҗевнең бүтән әсәрләренең дә төрек укучысына килеп ирешүен түземсезлек белән көтеп калам...

*Журналга* ***Фатих Кутлу*** *әзерләде.* ■

БИКӘ РӘХИМОВАНЫҢ ТУУЫНА – 80 ЕЛ

# Бикә Рәхимова
# *шигырьләре*

Танылган шагыйрә һәм нәшрият мөхәррире Бикә Рәхимова (Миңлебикә Рәхмәтулла кызы Фәйзуллина) 1939 елның 10 апрелендә Татарстанның Әлки районындагы Чуаш Кичүе авылында туа. Башта ул Кичүдә укый, аннан Түбән Әлкидә урта белем ала, Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетының татар теле һәи әдәбияты бүлеген тәмамлаганнан соң, 1968 елдан 1973 елга кадәр гаиләсе (ире – шагыйрь Равил Фәйзуллин һәм улы Алмаз) белән Әлмәттә яши. Рус телле мәктәптә сигез ел татар балаларына татар теле укыта, шул елларда балалар һәм өлкәннәр өчен шигырьләр, хикәяләр яза башлый. Татарстан китап нәшриятында уналты ел буе башта – кече мөхәррир, аннары мөхәррир вазыйфасын башкара.

Бикә Рәхимова, элеккеге СССР халыклары әдәбияты үрнәкләреннән тыш, байтак кына төрек язучыларының (Җәләлетдин Руми, Юныс Әмрә, Мәхмәт Акиф Эрсой, Омәр Сәйфетдин, Ниһял Атсыз һ.б.) әсәрләрен тәрҗемә иттереп матбугатта бастыра. Шагыйрә әле студентлык елларында ук беренче татар шагыйрәсе Газизә Сәмитованың әсәрләрен тәүге мәртәбә китап итеп төзеп, дөньяга чыгаручыларның берсе була.

Б.Рәхимова – 1991 елдан Татарстан язучылар берлеге әгъзасы.

Ул 2011 елда Казанда вафат була.

## ИРЕШЕР...

*Унда үлән – үле калмас, терелер,*
*Аңа чук мәнсаб, мәратиб вирешер.*
*(Бары үлән үле калмас, терелер,*
*Аңа күп мактау, туганлык ирешер).*

***Мөхәммәт Әмин***
*Хан һәм шагыйрь, XV-XVI гасыр*

Үлән күзе карап тора миңа,
Кем дип таный икән җисмемне?
Үз итәме мине? Ни зур шатлык –
Җирдәш, диеп әйтсә исмемне!

Елау-сыктау шигърият юлдашы –
Шул әчтәлек сыя юлына...
Исемнәрне күтәрүе авыр,
Җисме сыйса әгәр колына.

Мин ул бетмәс-төкәнмәс җисемме
Мәрхәмәтле Ходай каршында?..
«Әчтәлегем шул ук – үлән карый –
Үзгәрешләр көтмә карыш та...

## БӘХӘС

Бәхәстәнме? Бәхәстән!
Нәсим белән Нәсимә,
Әй даулаша, әй даулаша,
Теттереп бәхәсләшә.

– Синең сүзең дөрес түгел,
Бака ул квакает.
– Әйттең менә, әт-тә-тә,
Бакылдый хәлдән таеп.

Бака бит ул ба-ка-ка,
Баткакта батып ята,
Әгәр аны куркытсаң,
Агулы суын ата.

Әгәр аңа тимәсәң,
Син килбәтсез, димәсәң,
Рәхәтләнеп бакылдый,
Үз телендә такылдый.

– Кирәге бар квакушкаң,
Эшли алмый, ни кушса.
Ни арбага, ни чанага
Җигеп булмый, ичмасам.

– Син әйтәсең: квакуша –
Кем шундый исем куша?
Үз телеңне, ичмасам,
Тагын син дә бозмасаң!

Туган телең белмичә,
Сүзләр бозып ятканга,
Көләләр бит үзеңнән,
Кычкыралар: ба-ка-ка!

## САНСЫЗ МАЛАЙ

Чабып килеп бер малай
Ак каенга атылды:
Ботагына ябышып,
Әй атынды, атынды.

Һаман атынды малай,
Әллә ниләр кыланды...
Шарт итеп сынган ботак
Җиргә төшеп сыланды...

Әй елады ак каен,
Әй елады ботагы...
Малай ялт икенчегә,
Асылынды бит тагы...

Бу елауны ишетеп,
Көтү-көтү чыпчыклар
Куаклар арасыннан
Очып килеп чыктылар.

Аяусыз малай, диләр,
Бик сансыз малай, диләр.
Алты яшькә җитсә дә,
Тәртипсез малай, диләр.

Аңлыймы соң бу малай
Ни кылганын чын-чынлап?
Әлегә баш очында
Чыпчыклар оча чырлап...

Әлмәттә яшәгән чаклар. Бикә ханым ире Равил Фәйзуллин һәм уллары Алмаз белән.
1968 ел

## КАЙДА?

Син, галәмнең якты йолдызыдай,
Яктыртучым минем – нурлым идең.
Гөлт иттең дә яндың, фидакарь җан,
«Пыскып кына яну – хурлык», – дидең.

Сабыр җанымны да давыл итеп,
Өереп лә алдың, очсын, дидең.
Бар җаннарны тарткан гареш кебек,
Йолдыз белән тулды синең күгең.

Хыялыңнан алтын сарай кордың,
Ә ул нурга күмде дөнья йөзен.
Яшен-таштай мине көйдерсәң дә,
Тик нигәдер сулдың көн дә үзең.

Уйчанландың, гүя тирән дәрья,
Давылландың хәтәр җилләр барда;
Тик шулай да безнең эзләр калды
Кояш сукмагында – комлы ярда.

Йөгереп киләм Идел хозурына,
Сине табармын күк көзге ярда.
Акчарлаклар дәрья якасында
Кычкыралар ярсып: «Кайда? Кайда?..»

*1989*

*Язманы* ***Ләбиб Лерон*** *әзерләде.* ■

БЕР БӘЙЛӘМ БЕРКЕТМӘ

# «ҖИҢЕЛ АДЫМНАРДАН СОҢ»

**29 апрель, 1956 ел.**
**Проза секциясе утырышы.**

***Көн тәртибе:*** *Гөлшат Зәйнашеваның «Җиңел адымнардан соң» исемле повестен тикшерү.*

***Катнашалар:*** *Габдрахман Минский, Гомәр Бәширов, Габдрахман Әпсәләмов, Касыйм Хәмзин, Гөлшат Зәйнашева, Әминә Бикчәнтәева, Нурихан Фәттахов, Гариф Ахунов, Гурий Тавлин, Фатих Хөсни, Мансуров (исеме язылмаган, Зыя Мансуров булуы ихтимал. –* **Л.Л.**).

***Утырышта рәислек итә*** *– Габдрахман Минский.*

***Сәркатип вазыйфасын алып бара*** *– Фатих Хөсни.*

*Фикер алышулар башлана. Беренче сүзне К.Хәмзин ала.*

**Касыйм ХӘМЗИН**. Повестьта бик актуаль тема күтәрелә. Шулай ук анда вакыйгалар да бер-берсенә яхшы ук нык бәйләнеп үсәләр. Ләкин әле әсәрдә күп кенә кимчелекләр бар. Төп персонажлардан, мәсәлән, Рауза әле хәзергә образ-характер булып җитмәгән. Аның мәхәббәте дә, шулай ук нәфрәте дә бик сыек, аның егеткә-иренә булган мөнәсәбәте – позициясе ачык түгел.

Фаяз шулай ук ачылып җитмәгән. Аның өзлексез эчеп йөрүенең сәбәпләре күренми. Ул кире тип буларак та үсү-ачыклануга таба бармый.

Әсәр күбесенчә истәлекләргә-хатирәләргә нигезләнгән, бу хатирәләр артык күп һәм кабатланалар, төчеләнә. Шулай ук әсәрнең теле дә урыны-урыны белән зәгыйфь. Бер кызның икенче кызга «парень» дип эндәшүе урынсыз: «чумарить», «шухор-мухор» кебек урынсыз жаргон сүзләр дә үзләрен нык сиздерәләр – эчне пошыралар. Трест директорының үзен тотышы шулай ук ышандырмый. Әгәр автор аның өстендә иренмичә эшләсә, семья турында түгәрәк кенә бер әсәр булыр кебек күренә.

**Әминә БИКЧӘНТӘЕВА**. Повестьта күтәрелгән мәсьәләләр шактый әһәмиятле. Шулай ук автор яшьләр тормышын да яхшы ук нык белә булса кирәк. Ул ике яшь кешенең язмышын эчке дулкынлану белән хикәяли. Фаяз белән Рауза арасындагы мөнәсәбәт шактый урында ышандыргыч тасвирлана. Ләкин Раузаның мәхәббәте дә, бу мәхәббәтнең башлангычы һәм очлануы да беркадәр ясалмарак чыккан. Фаязның соңыннан машинага тапталуы ясалма. Әсәрне моннан башка да хәл итеп булыр иде. Нәҗия апаның яшь геройларга йогынтысы көчлерәк күренсә, әсәр ота төшәр иде төсле. Кыскасы, геройлар турында әле автор тирәннәнрәк уйлап, яңадан бер кат эшләргә тиеш.

**Нурихан ФӘТТАХОВ**. Иптәшләрнең фикеренә кушылам: әсәрнең темасы һәм алынган идеясе әһәмиятле. Әсәр, һичшиксез, ахырына кадәр эшләнеп, түгәрәкләнергә

Гөлшат Зәйнашева

Нурихан Фәттахов

Әминә Бикчәнтәева

тиеш. Әсәрнең кимчелекләре шактый. Әсәрнең идеясе (кирәкле идея!) әле тиешенчә образ теленә күчеп бетмәгән, ялангач калган. Әсәрдә шулай ук гомумиләштерү көче дә бик зәгыйфь. Рауза белән Фаязның үсеше җитәрлек күренми, алар әсәргә ничек килеп кергән булсалар, шулай ук булып чыгып та китәләр. Фаязның тискәрелеге тиешенчә мотивлаштырылмаган. Тел ягыннан да барысы да урынында түгел. Кирәкле-кирәксезгә рус сүзләре кулланулар, жаргон сүзләр белән мавыгу да бик нык сизелә. Әсәрне мондыйлардан чистартырга кирәк.

**Гариф АХУНОВ**. Әсәрнең сюжетын төзүдә авторның беркадәр уңышы барлыгы сизелә. Әсәр табигый язылган. Анда күңелне ышандырырлык байтак кына эпизодлар бар. Ике исемнән җәяләр эчендәгесе, ягъни «Дулкыннарга каршы» дигән исем миңа ныграк ошый. Раузаны бик нык төшерә торган урыннары бар – мәсәлән, иренең кесәсенә кереп, аның акчасын санавы һ.б., шулай ук Фаяз больницада чакта аның (Раузаның) башка берәү турындагы уйлануы начар тәэсир калдыра.

Әгәр автор әсәрен яхшылап, уйланып яңадан төзәтеп чыкса, матур гына бер әсәр чыгар кебек.

**Гурий ТАВЛИН**. Әсәрдә семья мәсьәләләре алына, ләкин бу алынган семьяның таркалу моментын бу әсәрдә язылган хәлдә генә калдырсаң, ул бу мәсьәләне уңай хәл итү булмас иде. Рауза үз тормышын ничектер яшереп асрый, аның фикер йөртүләре бик сай. Әсәрдә коллективның көче күренми. Ире машина астында калып, больницага эләккәч, Раузаның эчке кичерешләре җитәрлек түгел. Авторның еш кына чит «авторитетларга» ташлануы җитди түгел, үз фикере юк икән, дигән тәэсир кала.

**Габдрахман ӘПСӘЛӘМОВ**. «Семья таркала» дигән фикер, минемчә, дөрес түгел. Минемчә, автор семьяны таркатмыйча саклап калырга тели. Кайбер үзгәртүләрдән соң әсәр, сюжет төзелеше ягыннан, сыеклана гына төшкән. Мине иң нык борчый торганы – Рауза. Анда олы җанлылык җитми, ул күбесенчә зарланып кына йөри. Зарлану – көчсезлек галәмәте. Рафис сызыгын артык тупас һәм ялангач күрсәтеп, автор Раузаны бик нык төшерә. Рауза, барыннан да элек, ире өчен көрәшергә, бу көрәшне ахырына кадәр дәвам итәргә тиеш. Язылыш ягыннан да барысы да тигез түгел. Диалог белән диалог арасы буш калгалый. Шулай ук эчке фаҗигане сурәтләгән урыннарда диалоглар белән артык мавыгуны да уңышлы дип булмый – андый урыннарны

Габдрахман Әпсәләмов

Гариф Ахунов

Гурий Тавлин

эчке кичерешләр рәвешендә биргәндә яхшы булыр иде. Әсәр җәелгән һәм сизелерлек сүлпәнләнгән.

**Гомәр БӘШИРОВ**. Автор моннан дүрт-биш ай элек миңа әсәренең төп замыселен сөйләгән иде, ул вакытта авторның сөйләве миндә яхшы тәэсир калдырган иде. Ләкин әсәр миндә канәгатьләнү тойгысы калдыра алмады. Әсәр, ничектер, җәенке, сүлпән, «салкын канлы» булып чыккан. Күрәсең, автор образлары һәм алган вакыйгалары белән тиешенчә дулкынланмаган.

Әсәрдә яшьләрнең үзара мөнәсәбәте, мәхәббәте үтә җиңел, ригаясез язылган, без моның белән яшьләрдә мәхәббәткә хөрмәтле караш тәрбияли алмыйбыз. Дөресен әйткәндә, тормышка чыкканда Раузада Фаязга карата нинди дә булса ягымлы мөнәсәбәт хисе булды, дип ышанасы да килми. Кыскасы, бу образлар һәм аларның үзара мөнәсәбәтләре аша авторның нәрсә әйтергә теләгәнлеге ачык түгел. Шулай ук Раузаның үзен тотышы шулкадәр начар, Раузаның эчкечелеккә бирелүе үзеннән-үзе килеп чыга төсле. Кыскасы, әсәрнең бу яклары һич тә уйланылып бетмәгән. Гомумиләштерү көче җитәрлек түгел, ул күп кенә урында натуралистик дөрес эпизодлар да бирә кебек, ләкин гомумиләштерү булмаганлыктан, алар чи, таркау булып калганнар.

**Габдрахман МИНСКИЙ.** Әсәр миндә канәгатьсезлек хисе тудырды. Вакыйга уйланылмаган. Ә менә Г.Бәшировка сөйләп биргән замыселе бик яхшы булган. Теле бик чуар, бик кытыршы, бик шапшак. Үзе редактор булган кешегә (1952-1963 елларда Г.Зәйнашева Татарстан китап нәшриятында Матур әдәбият бүлегендә мөхәррир булып эшли. – **Л.Л.**) мондый тел шапшаклыкларын һич гафу итәсе килми. Автор әсәрне яңадан бик нык эшләп чыгарга тиеш.

**Гөлшат ЗӘЙНАШЕВА** фикер әйтүчеләргә рәхмәт белдерә һәм әсәрен төзәтү өстендә эшләргә сүз бирә (автор, күрәсең, каләмдәшләренең фикер-киңәшләренә колак салган һәм әлеге әсәрен китап итеп чыгармаска булган. Авторның китаплары арасында андый әсәре очрамавы шул хакта сөйли. – **Л.Л.**).

Утырыш председателе – /Г.Минский/
Секретарь – /Ф.Хөсни/

*Беркетмәне* ***Ләбиб Лерон*** *укыды.* ■

# ГАФФАРИЗМНАР

Әхәт Гаффар

***

Артыннан төлке кумаса, куян йөгермәс.

***

Яман булуы җиңел, яхшы булуы авыр.

***

Җил белән – җил, җен белән җен сугышмыйча калмас.

***

Бүлешере булмаганның дошманы булмас.

***

Дөнья буйлап, сәяхәтче сыман, Калашников автоматы йөри.

***

Мизгелендә бер әйтми калу гомереңдә мең әйтми калудан үкенечлерәк.

***

Пычактан курыкма, телдән курык.

***

Бәрәкәтсез тотсаң, чишмә дә корый.

***

Кайдадыр җил иссә, татарның яфрагы леперди.

***

Мал асраганның туны бетмәс (тузмас).

***

Дәүләтле татар келәтен мактамас.

***

Ташбака көн буе биш атлам җир киткән, шуңа да сөенә: «Бик җиткән!»

***

Хәзинәңне бүген ятка сөйләү – иртәгә бөлүең.

***

Аерылышуы җиңел, бергә торуы авыр.

***

Татар – тышаулы аргамак.

***

Шагыйрьнең таеп егылырга хакы юк.

***

Башы кызганның җаны өшер.

***

Язучының авызлыгы каләмендә.

***

Куркак батырлык турында сөйләр.

***

Камытын шәп тарткан ат алтын ыңгырчак күтәрми.

***

Көмеш тәңкәле эшләя эш атына эш өймәс.

***

Акыл белән акыл мәңге бәйге тотар.

***

Кыз баланың киләчәге анасының үткәнендә.

***

Иң зур дәрья – адәмнәрнең күз яше.

***

Яшьлегендә яшьнәгән картлыгында да күк күкрәтер.

***

Вакыт узар – хәтер тузмас.

***

Сукыр кояшсыз булмас.

***

Түрә түбәтәй җыяр.

***

Түрәгә түбәтәй төтмәс (төс түгел).

***

Җилкәнеңне борсаң да җилкәңне борма.

***

Уеңдагы – туеңда.

***

Туйдан соң уй ишәер.

***

Үз күләгәңне таптап булмый. ■

# «ӘЛЛҮКИ»ЛЕ ЕЛЛАР

Халисә Ширмән

**«ИҢ МӨҺИМЕ – ЯЗЫГЫЗ!» ФӘННУР САФИН**

...Казан федераль университеты Габдулла Тукай исемендәге милли мәдәният һәм мәгариф югары мәктәбенең татар теле белеме кафедрасы бүлмәсендә бик кадерле бер ядкәр саклана. Совет елларында һәркемнең өендә булган, бәрхет тышлыгыннан бераз нафталин исе аңкып торган калын битле альбом ул. «Әллүки» түгәрәге альбомы. Беренче битләреннән үк тарих бөркелә...

Дәһшәтле сугыш ахырга якынлашканда – 1944 елда Казан университетында татар теле һәм әдәбияты бүлеге ачыла. Әлбәттә, карачай, балкар, кырым татарлары кебек төрки халыклар депортацияләнгән елларда дәүләтнең татар халкына булган мондый игътибары күпләрне таң калдыргандыр. Әлеге адымның сәбәпләре тарих төпкелендә күмелеп калган инде, хәтта тарихчы галимнәр өчен дә бу – ябык сәхифәләрнең берсе. Ничек кенә булмасын, бүлек җитәкчесе итеп билгеләнгән доцент Рабига Афзал кызы Хәкимова тиз арада татар телен һәм әдәбиятын югары дәрәҗәдә укыта алырлык педагог-галимнәр коллективы җыюга ирешә һәм беренче курска ун студент кабул итедә. Шунысы кызыклы: кабул итү вакытында абитуриентларның белем ягына гына түгел, ә иҗади мөмкинлекләренә дә зур игътибар бирелә.

Татар бүлеге оешуның беренче айларыннан ук бирелә иҗади түгәрәк эшли башлый, агитбригада чыгышлары оештырыла, «Әдәби сүз» дип аталган стена газетасы дөнья күрә. Әлеге бүлекне тәмамлаган күп кенә шәхесләр (Ибраһим Нуруллин, Нурихан Фәттах, Мирфатыйх Зәкиев, Гариф Ахунов, Мансур Хәсәнов, Аяз Гыйләҗев, Равил Фәйзуллин, Марсель Әхмәтҗанов, Рәдиф Гаташ, Хатыйп Миңнегулов, Азат Әхмәдуллин, Вахит Хаков, Гомәр Саттаров, Марсель Бакиров, Фәһимә Хисамова, Флера Сафиуллина, Фазыл Фәсиев һ.б.) соңыннан татар халкының күренекле фән һәм мәгариф, әдәбият, мәдәният эшлеклеләре булып китә, университетта укытырга

кала. Сугыш алды репрессияләренә эләгеп, юкка чыгарылган, яу кырларында һәлак булган татар зыялылары урынына сугыштан соңгы ачлык-ялангачлык арасыннан яктыга – мәгърифәткә омтылган яңа катлам татар интеллигенциясе барлыкка килә. Аның формалашуына зур өлеш керткән иҗади түгәрәк – «Әллүки»нең дә тарихы озын һәм катлаулы.

### «ӘЛЛҮКИНЕҢ ЯШЕН СОРАМАГЫЗ...» ЛӘБИБ ЛЕРОН

Татар бүлегендә гөрләп эшләгән түгәрәк егерме елдан артык исемсез, бары «әдәби түгәрәк» дип кенә атап йөртелгән. «Хрущев җепшеклеге» вакытында баш төрткән сүз ирекне әдәби барышка да үзгәрешләр алып килә. Казан университетында алтмышынчы елларда укыган татар студентлары әдәбият дөньясына үзләре бер «дулкын» булып ургылып килеп керә. Бу вакытта лекцияләрне татар халкының атаклы мөгаллим-педагоглары Хатип Госман, Латыйф Җәләй, Якуб Агишев, Мансур Габдрахманов, Ибраһим Нуруллин, Диләрә Тумашева, Гаяз Ишмөхәммәтовлар укыган. 1965 елда татар филологиясенә укырга килгән ике егет – Зөлфәт Маликов һәм Мөдәррис Әгъләмов әдәби утырышларның иң дәртле, актив оештыручыларыннан була. Түгәрәкнең исемсез йөрүе алар күңелендә ризасызлык уяткан, күрәсең. Һәм, озак уйлап тормый, алар татар халкының бишек җыры булган «Әллүки»не түгәрәк исеме буларак игълан итәләр. Исеме җисеменә туры килә: «Әллүки», чын мәгънәсендә, яшь иҗатчыларны тәрбияли, аларга канат куя, үстерә торган бишеккә әйләнә. Бүгенге көндә татар халкының сөекле уллары һәм кызлары Зиннур Мансуров, Роберт Миңнуллин, Фәйрүзә Мөслимова, Галимҗан Гыйльманов, Газинур Морат, Ркаил Зәйдулла, Ләис Зөлкарнәй, Рафис Корбан, Рифә Рахман, Илсөяр Ихсанова һәм башка бик күпләр – әлеге бишектә тәрбияләнеп, иҗат дөньясында үз юнәлешләрен булдырган әдипләр.

Түгәрәкнең җитәкчесе алышынып торган. Гадәттә, студентлар үзләре арасыннан иң актив, иҗат итә торган, оештыру сәләте булган студентны староста итеп сайлаганнар, ә та-




тар бүлеге укытучылары арасыннан бер укытучы җитәкче-куратор буларак билгеләнгән. «Әллүки» тарихы турында сөйләгәндә, озак еллар дәвамында университетта әдәбият фәне тармакларын укыткан, үзе дә «Әдәби сүз» газетасында иҗат юлын рәссам буларак башлаган Марсель Хәернас улы Бакиров исемен атыйлар. Марсель аганың «Әллүки» яшәешенә керткән өлеше әйтеп бетергесез зур. Төрки шигырь төзелешен фәнни яктан өйрәнгән шигъри күңелле галим һәрвакыт яшь шагыйрьләр иҗаты белән кызыксына, үзенең киңәшләрен бирә, юнәлеш күрсәтә. «Әдәби сүз» стена газетасы ул баш мөхәррир чагында университет күләмендә уздырылган ярышта беренче урынга чыгып, аннан соң Казан шәһәрендә үткән вузара ярышта да алдынгылыкны яулый.

XX гасырның 80-90 нчы елларында һәм XXI гасыр башында «Әллүки» әдәби түгәрәген татар бүлегендә эшләгән язучы-галимнәр әйдәп алып баралар. Мөхәммәт Мәһдиев, Галимҗан Гыйльманов һәм Рифә Рахманның әдәби остаханәсе аша дистәләрчә әллүкиче иҗат дөньясына килеп керә, күренекле язучы-шагыйрьләр булып җитешә. Бу еллардан Рөстәм Сүлти, Рәмис Аймәт, Резидә Әхтәмова (Җәмилә), Алмаз Гыймадиев, Айдар Минһаҗев, Чулпан Әхмәтова (Таңчулпан), Гамилә Рәхмәтуллина һ.б. исемнәр «Әллүки» елъязмасына уелып кала.

..Бәрхет тышлы альбомга еллар кагылмаган: 75 еллык тарихы булган әдәби түгәрәкнең «Әллүки» исемен алуын билгеләп үтү вакыйгасын, әлеге чарага килгән күренекле әдипләрнең кул тамгаларын һәм килер буын әллүкичеләргә аталган сүзләрен саклый ул. Бу турыда 1987 елда шул вакыттагы әллүкичеләр – Люция Шәрәфиева, Света Заһриева, Әлфия Сафина һәм Филиза Сәлахова язып куйган: «Без 24 апрель көнне «Әллүки» әдәби түгәрәгенә «Әллүки» дип исем бирелүгә 20 ел тулуны билгеләп үттек. 1985 елның 12 мартында «Әллүки» түгәрәге оештырылуга 40 ел тулуын билгеләп үткән идек. Безнең түгәрәк татар бүлеге ачылганнан бирле яшәп килә икән инде».

«Әллүки»нең яшен сорамагыз –

Халык белән бергә туган ул:

«Әллүки» ул – зәңгәр күзле Такташ
Һәм ак чәчле Хәсән Туфан ул... 24.04.1987.

Ләбиб абый Леронның альбом битенә экспромт язып калдырган әлеге сүзләре шулкадәр төгәл, шулкадәр күңелгә якын-кадерле...

### «БЕЗ ӘЛЕ КАРТАЙМАБЫЗ...» МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ

Шау-шулы 90 нчы еллар ахырында «Әллүки» берара тынып кала. Әллә җәмгыятьтә барган икъдисади-сәяси тетрәнүләр әдәби барышка тискәре йогынты ясый, әллә инде түгәрәк зур күтәрелеш алдыннан хәл җыя. Бу күтәрелеш исә үзен озак көттерми: 2000 нче елларда университетта иң зур факультетларның берсенә әйләнгән татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләр факультетына үзгәртеп кору чорында туган балалар укырга килә башлый. Болар хөр фикерле, милли җанлы, белемле укучылар була. Дөньяны киңкырлы күзаллау белән бергә, күбесенең күңелендә әдәбиятка тартылу яши. Йолдыз Миңнуллина, Луиза Янсуар, Ленар Шәех – нәкъ менә әлеге чорда шушы мохиттә белем алган шәхесләр. Галимҗан Гыйльманов җитәкчелегендә 2 нче курс студенты Ленар Шәех (хәзерге вакытта Татарстан китап нәшриятының баш мөхәррире) «Әллүки» түгәрәгенең эшен кабаттан торгызып җибәрә, «Әдәби сүз» стена газетасы урынына типография юлы белән 1000 данәдә басылган һәм университет студентлары арасында таратылган «Тәрәзә» газетасын гамәлгә куя. Бу чорда «Әллүки» татар факультеты студентларын гына түгел, башка уку йортларыннан да студентларны үзенә туплый. Татар дәүләт гуманитар-педагогик университетының – «Илһам», Алабуга дәүләт педагогик университетының – «Шәкертләр», Башкортстандагы «Акчарлак» һәм «Шоңкар» әдәби иҗат түгәрәкләре белән бәйләнешкә кереп, фикердәшләрен таба, Идел-Урал төбәге студентларының «Шигъри Сабантуй» дигән иҗат бәйгесен оеш-



тыра. Ленар Шәех, Лилия Гыйбадуллина, Рифат Сәлах, Айсылу Имамиева, Рөстәм Галиуллин, Лилия Закирова, Айдар Җамал кебек әллүкичеләрнең китаплары дөнья күрә, аларның күбесе Татарстан Язучылар берлегенә кабул ителә.

2006 елда «Тәрәзә» газетасы республика күләмендә уздырылып килгән «Ел студенты» бәйгесенең «Иң яхшы студентлар басмасы» номинациясендә лауреат исеменә лаек була, 2007 елда университетта үткән «Ел студенты» конкурсының «Иң яхшы студентлар газетасы» номинациясендә дә җиңү яулый. Татарстан китап нәшрияты, әллүкичеләрнең иң яхшы әсәрләрен туплап, ике тапкыр «Әллүки» дигән җыентык бастырып чыгара.

2010-2011 нче елларда Казан дәүләт университеты һәм Татар дәүләт гуманитар-педагогика университеты берләшкәннән соң, «Әллүки» белән «Илһам» түгәрәкләре һәм алар чыгара торган «Тәрәзә» белән «Раушан» газеталары да кушылып, «Әллүки» әдәби иҗат берләшмәсе һәм аның газетасы «Раушан» буларак эшләп китә. Ел саен үткәрелә торган «Шигъри Сабантуй» бәйгесе студентлар арасында гына түгел, мәктәп укучылары арасында да көтеп алынган тантанага әйләнә. Бу елларда әдәбият мәйданында Булат Ибраһим, Фәнил Гыйләҗев, Рүзәл Мөхәммәтшин, Алмаз Мансуров, Руфинә Габдрахманова, Эльмира Камаева, Айгөл Абдрахманова, Чулпан Гобәйдуллина, Светлана Гыйләҗева, Илсөя Галиәкбәрова, Алинә Галиева, Гүзәл Закирова, Ләйлә Хәбибуллина, Зилә Сабитова, Алсу Сәлахова, Гөлүсә Шиһапова, Энҗе Хөсәенова кебек яңа исемнәр мәгълүм була, аларның иҗаты «Илһам канатында», «Дәвам», «Ак юл» җыентыкларында дөнья күрә. Яшь шагыйрь һәм язучыларны дөньяга таныткан «Яңа дулкын» чараларында катнашу оештырыла, төрле иҗади конкурсларда әллүкичеләр ел саен утызга якын призлы урыннар яулый.

«Әллүки» картаймый. 75 яшендә дә аның йөрәге унсигездә: ул яшьләрчә дуамал-бунтарь; ул нокта085 ларсыз һәм баш хәрефләрсез шигырь яза, ритм-рифмаларны сындыра; ул, заманга ияреп, кинофильмнар төшерә, селфилар ясый, социаль челтәрләрдә сәяхәт итә. Ул беркайчан да картаймаячак, чөнки «Әллүки» – бишек җыры... Яңарыш җыры! ■

**«ТАТМЕДИА» республика матбугат**
**һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы**
**Татарстан китап нәшрияты,**
**«Безнең мирас» журналы редакциясе**

## ТАССРНЫҢ ҺӘМ ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫНЫҢ 100 ЕЛЛЫКЛАРЫНА БАГЫШЛАП, «ХӘТЕРГӘ УЕЛГАН КИТАП» ИСЕМЛЕ КОНКУРС ИГЪЛАН ИТӘ

**КОНКУРСНЫҢ МАКСАТЫ** – татар китап мирасын пропагандалау, республикабызда телләрне саклау һәм үстерү, яңа авторларны табу, алар белән хезмәттәшлек итү.

**Конкурс 2019 елның 1 апреленнән 2019 елның 15 декабренә кадәр** үткәрелә.

**Конкурска** үзегез бик тә яратып укыган, тормышыгызда мөһим роль уйнаган, хәтергә уелып калган яки сез «өстәл китабы» буларак файдалана торган китап турында татар телендә язылган очерк, эссе, мәкалә кабул ителә. Күләме А4 форматында 12 нче кегельдә 2 биттән дә артмаска тиеш.

**Конкурста** катнашучылар үзләренең эшләрен «Безнең мирас» журналына 2019 елның 2 нче ярты еллыгына яки 2020 елның 1 нче ярты еллыгына язылу турындагы квитанция фотосын (скан вариантын) беркетеп, yanamiras@mail.ru электрон почтасы адресына «КОНКУРСКА» дигән сүз белән җибәрергә тиеш.

**Конкурска** юлланган эшләр Татарстан китап нәшриятының генераль директоры һәм «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире раслаган жюри әгъзалары тарафыннан бәяләнеп, җиңүчеләр 2019 елның 1 декабрендә игълан ителә.

Җиңүчеләргә акчалата премияләр, Татарстан китап нәшриятыннан китап алу өчен сертификатлар, «Безнең мирас» журналы редакциясеннән конкурста призлы урын алучыларга сертификат һәм барлык катнашучыларга дипломнар биреләчәк.

Барлык материаллар да «Безнең мирас» журналында яки http://beznenmiras.ru/ сайтында басылачак.

Конкурс турындагы мәгълүмат **http://beznenmiras.ru/** сайтына урнаштырыла.

Безнең мирас №4 апрель 2019

# ТАТАРСТАН САНДУГАЧЫ

Әгъзам Фәйзрахманов

*Мин композитор, җырчы Сара апа Садыйкова белән Казан дәүләт университетында укыган вакытымда таныштым. Көннәрнең берендә ул, дәресләр тәмамланугa аудиториягә керде дә, университетта татар хоры оештырып йөрүе турында әйтте. Аннары безнең төркемнән унлап студентны сайлап алды да, химкорпусның гадәттә барлык тантаналары үтә торган иң зур йөзенче аудиториясенә кереп китте. Без дә аңа иярдек. Сара апа безне нинди сыйфатлардан чыгып сайлагандыр, моны әйтә алмыйм. Бәлки тышкы кыяфәткә, үзебезне ничек тотуга, кием-салымга игътибар иткәндер.*

Без кергәндә йөзенче аудиториядә инде төрле төркемнәрдән җыелган берничә дистә студент бар иде. Сара апа безне тиз генә тезеп тә куйды. Бик үк таныш булмаган кыз белән мине алга бастырды. Без – солистлар – башлап җырлаучылар булырга тиеш икән. Җитәкчебезнең ниятен белеп алуга, мин ризасызлыгымны белдердем. Моңарчы авылларда үзешчәннәр концертларында катнашкаласам да, сәхнәдә бер тапкыр да җырламадым. Шигырьләр, төрле мәзәкләр сөйләдем, концертлар алып бардым. Турысын әйткәндә, бөтенләй җырлый белми идем. Гомумән, безнең нәселдә оста җырлаучылар юк иде.

Бу хакта Сара апага әйткәч, минем сүзләргә аның әллә ни исе китмәде: «Өйрәнерсең. Репетицияләр шуның өчен бит», – дип кенә куйды. Әмма мин, берничә репетициядә булганнан соң, бу эштән котылу әмәленә керештем. Репетиция көнне, соңгы тәнәфестә берәр сәбәп табып, аудиториядән чыгып китә башладым. Төркем старостасы булганлыктан, кая китүемне берәүгә дә аңлатып тормый идем. Күрәсең, Сара апа да мине аңлагандыр, ачуланмады. Очрашканда исәнләшеп, хәл-әхвәл сорашып йөри башлады. Университетны тәмамлагач та озак еллар дәвамында Сара апа Садыйкова белән даими аралашып яшәдем.

Казан шәһәрендә туган булса да, Сара апа әти-әнисе, әби-бабасының кендек каны тамган Апас төбәген үзенең газиз җире, туган ягы дип санады. Чөнки моң чишмәсе, зур дәрья кебек киң иҗатка юл башы Апас районының Тутай авылыннан башланган.

Тутайда туып-үсеп, соңрак Казан пристаненда пароходлар йөртү эшендә казна хезмәтен үтәүче Әхмәдишаның кызы Бибигайшә әнисе Нәгыймә ападан ятлаган шигырь-мөнәҗәтләрне, халык көйләрен кызы Сара күңеленә дә сеңдерә. Бәлки шуның нәтиҗәседер, кыз киләчәген тулысы белән сәнгатькә багышларга карар кыла. Үз гомерендә дан-шөһрәт диңгезендә коенган, «Татарстан сандугачы» дигән исемгә

Сара Садыйкова сәхнәгә чыгар алдыннан (1980 нче еллар башы)

С.Садыйкова опера һәм балет театрында куелган «Мәхәббәт җыры» спектакленнән соң артистлар арасында (1970 нче еллар уртасы)

хаклы рәвештә лаек булган Сара Гариф кызы Садыйкова гомере буе Апасякларын данлады, бу гүзәл төбәккә багышлап җырлар язды, халкы белә очрашты һәм үзеннән соң гаять матур – күркәм истәлек-хатирәләр калдырды.

Аитовлар мәктәбендә гимназия программасын үзләштергәннән соң, С.Садыйкова педагогоия техникумына юл тота һәм биредә татар халкының беренче композиторларыннан саналган Солтан Габәшидә музыка белеме ала. Ә аннары П.Чайковский исемендәге Мәскәү дәүләт консерваториясе... Соңрак, зур җырчы һәм композитор булгач, Сара Садыйкова үзенең осталары – профессорлар Прохоров, Цебушенко, танылган композитор, опера остасы Антон Эйхенвальдны олы хөрмәт хисләре белән искә ала.

Мәскәүдә укыганда Сара апа тормышында тагын бер вакыйга булып ала. Ул Луначарский исемендәге театр институты студенты, булачак актер һәм татарлардан беренче профессиональ режиссер Газиз Айдарскийга кияүгә чыга. Алар башкалада эшләүче татар театрларында барган спектакльләрдә баш рольләрне башкара башлыйлар.

1925 елда, Татарстан Республикасының бишьеллыгы уңаеннан, С.Габәши, Г.Әлмөхәммәтов Һәм В.Виноградов «Сания» операсын иҗат итә. Татар сәнгате тарихында беренче операны! Төп партияне башкару өчен, Мәскәү консерваториясе студенткасы Сара Садыйкова, әсәрне сәхнәгә кую өчен, Газиз Айдарский вакытлыча Казанга чакырыла. Ул елларда Казан музыка училищесы директоры булып эшләгән А.Литвинов «Сания» операсының дирижеры була.

Зур иҗади дуслык шартларында туган бу операны бөтен Казан җәмәгатьчелеге түземсезлек белән көтеп ала. Булачак опера солисткасы Сара Садыйкова тырышып укуның беренче нәтиҗәләрен күрсәтә, ул Сания ариясен зур осталык белән башкара.

Операны карагач, Фатих Әмирхан болай дип яза: *«Сания» операсындагы төп*

Сара Садыйкова Гомәр Бәширов белән (1980 нче еллар ахыры)

*рольне С.Габәши Сара Садыйкованың чылтырап аккан чишмәдәй саф тавышын күздә тотып иҗат итә. Яшь җырчы Сара Казан тамашачылары алдында зур сынауны бик уңышлы үтә, сәнгать сөючеләрнең күңелендә гүзәл кыз Сания образын тудыра».*

С.Садыйкова Мәскәүдә укыган чорда Г.Айдарский оештырган һәм җитәкчелек иткән Мәскәү татар эшче театрында эшли, татар музыкаль мәдәниятен булдырып һәм аңа хезмәт итеп, Советлар Союзын иңли, халыкка концертлар һәм спектакльләр күрсәтеп, Казанга кайткач, сәнгать үзәкләрендә була. Укуны тәмамлап Казанга кайткач, С.Садыйкова, Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында төр рольләрне башкара.

1938-1948 елларда Сара апа – татар опера һәм балет театры артисткасы. Монда да аңа төп партияләрне тапшыралар. Ул яшь композитор Нәҗип Җиһановның «Качкын» опрасында Рәйхан партиясен башкара. Бу Сара Садыйкованың диплом эше дә була. Ә аннары, Мансур Мозаффаров тарафыннан «Галиябану» операсы язылгач, Га-

лиябану партиясен җырлый. С.Садыйкова шушы ук чорда композиторлык эшенә дә кереп чума.

Аның татар театрларында барган 18 спектакльгә музыка язуы мәгълүм. Композиторның 1971 елда иҗат иткән «Мәхәббәт җыры», 1972 елда куела башлаган «Кияүләр» музыкаль комедияләре музыка җәмәгатьчелеге тарафыннан югары бәяләнә.

Сара апа бик күп шагыйрьләр белән иҗади дуслыкта эшләде. Гөлшат апа Зәйнашева һәм Мостафа Ногман белән алар бигрәк тә якын дуслар иде булса кирәк. 1996 елда Гөлшат ханымның «Сара Садыйкова» дигән китабы дөнья күрде. Ә композиторның М.Ногман сүзләренә язылган «Актаныш таңнары», «Балкый Шәйморза утлары», «Туган авылыма», «Арча кичләре», «Сөн буйлары бөдрә урман» һәм башка җырлары бүген дә репертуардан төшми. Музыка белгечләренең раславына караганда, Сара апа 400гә якын җыр иҗат иткән. Белмим, татарлар арасыннан мондый актив эшләүче тагын берәр композитор бармы икән?!

Хәтерлим әле, яңа әсәрен иҗат иткәч, С.Садыйкова еш кына телевидениегә килә иде. Без, телевидение студиясе хезмәткәрләре ул әсәрләр белән тамашачыларны да таныштырырга тырыша идек.

Җырчы, композитор Сара Гариф кызы Садыйкова 59 ел дәвамында Татарстанның музыкаль мәдәниятен барлыкка китерү һәм аның чәчәк атуы өчен җиң сызганып эшләде. Сәхнә Сара ханымның стихиясе, аның тормышының иң җанлы, күңелендә канәгатьлек тудыра торган иң нәтиҗәле өлеше булды. Сара Садыйкова үзеннән соң бай мирас калдырды. Аның бик күп әсәрләре татар музыкасының беркайчан да искерми, кадерен югалтмый торган алтын фондына керде.

«*Күпкырлы иҗат эшчәнлеге алып барган якташым Сара Садыйкова турында сөйләве кыен да, җиңел дә. Кыен, чөнки опера сәнгатенең беренче карлыгачы, үзенчәлекле артистка, сандугачтай моңлы җырчы, сәләтле композитор турында сөйләү өчен үзеңә күп нәрсәне белергә кирәк. Җиңел,чөнки аның күпкырлы иҗат байлыгын халык күптән белә*», – дип язды «Тау ягының кадерле баласы» мәкаләсендә филология фәннәре докторы Мөхәммәт Гайнуллин.

Музыка сәнгатен үстерүдәге зур хезмәтләре өчен, С.Садыйкова Татарстанның атказанган (1939), халык артисткасы (1977), Россия Федерациясенең атказанган сәнгать эшлеклесе (1984) дигән мактаулы исемнәргә лаек булды. Ә үзе үлгәннән соң, 1990 елда аның иҗаты Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе белән бәяләнде.

Балерина Әлфия Айдарская әнисе – халкыбызның талантлы кызы, олы сәнгатьнең зур йөген XX гасыр буена үз иңнәрендә тартып барган Сара Садыйкованың (1906-1986) тормыш юлын чынбарлыктагыча тарих сәхифәләренә теркәп калдырырга тырыша. Гаилә архивындагы материалларны киң җәмәгатьчелеккә тәкъдим итә.

«Яшәү яме» ветераннар клубы татар халкының күренекле җырчысы һәм композиторына һәйкәл куяр өчен имза җыя. Сынчы Рада Нигъмәтуллина иҗат иткән «Җидегән чишмә» композициясе Казанның Юнысов мәйданында куелырга тиеш булса да, ниндидер сәбәпләр белән куелмый калды. Быел, ниһаять, Сара апаның һәйкәле булыр, дип өметләник. ■

# Күршем Хәсән Сарьян

Фәйруз Якупов

*Казан махсус автобазасында (спецавтобаза) профсоюз оешмасы рәисе булып эшлим. Күп кыенлыклардан соң, 1974 ел безгә – яшь гаиләгә зур шатлык алып килде: парлы тормышны башлап җибәргәннән соң беренче мәртәбә бусагадан үз өеңә кыю атлап керергә мөмкинлек туды. Зорге урамының 50 нче йортыннан кечкенә генә бер бүлмәле фатирга ордер бирделәр.*

Аңа кадәр ничә еллар буе тулай торакта яшәп, бер урыннан бер урынга күчеп йөрүдән шактый туйган идек инде.

Комаров урамындагы тулай торактан бу яңа фатирга күчү күп мәшәкать тудырса да, гаилә тормышыбызның дөрес юнәлештә хәрәкәтенә канәгать идем. Мондый уңай хисләргә беренче бала көтүебез дә зур этәргеч бирде. Йортыбыз ыгы-зыгы килә. Монда әле генә яшәргә килгән, моңа кадәр бер-берсенә таныш булмаган кешеләр бер казанда диярлек кайный: өй җиһазларын күтәрәләр, төшерәләр, үзара танышалар, бер-берсенә ярдәмгә киләләр...

Шунысы да билгеле булды: безнең мәйданчыкта (йортыбызның өченче катында), дүрт бүлмәле фатирда язучы Хәсән Сарьян үзенең гаиләсе белән яши икән. Аның турында ишеткәнем булса да, үзе белән таныш түгел идем.

Әкрен генә элекке танышларыбыз да очрый башлады бу йортта. Минем белән Казан университетында бер курс алдарак тарих-филология факультетында укыган яшь, аягында шактый нык басып торучы Рәдиф Гатауллин монда тора икән. Хатыным Рушания белән медицина институтында укыган Юрий Майоров та дүрт бүлмәле фатир алып, безнең өске катка күчкән. Ул инде хәрби медицина хезмәте капитаны...

Казан дәүләт университетында укыган еллардагы замандашларым арасында язучылар, шагыйрьләр шактый күп. Без, күпләр, укуны бетереп, мәктәпкә укытырга киттек. Миңа да урыс мәктәбендә тарих, урыс теле һәм әдәбияты дәресләрен укытырга туры килде. Ә әдәбият, иҗат эшендә уку елларында ук шактый зур адымнар ясаган талант ияләре, университетны тәмамлап, Казанда калдылар, газета, журнал, редакцияләрендә, радио һәм телевидениедә, яшь журналист буларак, иҗат эшләрен дәвам иттеләр, шактый зур уңышларга ирештеләр. Шулар арасында Равил Фәйзуллин, Рәдиф Гатауллин (Гаташ), Рөстәм Мингалим, Шамил Маннапов һәм башкалар бар иде.

Язучылар белән аралашу, аларны тыңлап утыру, нигәдер, минем өчен бик рәхәт. Алар белән сөйләшү җанга нindidер бер дәва бирә. Әдипләр үзләренә генә хас караш белән күрә белә: чишмә суы челтерәвен, куаклар серләшеп пышылдашканны башкачарак ишетә, болындагы чәчәкләрнең исләрен башкачарак тоя, тормыштагы безнең өчен гади булган бер кечкенә объекттан тирән фикерле йомгак ясый белә, көтелмәгән образ тудыра ала. Күбесе белән сөйләшкәндә, аралашканда алардан кыйммәтле мәгълүмат аласың. Тормыш проблемаларын уртаклашканда, язучылар, асыл татар интеллигентлары буларак, һәр әйберне үз исеме белән атап сөйләшәләр, үз фикерләрен күзгә карап, туры әйтәләр. Гомумән, аларның байтагын ялган, ясалмалылык дигән нәрсә читләп үтә.

Сарьян ага да шундый кеше иде!

Тагын өстәп шуны әйтү мәслихәт: хатыны Фирүзә ханым Сарьян агага өч ир-бала бүләк иткән. Инде барысы да үсеп җиткән, чибәр, акыллы егетләр. Аларның гаиләсендә зур дуслык иде. Дүрт бүлмәле фатирларының бер бүлмәсе – Сарьян аганың иҗат итү урыны. Монда идәннән түшәмгә кадәр дивар буе сузылган китап киштәсе, язу өстәле, урындык, диван.

«Җылыга елан да ияләшә», – ди безнең халык. Хәсән Сарьян да бик ягымлы, якты күңелле кеше иде. Аның өеннән кеше өзелеп тормады.

«Мин – язучы, зур шәхес!» дигән сыман җансыз, салкын һәйкәл позасы юк иде аңарда. Ул беркемне дә кире какмый, чын күңелдән, игътибар белән сөйләшә. Шуңа күрәдер, Сарьян ага янына кеше күп килә: алар уй-фикерләре белән уртаклашалар, аңардан киңәш, ярдәм сорыйлар.

Шулай беркөнне ишектән чыгуыма, ни күзем белән күрим: Сарьян агадан безнең авыл кешесе Радик Муллин чыгып бара. Бу бик кыска һәм көтелмәгән очрашу булды. Ул елларны Радик Чуашстанның Комсомол районындагы безнең күрше Тукай авылында укытып йөри иде. Сирәк кенә фельетоннары, юмористик хикәяләре басылгалады. Гомумән, әдәбият иҗат эше белән дә мавыккан еллары...

Соңрак Сарьян агадан сорыйм:

– Радик иҗатына мөнәсәбәтегез ничек? – дим.

Сарьян ага, миңа җавап итеп:

– Тормыш баскан аны, – диде.

Чыннан да, бу бик тирән мәгънәле сөземтә иде. Безнең авыл кешесе буларак, миңа Радикның тормышы, язмышы ничек катлаулы булуы билгеле иде. Бәлки шуңа күрәдер, Радик әдәбиятта киң колач ала алмады, иҗаты йомылып калды.

Язып үтүемчә, туган ягым – Чуашстан. Мондагы Батыр, Комсомол районнарында мишәр-татарларның авыллары урнашкан. Биредәге халык – искитәрлек эш сөючән, әрсез, эшлекле, кыю. Чуашстандагы татар авылларына барып керсәң, хәйран каласың. Урманнан шактый ерак урнашкан булсалар да, күбесенең өр-яңа йортлары еракта ук елмаеп-көлеп тора. Монда яшәүчеләр бер-берсеннән үрнәк алып, көнләшеп, ярышып-ярышып йортлар кора. Кайберсенең йорты әле шактый яңа булса да, аны сүтеп, сатып, тагын да яңарагын төзиләр.

Урам буйлап үткәндә, гаҗәпкә каласың: һәркемнең өй турында бүрәнәләр, берничә ел ягарга җитәрлек кисеп, ярып, киптереп куйган утын өелмәләре, төрле-төрле төзү материаллары. Әйтерсең лә монда иксез-чиксез складлар, урман делянкалары. Еллар үтеп, авылларга газ кергәч кенә, бу «делянкалар» юкка чыкты, әмма һәрбер йортта диярлек затлы чит ил машиналары тора, аларның саны ел саен күбәя бара...

Элегрәк, бигрәк тә сугыш елларыннан соң, йортларны бүрәнәдән салалар иде. Әмма башы салам белән япкан йортлар шактый тиз юкка чыкты.

Ә менә халык шулкадәр уңган, эш сөючән булса да, Арча ягындагы кебек, бу авыллардан үзенең Тукайлары, Мәһдиевләре, Ахуновлары, Сәйдәшләре үсеп чыкмаган. Әлбәттә, безнең Фәтхи Бурнаш, Кави Латыйпларыбыз бар. Ләкин аларның икесе дә Батыр районыннан.

Бәлки һәрбер авылдан Туфан Миңнуллин, Хәйдәр Бигичев кебек кабатланмас шәхесләр үсеп чыгу мөмкин дә түгелдер. Ләкин бездә дә чишмәләр бар ләбаса! Бездә дә шундый ук матур урманнар шаулый, кошлар сайрый, Казансу шикелле, Кондырлы, Гөбенә елгалары Иделгә су өстиләр...

Бәлки мондый табигый сорауларга беркемнең дә җавап эзләгәне юктыр? Сәбәп нәрсәдә соң? Караңгылыкмы яки кыргыйлыкмы бу? Рухи зәгыйфьлек билгесе түгел микән? Соңгы елларда кайбер татар авылларында бер гармунчы да, бер җырчы да юк

Сарьян Хәсәнов (уңда) Лирон Хәмидуллин һәм җәмәгате Фирүзә Еникиева-Хәсәнова белән

шикелле. Кайсыдыр елларны хәтта безнең авылның Сабан туен да чуаш авылында оештырдылар. Ә Татарстанда бит зур-зур татар авылларының клублары, стадионнары, үзешчән сәнгате, җыр бәйрәмнәре, төрле-төрле конкурслар, ярышлар, турнирлар...

Күпмедер дәрәҗәдә бу уйлар мине дә борчый. Кайчандыр Сарьян ага янына килгән безнең авыл егете Радик Муллинның иҗаты чишмә булып ага алмады. Безнең авылдан Вазыйх дустым да, күрше Әребашы авылы егете Фазыл Абитов та, мәктәптә уку елларында шигърияттә беренче ышанычлы адым ясасалар да, иҗат очкыннары ут булып кабынмады. Әлбәттә, бу уйланулар әйтелгән шәхесләрнең гаебе түгел, тәкъдиреңә ни язылган бит...

Шуңа күрә бертуган абыемның улы Ркаил Зәйдулланың бик яшьтән шигырьләр белән шактый профессиональ югарылыкта мавыгуы безнең якта яшәүчеләр өчен яңалык булды, минем дә күңелдә өметле хисләр уянды.

Рәсәйдә гади халык беркайчан да әйбәт яшәмәде. Ркаилнең дә балачак еллары җиңел булмады. Шулай да, әтисе, бабасы күргән сугыш еллары авырлыклары белән чагыштырып булмый аның яшүсмер елларын.

Ркаилнең әтисе дә, бабасы да – укытучы булып, күп еллар хезмәт иткән кешеләр. Шуңа күрә, матди яктан гаиләдә авырлыклар булса да, әтисе аңа бик яшьтән үк китаплар, газета-журналлар укып көне-төне утырырга мөмкинлек бирде, кирәкле шартлар тудырырга тырышты. Ркаил үзе дә бик яшьтән китап укырга маһир иде, сабый чагын-

нан ук шигырьләр белән мавыкты. Мәктәптә укыганда ук шигырьләре Казандагы үзәк газеталарда, журналларда басылып килде. Язучылар, журналистлар белән бәйләнешкә керергә тырышты, мөстәкыйль, инициативалы булды ул. Ркаил бик яшь килеш берүзе Казанга килеп, Язучылар оешмасында таяныч эзләде, белемгә омтылды.

Әтисе аның инициативасына һәрвакыт юл ачты. Ркаилнең әле малай чагында ук балалар шагыйрәсе Зәкия Туфайлова янына килүе хәтеремдә. Мәрхүмә Зәкия Туфайлова ул елларны Жуковский урамында яши иде. Бу йортта мин дә туганыбыз Муза апаларда бик еш була идем. Ркаил, Зәкия апа янына килеп, аңардан төпле киңәшләр алып, канатланып кайта иде.

Беркөнне, ундүрт-унбиш яшьләрдә чакта безгә килгәч, күршедә генә язучы Хәсән Сарьянның яшәвен ишетеп, аларга кереп китте. Соңыннан Сарьян агадан Ркаил турындагы фикерен сорадым. Ул, кыска гына:

– Өмет бар! – дип җавап бирде.

Шул көннәрдә Сарьян ага миңа үзенең «Казан утлары» журналында бастырган «Бер ананың биш улы» повестен бүләк иткән иде.

Әйткәнемчә, өстәге катта табиб Юрий Майоров гаиләсе яши иде. Беркөнне ул шатлыгы белән уртаклашты: Васильево бистәсендә кечкенә генә җир участогы алып, дача йортын төзеп бетерәсе икән.

Әлеге елларны дачага участок алу бик зур проблема иде. Ә анда төзү эшләрен башлап җибәрү – тагын да кыенрак. Төзү материалларын сатып алу үзе бер михнәт, һәрбер сатып алган такта кисәгенә, кадакка акча түләгәнлеккә документ кирәк. Әгәр дә йортыңны кыек юл белән салуыңны белсәләр, эзәрлекләү башлана. Йортны төзегәндә дә нормалардан чыгарга ярамый. Ул кечкенә булсын, ике катлы булмасын, бүрәнәдән, кирпечтән салырга ярамый... Мич чыгарырга, мунча салырга да ярамый – рөхсәт юк. Гомумән, закон кысасыннан чыкмаска тиешсең. Заманасы шундый.

Шулай да халык үз дачасын булдырырга тели – җиләк-җимеш, яшелчәне базардан сатып алу бик авыр мәсьәлә иде ул елларны.

Майоров Язучылар союзына караган бакча кооперативыннан җир алган. Ул әйтә:

– Син күршебез Хәсән Сарьян белән сөйләшеп кара әле, ул бит язучы кеше. Бакча мәсьәләсен хәл итүче Мөсәгыйт Хәбибуллин Язучылар союзында.

«Попытка – не пытка!» Сарьян ага белән сөйләшеп карарга булдым.

Аның белән икәү генә кухняда чәй эчеп утырганда сүзне ерактан башладым:

– Сарьян ага! – дим. – Мин бит Совет иленең «каймагы». Сугыш елларында балачагым ач-ялангач үтте, черек бәрәңге, кычыткан шулпасы ашап, ачтан үлми калдым. Сугыштан соң, ундүрт яшемдә колхоз кырыннан бер центнерлы капчыклар белән келәткә иген ташыдым, урта мәктәпне ачлы-туклы, аякка чабата киеп, уңышлы тәмамладым. Комсомол сафында булдым, армиядә Чиләбе өлкәсендә «Маяк» атом станциясе шартлаганнан соң радиация белән зарарланган җирләрдә хезмәт иттем. Ленин укыган университетны уңышлы тәмамладым. Урыс авылында бер марҗада фатирда яшәп, дуңгыз балалары белән бер бүлмәдә йоклап, мәктәптә өч ел буе тарих, урыс телен укыттым...

Сарьян ага, миннән тагын нинди сүзләр чыгуын көтеп, гаҗәпләнеп, күземә карап тора. «Күрше нигә кинәт кенә үз биографиясен сөйләргә тотынды?» – дип гаҗәпләнде, күрәсең.

Ә мин аңа «һөҗүмемне» дәвам итәм.

– Нигә минем бакча участогым булмаска тиеш? Мин бит авылда үскән малай. Бакча участогы алырга ярдәм итә алмассызмы икән?

Бу Сарьян агама көтелмәгән сорау иде. Күпмедер паузадан соң ул миңа:

– Мин бит мондый эшләр белән шөгыльләнмим, – диде. – Үзеңнең тәкъдимең нindirәк?

– Менә Язучылар союзына караган бакча кооперативы бар икән. Бу мәсьәләне хәл итүче – язучы Мөсәгыйт Хәбибуллин.

– Мин аны яхшы беләм. Ләкин мәсьәлә хәл ителер, дип гарантия бирә алмыйм. Шулай да, сөйләшеп карармын, – диде. – Әгәр минем генә көчем җитмәсә, тагын сиңа өстәмә ярдәмгә килерлек танышларың юкмы соң?

– Яшь язучылар арасында бергә университетта укыган, тулай торакта яшәгән иптәшләрем Рәдиф Гатауллин, Равил Фәйзуллин, Шамил Маннаповны әйбәт беләм, – дим.

Сарьян ага көлемсерәп куйды.

– Алар белән укуың яхшы булган... Ләкин элек үз көчебез белән генә тырышып карыйк әле.

Сарьян ага Мөсәгыйть Хәбибуллин белән очрашу сәгатен билгеләгәч, аның белән Язучылар союзына киттек.

Язучылар иҗат мәсьәләләрен чишкәндә бик озак сөйләшәләр. Ләкин Мөсәгыйт абыйның безнең йомышка карата сүзе бик кыска булды:

– Хәл итәрбез бу мәсьәләне, – диде, – ләкин бакча урыны кызыгырлык җир түгел. Ул урындагы җирнең уңышлы катламын бульдозер сыдырып, экскаватор белән үзбушаткыч машиналарга төяп, колхоз кырына ташыйлар. Аның астагы катламы –үзле кызыл балчык, төзү материалына чимал. Ул балчыкны якындагы Васильево поселогындагы заводка кирпеч ясарга ташыйлар. Шул ташландык җир инде ул. Кыскасы – карьер. Аны эшкәртү, билгеле, беркемгә дә җиңел булмас. Ләкин татар халкы авырлыкка түзем. Язучылар да моңа риза булып, бакчачылык эшен башлап җибәрделәр. – Ул, сынап, миңа карады.

Берничә көннән бакчачылык кооперативы рәисе Шаһи бабай белән карьер уртасында идек инде.

Авыл малае булсам да, шәһәр җирендә бакчачылык белән шөгыльләнә башлау моңа кадәр таныш булмаган яңалыклар китерде.

Билгеле, бу кызыл балчыкта берни дә үсмәячәк. Шуңа күрә, бөтен бакчачылар, күбесе татар зыялылары кырмыскадай мәш килә. Кемдер, төзү эшләрен башлаганчы, буласы йорт астына – балчык, ком, кайсылары, җиләк-җимеш, яшелчә үстерү өчен, якындагы урманнан капчык белән кара җир ташый... Чәй кайнатып эчәргә чиләк белән якындагы ишелеп барган йортлар да, агач баракларда яшәп, үзләренчә көн күреп ятучы урыс авылына суга баралар, якындагы сазлыктан дуен-ләм төяп кайталар.

Шулкадәр эссе көннәрдә 15-20 сәгать бертуктаусыз эшләсәләр дә, беркем дә зарланмый: эшли дә эшли. Хосусый милек шундый ул!

Мин дә бу кешеләр арасында. Беренче улыбыз Искәндәргә 3 яшь кенә әле. Ул диатез белән авырганга, аңа җәен күбрәк кояшта кызыну таләп ителә иде. Шуңа күрә еш кына җәйге эссе көннәрне үзен җилкәгә утыртып, капчыкка үзебезгә ашарга азык, шешә белән су алып, бакчага килә идем.

Шулай итеп, бакчачы булып киттем. Беренче елларны «Виктория» җиләген чиләкләп ташу бәхетенә ирештем, кишер, суган – үзебезнеке.

Әкрен генә тактадан кечкенә генә йорт та корылды. Төзү эшләрендә Рифкат, Мөнир, Ркаил үзләренең дус малайлары белән килеп булыштылар.

Шулай итеп гомер су кебек ага бирә.

Мин бу вакытта «Кызыл Шәрык» производство берләшмәсендә генераль директорның кадрлар буенча урынбасары идем.

1978 елның яңгырлы көзе иде. Авылларда урып-җыю эшләре бетмәгән. Арыш, бодайларның башаклары күп җирдә көндәлек җилле яңгырдан башларын аска игән. Шул көннәрне мине КПСС өлкә комитетының транспорт бүлегенә чакырып алдылар. Минем кебек чакырылганнар шактый иде монда.

Безне җыйдылар да республикада урып-җыю эшләренең бик начар баруы турында әйттеләр. Сәбәпләре күп инде: көндәлек яңгыр, районнарда кадрлар белән эшләү начар дәрәҗәдә, техникадан файдалану начар хәлдә... Элеватор янында ашлык төяп килгән машиналарның чираты зур. Мине Әгерҗе районына билгеләделәр.

Мин шул ук көнне 23 сәгатьтә Казан-Пермь поездына утырып китәргә җыендым.

Кичке, 7-8ләрдә юлга җыенып ятканда, безгә Сарьян ага килеп керде. Кулына таяк тоткан, үзе ак күлмәгенә кара галстук таккан, кара костюмнан. Кухняга узгач, Сарьян агадан сорыйм:

– Нигә болай таяк белән йөрисез? – дим.

Ул, кара мыегын акрын гына сыпырып:

– Кайбер яшүсмер бала-чагалар, эшкә аптырап, лифтта арлы-бирле шаярып йөриләр, шуларны кудым әле, – ди. – Аларга кисәтү ясамасаң, тагын да күбрәк шаярулары мөмкин. Ә син төнгә каршы кая болай юл тотасың?

Минем командировкага җыенганымны ишеткәч:

– Күпме вакытка китәсең? – дип сорады.

– Ун көнгә.

Ул шаярып кына әйтеп куйды:

– Шәригать кануннары буенча, командировкаң җиде көннән артса, никахны яңартырга кушалар.

Якында гына басып торган Рушания кинәт телсез калды, кызарып чыкты, әмма бу минутта әле үзендә берни дә әйтмәскә көч тапты.

Командировкага гомуми дәфтәр алырга теләгемне ишеткәч, Сарьян ага, өеннән алып чыгып, миңа дәфтәр бирде. Өйнең беренче катына кадәр озатып куйды.

Командировкадан соң бер-ике атна вакыт үтте.

Беркөнне иртән үк өстәге күрше Майоровның хатыны Люся ханым безгә бик борчылып килеп керде дә:

– Где Рая? – дип сорады.

– Әле генә институтка эшкә китте, – дим. – Нигә кирәк ул?

– Сарьянның хәле бик начар, – диде Люся.

Тиз генә аларга кердем. Сарьян аганың малае, идәнгә яткырып, әтисенә ясалма сулыш алдырыр өчен, авызына өреп азаплана. Сарьянның йөзе каралган.

Шул вакытта йортыбызның тугызынчы катында яшәүче табиб килеп керде дә, Сарьян аганың күз кабагын кулы белән ачып карагач, хөкемен әйтте:

– Булышырга соң инде, үлгән ул!

Хәсән Сарьянны соңгы юлга озатканда халык күп иде. Яшьли, бик яшьли китте ул. Югыйсә, тагын нинди гүзәл әсәрләр бирәсе иде халкыбызга... Татар зиратына килгәч тә мин аның табутын кемнәр беләндер кабергә кадәр күтәреп бардым.

«Үлем – күз белән каш арасында», – диләр бит. Сарьян аганың мине командировкага киткәндә озатып калуы соңгы күрешү булыр дип кем уйлаган!

Хәсән Сарьянның китүенә кырык көн үткәннән соң, аны искә алганда катнашкан Гариф Ахунов, Әмирхан Еники, Марс Шабаев, Мөсәгыйт Хәбибуллиннар аның хакында бик җылы сүзләр әйттеләр. ■

# ИСКЕ АЛЬБОМ ХАТИРӘСЕ

Рауза Хуҗәхмәтова

*Иске альбомны актарып, инде күптән онытылган фотографияләрне күреп алдым. Рәсемнәрдә – йа, Хода! – безнең мәшһүр җырчыбыз Әлфия Авзалова белән әтием Мингалим Хуҗәхмәтов! Яшь чаклары! Әтиемнең ул чакта Димитровградтагы (әүвәл Мәләкәс дип йөрткәннәр) үзешчән драма түгәрәгендә уйнап йөргән мәле. Менә алгы өлештә (рәсемдә, әлбәттә) ул вакытта ук мәшһүр җырчы апа утыра – яшь, матур хатын. Ниндидер кызыклы, мавыктыргыч әйберләр хакында сөйли. Аның тирәсендә – очрашудан шатлыклары йөзләренә бәреп чыккан һәвәскәр артистлар. Фотографиядә уң якта – минем әти, объективка туры карап төшкән – шулай ук яшь, каушауданмы, шатлыктанмы – йөзе балкый үзенең.... Апам сөйләвенчә, әти атаклы кунак апа белән «Башмакчылар» дигән мәгълүм музыкаль спектакльдән куплетлар җырлаганнар.*

Инде күптән булган хәл бит бу. Ул вакытта миңа ун яшь булгандыр. Бервакыт әти мине үзе белән ике көнлек сәфәр-сәяхәткә алды. Нindидер бер авылга барганыбызны хәтерлим. Анда коллектив белән чыгыш ясарга тиеш иде.

Җәйге җылы көндә кечкенә автобуста без озак бардык. Спектакльгә күп итеп реквизитлар алынган иде. Тирә-юньне күзәтүе кыен. Артистлар – төрле яшьтәге һөнәр ияләре. Эштән бушаган вакытта алар шулай төрле авылларга барып «кәнсирт-тамаша» күрсәтеп кайта иде. Нәрсә йөртте аларны? Әлбәттә, сәнгатькә мәхәббәт! Татар теленә мәхәббәт!

Алар автобуска утыруга, көлкеле-шаян җырлар җырлап җибәрәләр иде, кәефләре бер-берсенеке белән үтә тәңгәл килгән чакларда, күмәкләшеп, гөрләшеп сөйләшерләр иде...

Авылда безне нindидер бер агач йортка урнаштырдылар. Кече күңелле хуҗабикә апа миңа бакчага чыгарга һәм алмагачлардан алма өзеп алып ашарга тәкъдим итте.

Кичкә хәтле әле шактый вакыт бар иде. Без – әлеге сәфәр-сәяхәткә чыккан берничә бала – су буена барып, бер-ике сәгать чамасы сай суда йөзеп алдык. Аннары, тиз-тиз генә киендек тә, клубка йөгердек. Безнең янга авыл малайлары җыелды инде. Бу вакытта клуб эчендә спектакльгә әзерлек бара иде. Кемнәрдер сәхнә җиһазларын урнаштырды, кемнәрдер исә урындыклар һәм эскәмияләр белән мәш килде...

Клуб халык белән шыгрым тулды. Ул вакытта авылларга зур концертлар белән сирәк киләләр иде. Кинолар да еш күрсәтелмәде. Шуңадырмы, шәһәрдән үзешчән артистларның килүен зур бәйрәм кебек кабул итәләр иде.

Әүвәл спектакль күрсәттеләр, аннары артистлар, кием алмаштырып, концерт номерларын «әйттерергә» тотынды – җырладылар һәм шигырь укыдылар. Тамашачылар һәрбер чыгышны зур алкышлар белән озатты. Тамаша соң гына тәмамланды... Болар һәммәсе – хәтердә, һәммәсе – истә...

...Янә иске фотографиядәге үзешчән иҗади коллективка карап алам. Мин инде бу гаҗәеп кешеләрнең күбесенең исемнәрен хәтерләмим дә. Менә озын буйлы бер абый – яшь ир кеше. Аның тавышы көчле иде. Мин бу абыйны башкалар арасыннан бик тиз танып ала идем. Менә янә яшь ир кеше һәм бер чибәр хатын-кыз. Алар бергә спектакльдә уйнады, анда яшь кеше аңа «күгәрченем» дип әйтеп торды, ә бервакыт хатын-кыз, әйтәсе сүзен оныттымы, сәхнәдә бик озак сүзсез йөрде. Аннары, кинәт кычкырып: «Мостафа, минем Мостафа!» – дип, сәхнәдән йөгереп чыгып китте...

Менә бу апа кеше әти белән 1967 елда Куйбышевта Бөтенроссия смотры барган чакта күңелле куплетлар җырлады. Хәтеремдә, әтине беренче дәрәҗә диплом белән бүләкләделәр. Ә концертны исә телевизордан күрсәттеләр.

Чыгыш ясаучыларның куплетлары кызыклы булды. Әти өйгә кайткач, без аннан, ник концерт вакытында ясалма мыекларыңа еш кагылып алдың, дип сорадык. Ул, елмаеп, сөйләп бирде: «Мыекны концерт алдыннан ябыштырып куйган идем дә, җырлап җибәргәч, мыек куба башлады. Ләкин тамашачылар бу вак-төякләргә игътибар бирмәделәр, – диде ул. – Һәм безнең дуэтны кайнар алкышлар белән озаттылар!»

Артистлар баш иргә ике тапкыр чыкты. Истә калды, икенче тапкыр тамашачылар каршына чыккач, әти хәтерсез карт бабай кебек сәхнә артына чыгып китте дә, кинәт, атылып, спортчылар шикелле сәхнә алдына чыгып, башын иде.

...Хатирәләр, хатирәләр... Фотосурәтләрдә калган истәлекләр... Игелекле, шатлыклы, якты – барысы да әти-әниләр белән бәйле. Һәм әле дә истә. ■

Безнең мирас №4 апрель 2019

Фото followerinsta.com сайтыннан алынды

1980 нче еллардагы Багдад күренеше

# БАГДАДТАН ХАТЛАР[1]

Назыйм Мәхмүтов

*Түбәндә тәкъдим ителгән хатларны 1980 елда Гыйрак башкаласы Багдад шәһәреннән Казан университетының филология факультетына татар теле һәм әдәбияты бүлегенең өченче курсында укучы 1173 (476) нче группа студентларына Габделҗәмил Габделхак улы Зәйнуллин яза.*

*Ташкент дәүләт университетын тәмамлап, ике еллап Гыйракта илчелектә тәрҗемәче булып эшләгән Җәмил әфәнде Зәйнуллин 1977 елның июль аенда Казан дәүләт университетында гарәп теле укытучысы булып кайткан гына була. Тарих-филология факультеты җитәкчелеге аңа, шушы елда гына укырга кабул ителгән 476 нчы группага кураторлык вазыйфасын йөкли. Яшь белгеч шушы ук группада «гарәп теле» һәм «иске татар язуы» дәресләре дә алып бара.*

*1979 елда Гыйракта җитәкчелеккә Сәддам Хөсәен килә һәм Советлар Союзы белән болай да тыгыз экономик элемтәләр тагы да көчәя, бигрәк тә хәрби корал сату, оборона заводлары төзү активлаша. Меңәрләгән совет хәрби белгечләре Багдадта хезмәт куя. Менә шушы вакытта Җәмил әфәндене янәдән Гыйракка чакырып алалар. Ул укыткан студентлар исә өченче курска күчеп кенә кала. Гарәп, фарсы, төрек, үзбәк, рус һәм татар телләрен камил белгән белгеч югары бәяләнә, СССРның Министрлар Советы рәисе А.Н.Косыгинга яшь тәрҗемәченең эше бигрәк тә ошый.*

[1] Хатлардагы сүзләрнең язылышы, стиль, орфография өлешчә сакланды.

*Шулай итеп, Җ.Зәйнуллинның тагын ике елга планлаштырылган командировкасы башлана: СССР тышкы экономик элемтәләр буенча Дәүләт комитетының Гыйрактагы Баш инженерлык идарәсендә (ГКЭС ГИУ) эшли башлый. Хатлар менә шушы чорда язылган.*

**БЕРЕНЧЕ ХАТ (***1980 елның апрель ае***)**

«420073, Казань, ул.Аделя Кутуя, дом 2б, общежитие КГУ, комната №473, Махмутову Н.

Назыйм, исәнмесез! Үзегезгә һәм барлык группадаш иптәшләрегезгә күп итеп сәләм озатып калам! Сезгә, яңа ярты еллыкта зур уңышлар, өлгерешләр телимен!

Яңа чирекне нинди билгеләр белән каршыладыгыз? Имтиханнарыгызның нәтиҗәләре ничегрәк? Менә шулар һәм башка яңалыклар турында язып җибәрсәгез иде.

Үзегезнең старосталык эше ни төстәрәк? Кыенлыклар юкмы? Иптәшләрегез ярдәм итәләрме?

Безнең биредәге тормыш-күрмеш үз агымында. Көннәр эссе (+30 илә +35 җылылык), ком бураннары булып тора. Иң эссе көннәр июнь ае азагында һәм июль айларында булчак. Хәзердән үк эсселек сизелә. Монда да сездәге кебек үк укулар дәвам итә. Тагын бер ай ярымнан институтларда имтиханнар башланачак.

Эш җитәрлек күп. Вакыты белән бик күп – шулай да чыдарга була. Минем ниятем – әле сез укып бетергәнче кайтып җитү, биредә артык озак соткарланмау. Әлбәттә, миннән генә баглык[2] түгел, ә шулай булса да, ышанычым юк түгел. Монда, гомумән алганда, тынычлык.

Җәмил Зәйнуллин җитәкләгән 476 нчы төркемнең беренче курста укыган чагы

[2] Баглык – бәйле.

Группа хәлләре турында, үзегезнең үзгәрешләр турында хат язып җибәрегез. Равилнең[3] адресын алмаган идем, аңа да адресны бирерсез, хат язсын.

Хушыгыз. Түбәндәге адрес белән гади авиаконвертка салып, шул адреска хат юллагыз.

Багдад. Посольство СССР.
ГКЭС ГИУ.
Зайнуллину Ж.Г.»

## ИКЕНЧЕ ХАТ (*1980 елның июнь ае*)

«Назыймга Багдад каласыннан күп итеп сәләмнәр юллыймын.

Хатыңны алдым, рәхмәт. Группадагы хәбәрләрне белү күңелле булды.

Укуларыгыз турындагы юллар бик шатландырырлык түгел-түгелен, шулай да бөтенләй яман, дип тә булмый икән. Җәйге имтиханнарыгыз икәү генә булгач, барыгыз да булмаса да, күпчелегегез яхшы һәм бик яхшыга гына бирерсез, дип өметләнәм.

Сезнең Урта Азиягә бару планыгыз, ниятегез бар икән, аны бит миннән башка да алып баручы табылыр, бу мәсьәләне хәл итү мөмкин. Барыгыз да бара алмастыр барыбер, чөнки юлга шактый гына чыгым кирәк. Юл бәясен учебн. часть түли бугай һәм көнгә ничәдер тиен бирелә, өстәвенә, юлга фәкать поездга бирелә, эсседә поездда бару бик авыр, кайтканда, әлбәттә, поезд белән кайту кирәк, вак-төяк, җиләк-җимеш һәм күреп кайту үзе бер студент еллары хатирәсе булып калачак. Торак мәсьәләсен алдан кайгырту кирәк, ә билетны 40 көн алдан алу шарт, сезонда алулар бик авыр. Бу нәрсәне Фәһимә апа[4] белән сөйләш үзең, ә мин Диләрә апага[5] язармын. Әгәр инде хәзер бер эш тә чыкмаса, үзем кайткач, бәлки кышта, барырбыз.

Ж.Зәйнуллин җитәкчелегендәге группа Ташкент каласында. Рәсемдә: сулдан дүртенче – галимә Фәһимә Хисамова. 1981 ел

[3] Равил – группа студенты Равил Әхмәтшин.
[4] Фәһимә апа – галимә Фәһимә Хисамова.
[5] Диләрә апа – галимә Диләрә Тумашева.

Мин сез 4 курсны тәмамлаган чорда өйдә булырга телим, тик бу миннән генә баглы түгел, шулай да ышанычым бар. (Бару турында тагын бер-ике сүз: өчлесез укучыларны, активларны гына алып бару күздә тотыла – бу моментны истә тоту кирәк.)

Монда хәзер бик эссе (+40 һәм +45), ә соңрак 50нең өстенә менәчәк, быелны бик эссе булчак, дип сөйлиләр. Хәзер җиләк-җимеш мәүсимы[6] биредә: йөземнәр, миш-миш[7] һ.б.

Үзең киләчәк планнарын ничек күздә тотасың? Укуларны тәмамлагач, аспирантура турында уйламыйсыңмы? Нинди яңалыкларыгыз бар? Торак шартларыгыз ничек?

Иптәшләрегезгә сәлам әйт.

7 июнь, 1980 ел. Багдад.»

## АЧЫК ХАТ (*открытка арты*)

*«Тарих сәхифәсеннән: Гыйракның элеккеге, Һарун әр Рәшиднең төрек җариясеннән туган углы хакимлек иткән заманадагы башкаласы Самарра шәһәрендә корылган Мәльвия бормалы (спираль) манарасы. Багдад шәһәреннән 115 чакрым ераклыкта урнашкан бу шәһәрдә хәзер шәитләрнең изге имам мәчете урнашкан. Шәһәр елга буенда бик матур калкулыкта урнашкан. Манараның биеклеге 54 метр, баскычларының киңлеге аста 2 метр, өскә менгән саен тарая бара. Хәлиф шул баскычлардан атка атланып менгән, дип сөйлиләр».*



Самарра шәһәрендәге Мәльвия манарасы



ملوية سامراء (العراق)
Samarra' Spiral (Iraq)
Minaret Spirale de Samerra'a, (Iraq)

Тарих сәхифәсеннән: Иракның элеккеге, Һарун әр Рәшиднең төрек җариясеннән туган углы хакимлек иткән заманадагы башкаласы Самарра шәһәрендә корылган Мәльвия бормалы (спираль) манарасы. Багдад шәһәреннән 115 чакрым ераклыкта урнашкан бу шәһәрдә хәзер шәитләрнең изге имам мәчете урнашкан. Шәһәр елга буенда бик матур калкулыкта урнашкан. Манараның биеклеге 54 метр баскычларының киңлеге аста (2м) өскә менгән саен тарая бара. Хәлифләр баскычлардан атка атланып менгән дип сөйлиләр.

[6] Мәүсим – сезон, вакыт.

[7] Миш-миш – киш-миш булырга тиеш, йөземнең бер төре.

Җ.Зәйнуллин шәкертләренең бишенче курста укыган вакыты

1980 елның көзендә Гыйрак күрше Иранга һөҗүм итә. Бер көтмәгәндә башланган бу хәрби конфликт, беренче чиратта, совет җитәкчелегенең күңеленә хуш килми, чөнки С.Хөсәен бу гамәлен СССР лидерлары белән киңәшмичә башкара. Багдадтагы хәрби һәм башка белгечләр кире өйләренә кайтарыла, шул исәптән Җәмил абый Зәйнуллин да үз студентларының бәхетенә университетка кире кайтып, гарәп теле дәресләрен үзе дәвам итә. Бәхетенә, дим, чөнки, чит тел буларак укытыла торган гарәп теле буенча дәүләт имтиханы нәкъ дүртенче курста бирелә бит.

1977-1982 елларда Казан дәүләт университетында укыган студентлары филология фәннәре докторы, профессор Габделҗәмил Габделхак улы Зәйнуллинның йөзенә кызыллык китермәде. Югары категорияле укытучылар: Зөлфия Нәбиуллина, Галиябану Усманова (Сабирова), Фидания Фәләхетдинова (Леронова), Назыйм Мәхмүтов, Миләүшә Нигъмәтҗанова (Әбдерәшитова), Талия Мингалимова (Сафина), Резеда Заһидуллина, Камил Габдрахманов, Хәдичә Әхәтова, Рәзилә Гаязова һ.б.; журналистлар: Ирина Шәфыйкова (Апачаева), Фирая Нәгыймова (Моратова), Нәсимә Гәрәйшина (Фазлыева), Гөлшат Салихҗанова; илкүләм дәүләт эшлеклесе – Татарстан Республикасының Мәскәүдәге вәкаләтле вәкиле Равил Әхмәтшин, шагыйрә һәм мөгаллимә Гөлнур Гыйниятуллина (Айзатуллова), язучы Фирүзә Җамалетдинова; Татарстанның халык артисты Рәшит Сабиров, галимә Энҗе Вафина (Кадыйрова) – шушы төркем студентлары; халык хуҗалыгының төрле тармакларында хезмәт куйган Шамил Сабиров, Әмир Исмәгыйлев, Гөлнар Гәрәева, Гөлфирә Закирова, Фаиз Фәрхетдинов, Гөлнур Миһранова, Һидая Әхмәтҗанова, Минсәхрә Сафиуллиналар... Аллага шөкер, группадашларыбызның барысы да бүгенге көндә исән-сау! ■

# ТӨШЛӘРЕМӘ КЕРГӘН АЛМАНИЯ...

Гөлфия Дәүләтшина

*Язучы Нәби Дәүлинең язмышы бик күпләргә таныш. Аны «Яшәү белән үлем арасында», «Җимерелгән бастион» повестьлары, хикәяләре, шигырьләре аша хәтерлиләр. Ул һәр жанрны тигез күтәрә белде. Аның пьесалары, мәсәлән, бүген дә «Әкият» курчак театрында бара. Шулай ук Нәби Дәүлине Бөек Ватан сугышы юлларын үткән, Бухенвальд газапларын тәмугын кичкән хәрби тоткын буларак та беләләр. Ул 1941 елның августында Белоруссиядә әсирлеккә эләгә, 1945 елның апрелендә генә Алманиядә иреккә чыга.*

Гөлфия Дәүләтшина Н.Дәүлине ике ай тоткан элекке гестапо төрмәсе диварына куелган истәлек тактасы янында. Дармштадт шәһәре

Бухенвальд-Дора лагеренда күргән михнәтләре турында ул «Яшәү белән үлем арасында» әсәрендә тәфсилләп яза. Бу повесть концентрация лагерьлары һәм анда тамыр җәйгән Каршылык хәрәкәте турында язылган беренче татар әдәби әсәре булды. Китап гаять уңышлы чыгып, бихисап укучының күңелендә урын тапты. Бу әсәр лагерь тормышын сурәтләү белән генә чикләнмәде. Ул, гомумән, яшәргә, тормышны яратырга, авырлыклардан сынмаска, сыгылмаска өйрәтте. Китапның беренче басмасы 1957 елда дөнья күрде. Соңыннан аны берничә мәртәбә кабат нәшер иттеләр. Ниһаять, 2016 елда ул яңадан укучы кулына барып иреште. Алай да, моңарчы һичкемнең Нәби Дәүли эзләре буйлап Алманиягә барганы, әсәрдә урын алган вакыйгаларга бәйле документларны күргәне, өйрәнгәне юк иде.

Фәкать 2018 елда гына миңа, Казан мэры Илсур Метшин ярдәме белән, Алманиягә барырга, әтием һәм әдип Нәби Дәүли булган урыннарны күрергә, ул йөргән сукмаклардан узарга насыйп булды. Мәрҗани исемендәге Тарих институты директоры

урынбасары Марат Гыйбатдинов юлдашлыгында мин «Яшәү белән үлем арасында» исемле повестьта телгә алынган урыннарны яд иттем. Дармштадт шәһәренең гестапо диварын күргәндә җаным өзгәләнде (Нәби Дәүли ике ай буе мондагы төрмәдә тотыла). Әти әсирлектән качып котылырга омтылыш ясаган Люзовец авылында кичергән хисләремне бөтенләй әйтеп-аңлатып бетерерлек түгел. Әсирләр урман еккан Бад-Орб шәһәрчеге... Хәзер монда җәйге балалар лагере эшли икән. Кызганыч, вакыт кысканга күрә, Нәби Дәүли таш ваткан штольняларда һәм яшерен рәвештә «Фау» ракеталары эшләнгән мәгарәләрдә булырга, аларны үз күзләрем белән күрергә язмады.

Әтинең «Яшәү белән үлем арасында» әсәре Алманиянең һәр китапханәсендә бар икән. Бу хәбәр күңелемә сары май булып ятты. Магдебургтагы Әдәбият йортында Нәби Дәүлигә багышланган кичә узды. Биредә аның, соңгы 73 елда беренче тапкыр, татар телендәге шигырьләре, җырлары яңгырады. Алман, гарәп, көрд телләрендә

Бад-орб шәһәре янында урнашкан хәрби әсирләр өчен лагерь урынындагы урман. Н.Дәүли әлеге лагерьда урман кисүдә эшләгән

тәрҗемәләр укылды (аларны студентлар махсус шушы кичә өчен тәрҗемә иткән иде). Музыкантлар Әнвәр Ибраһимоглы һәм Мөҗтаб Фагхихинең чыгышлары чараны тагын да җанландырып җибәрде. Сурия рәссамы Иман Шәәбанның каллиграфик хезмәтләре күргәзмәсе ямь өстенә ямь булды. Кичәдә катнашучылар Нәби Дәүлинең авыр тормышына багышланган «Күзләреңә багам...» («Татарстан» телерадиокомпаниясе) фильмын да яратып карады.

Әлеге чаралар Фәннәр академиясенең Мәрҗани исемендәге Тарих институты һәм Алманиянең Кавказны, татарларны һәм Төркестанны өйрәнү институты (ИКАТАТ), Саксония-Анһальт җиренең LKJ оешмасы, «Татарлар – Дойчланд» (Берлин) ассоциациясе арасындагы хезмәттәшлек кысаларында үткәрелде. Җирле педагоглар, төбәк белгечләре, татар җәмәгатьчелеге, иҗтимагый оешмалар, музейлар белән уртак сөйләшүләр нәтиҗәсендә Нәби Дәүлинең иҗатын һәм тормышын өйрәнүдә алга таба да үзара ярдәмләшеп-булышып эшләргә килешенде. ■

# Истә, һаман да истә!

## *Журналист Шәмси Хамматовның тууына 100 ел*

Күренекле журналист, публицист, тарих фәннәре кандидаты, РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре Шәмси Хәбибулла улы Хамматов 1919 елның 14 апрелендә Свердловск өлкәсендәге Яңа Сергиевский районының Перепряжка (Аккүл) авылында ярлы крәстиән гаиләсендә туа.

Күрше Шәкүр авылындагы тулы булмаган урта мәктәпне тәмамлагач, Шәмси Хамматов Свердловск педагогия техникумында белем ала. Аннары кайчандыр үзе укыган Шәкүр авылы (Перепряжка (Аккүл) шушы авыл советына карый) мәктәбендә укыта башлый (1939).

1959 елда Казанда узган тәүге Татарстан Журналистлар съезды делегатлары аны үзләренең рәисе итеп сайлый.

1960 елның гыйнварыннан ул «Социалистик Татарстан» газетасының баш редакторы. Ул әлеге вазыйфаны 1983 елга кадәр башкара.

Шәмси Хамматов 1988 елның 21 ноябрендә вафат була.

## *Актриса Зәйнәп Камалованың тууына 120 ел*

Күренекле актриса, ТАССРның атказанган артисты (1957) Зәйнәп Галиәкбәр кызы Камалова 1899 елның 16 апрелендә Казанда туа.

Галиәкбәр ага һәм Мәүгыйзә апаның кызы Зәйнәп, Казаннан тыш, Әстерханда, Ташкентта яшәп ала, әлеге шәһәрләрдәге театрларда уйный.

1942 елдан – Татарстан Республикасы күчмә театры артисткасы.

1958 елда лаеклы ялга чыга.

Зәйнәп Камалова 1977 елда вафат була.

## *Сәясәт эшлеклесе Дулат Али Мәхмүтнең тууына 130 ел*

Журналист, сәясәт эшлеклесе Дулат (Дәүләт) Али Мәхмүт (Мәхмүт Габделвахит улы Алиев) 1889 елның 17 апрелендә Казанда мәзин гаиләсендә туа. Башлангыч белемне «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә ала. Якын дусты һәм туганы Хөсәен Ямашев йогынтысында революцион эшчәнлеккә бирелә.

1903-1905 елларда Мәхмүт үзе яшәгән йорт подвалында татарча листовкалар бастыра һәм халыкка тарата.

1905 елдан башлап ул Фатих Әмирхан җитәкләгән «Әл-Ислах» хәрәкәтенә катнаша башлый.

Беренче Бөтендөнья сугышы вакытында Дулат Али хәрәкәттәге армиядә катнаша, татарча чыккан «Султын сафа» («Фронт») газетасында редактор булып эшли. Күп язмалары «Чулпан» газетасында басыла.

1918 еда ул Казанга кайта һәм М.Вахитов оештырган Мөселман социалистик комитетына керә, шундук коммунистлар фракциясенең әгъзасына әйләнә.

1919 елның 11 июнендә Көнчыгыш халыкларының коммунистик оешмалары Үзәк бюросы карары белән Дулат Алины Кече Башкортстанга – Эстәрлетамакка җибәрәләр. 1920 елда башкорт авылы Аймакта ул әллә кулаклар, әллә анархистлар тарафыннан атып үтерелә.

Казанның Яңа татар бистәсендәге бер урам Дулат Али исемен йөртә.

## *Актриса Асия Галиеваның тууына 90 ел*

Күренекле актриса, педагог, ТАССРның халык артисты (1982) Асия Әмир кызы Галиева 1929 елның 25 апрелендә Татарстанның Баулы районындагы Кызылъяр авылында (Татарстан Республикасының халык шагыйре Фәнис Яруллин дөньяга килгән авыл) туа. Биографиясенә шулай дип язылса да, актриса бу авылны бөтенләй белми: «Бер мәртәбә Кызылъярга «Әни килде» спектакле белән кайткан идек. Авылга бик кызыксынып карадым. Әмма анда мине белмиләр. Шулай да заманында үзләренеке итеп танулары өчен бу авылга рәхмәтем зур. Таныклыкны 1946 елда, әнинең язуы буенча, гувернанткабыз Александра Ивановна алган».

Ул 1949 елда Шәхсәнәм Әсфәндиярова, Рәфкать Бикчәнтәев, Гәүһәр Камаловалар белән бергә Мәскәүдә ГИТИСның татар студиясен тәмамлый.

Асия Галиева – беренче татар актрисасы Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжскаяның сәхнә образын тудырган актриса. Спектакль 1963 елда Камал театрында куела.

Асия Галиева «Король Лир» (В.Шекспир) спектаклендә Корделия ролен башкара. Ул Хәлим Әбҗәлилов белән бергә уйнавына горурлана торган була. Асия Галиеваның кайбер рольләре:

Гайни – «Бәхетсез егет» (Г.Камал);

Гөлҗамал – «Гөлҗамал» (Н.Исәнбәт);

Зөбәрҗәт – «Хуҗа Насретдин» (Н.Исәнбәт);

Сәрби – «Качаклар» («Һиҗрәт», Н.Исәнбәт);

Әйшә – «Зифа» (Н.Исәнбәт);

Дилбәр – «Американ» (К.Тинчурин);

Айсылу – «Ташкыннар» (Т.Гыйззәт);

Беатриче – «Хатыннар гайбәте» (К.Гольдони) һәм башкалар.

А.Галиева 2018 елның 11 гыйнварында Казанда вафат була.

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Безнең мирас №4 апрель 2019

# БОРЫНГЫ ТАТАР МИЛЛИ МУЗЫКА УЕН КОРАЛЛАРЫ

### БЫРГЫ

Быргы иң элек музыка уен коралы буларак түгел, ә көнкүреш әсбабы сыйфатында барлыкка килгән. Әйтик, аучылар аның ярдәмендә кыргый җәнлекләргә, кош-кортларга охшатып аваз чыгарган. Хәрби максатларда быргы ерак араларга хәбәр җиткерү, гаскәр белән идарә итү өчен бик уңайлы булган. Көтүчеләр быргы аша авыл халкына көтү куу, көтүне каршы алу турында хәбәр җиткергән. Бүгенге көндә фольклор ансамбльләрендә быргыны музыка уен коралы буларак куллану киң таралган.

Халык иҗатында уен кораллары хакында төрле риваятьләр, әзер сюжетлар бар. Быргы турындагы берсе белән танышып үтик.

Борын-борын заманда Идел-Урал буйларында яшәгән, ди, аучы Мәргән. Көннәрдән беркөнне ул, сукмаксыз җирдән сукмак ясап, кыядан кыяга сикереп, ауга чыга. Шул вакыт кыя өстендә басып торган бик матур боланны күрә. Аның күркәмлегенә сокланып хәтта үзенең аучы булуын да оныта. Куллары гомерендә беренче тапкыр җәя белән укны читкә куеп, биленә кыстырылган быргыга үрелә. Мәргән каен тузыннан үзе төреп эшләгән шушы быргы аша болан белән «сөйләшә» башлый. Кешеләрдән куркып яшәргә күнеккән гүзәл җан иясе, сихерләнгәндәй, тораташ катып кала. Егет үзәк өзгеч моңлы көен өзеп, янына борылып караса, ни күзләре белән күрсен: боланнан җилләр искән. Аның урынына искиткеч чибәр кыз басып тора. Үзе кыенсынып кына елмая икән.

– Ник елмаясың? – дип сорый Мәргән.

– Шатлыгымнан елмаям, – ди кыз, гаять серле, ягымлы тавыш белән.

– Нинди шатлыгың бар соң?

– Мин бала чакта явыз патша илебезне басып алды. Урманга көч-хәл качып котылдым. Боланнар арасында үсеп, үзем дә сизмәстән, боланга әйләнгәнмен. Мине дәвалап та, өшкереп тә карадылар, файдасы тимәде. Илебезнең бер карты гына: «Бу кыз бала яңадан адәм сыйфатына кайтсын өчен аңа үзе яраткан батыр егет болан телендә хикмәтле сүз әйтергә тиеш», – диде. Бүген мин синнән шул сүзне ишеттем, батыр егет...

Аучылар өчен быргы – гаять кирәкле корал саналган. Ауның ни дәрәҗәдә уңышлы булуы аучының уйнау осталыгыннан торган.

Күренекле казакъ галиме Ч.Вәлиханов Себердә яшәүче төрки халыкларның мөгезгә охшаган «сырнай»да уйнавы, бу уен коралының көчле һәм ачы тавышка ия булуы турында яза. Халык арасында хәзер дә «ярык быргы кебек кычкырма», дигән гыйбарә очрый.

### АУЧЫ БЫРГЫСЫ

Аучы быргысын каен тузыннан ясыйлар. Яз көне, агачка сут төшкәч, ботаксыз, шома өлештән үткен пәке белән озын каен тузын спираль формасында телемләп

---

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2019) санында.

Сугыш быргысы

кубарып алалар. Ике ягын да яхшылап чистарталар. Каен тузының тышкы, ак ягы быргының эчендә калырга тиеш. Кубарып алынган кайрының калынлыгы әһәмиятле түгел, чөнки яз көне ул барыбер сыгылмалы, төрү өчен уңайлы була. Алдан әзерләп куелган конус сыман калыпка әлеге кисеп алынган кайрыны нәзек башыннан тыгыз итеп чорныйлар. (Бөгелгән зур мөгез формасында ясалганнары да очрый.) Чорналган җирдән таралып китмәсен өчен, кайрының икенче очын бәйләп куярга кирәк. Шул килеш берничә көн торганнан соң, калыпны тартып алырга була. Әзер быргының нәзек башына тавыш чыгару өчен сыбызгы киертеп куябыз.

Тавыш сыбызгысы шулай ук юка каен тузыннан ясала. Моның өчен 3х4 см каен тузы алына. Урталай бөкләнә. Бөкләнгән килеш өске ягы аз гына түгәрәкләнеп киселә.

Быргыны элек, ауланачак җәнлекнең яки кошның тавышына охшарлык итеп, төрле зурлыкта ясаганнар. Озынлыгы – 150-500 мм; сыбызгы өлеше беркетелә торган нәзек башының диаметры – 15-20 мм, ә икенче, юан башы 60-100 мм булган. Кирәгенә күрә быргыга 3-4 тишем тишкәннәр.

## КӨТҮЧЕ БЫРГЫСЫ

Әгерҗе районында мин сыер мөгезенә охшатып калайдан ясалган быргыда уйнаганнарын күрдем. Авыл көтүчеләренең сөйләве буенча, шундый ук быргыны элек сыер мөгезеннән дә ясаганнар. Тавыш чыгару җайланмасын (мундштугын) камышны, саламны яисә каз каурыен кыеклап телеп ясаганнар.

Мондый быргыны ясау өчен яшь сыерның мөгезе сайлап алына. Эче бик яхшылап чистартыла, шомартыла. Мөгезнең очлы башын эчке тишеме күренерлек итеп кисәргә һәм алдан әзерләнгән тавыш сыбызгысын тыгызлап киертеп куярга кирәк. Тавыш сыбызгысының үлчәмнәре сорнайныкына тәңгәл итеп ясала[1]. Билгеле бер

* Карагыз: «Безнең мирас», №3, 2019. Б.96-99.

Быргылар

тавыш югарылыгына көйләү өчен мөгезгә бер тишем тишәргә яисә тавыш ярысын беркеткән резина балдакны беркадәр күчереп йөртергә була.

Уйнаганда мөгезнең киң башын уң кул учы белән каплап-ачып төрле тавышлар, ритмик бизәкләр чыгарырга мөмкин.

Фольклор белгече Р.Халитов «Татарские народные духовые инструменты» дигән хезмәтендә көтүче быргысының тагын бер төре турында яза һәм аның үлчәмнәрен дә бирә. Ул 500-600 мм озынлыктагы калайдан конус сыман итеп ясалган. Киң башының диаметры – 90-110 мм, нәзек башының эчке диаметры – 15 мм. Нәзек башына, тыгыз итеп, кәтүк киертеп куелган. Уйнаганда иреннәрне кәтүк тишеменә терәп, өреп уйнаганнар. Тавыш тишемнәре булмаган.

### СУГЫШ БЫРГЫСЫ

Сугыш быргысы турында мәгълүмат бик борынгы истәлекләрдә очрый. VII гасырда Кубрат хан гаскәренең быргы кычкыртып, барабаннарда уйнавы мәгълүм.

Кол Гали дә «Йосыф белән Зөләйха» кыйссасында быргы һәм тагын күп кенә уен коралларының хәрби максатларда кулланылуы турында яза. «Идегәй» дастанында да, башка күп кенә халык авыз иҗаты әсәрләрендә дә хан гаскәренең быргы кычкыртып, давылбаз, барабан, дандалай сугып сугышка керүе сурәтләнә.

Безнең якларда очрый торган үгез мөгезеннән андый көчле тавышлы быргы ясап булмый. Гадәттә, андый зур мөгезләрне Дон буйларыннан яисә Кавказдан алып кайтканнар. Урта Азиядә, Төркиядә сугыш быргыларын төрле зурлыктагы металл калайдан да ясаганнар.

Без «Сорнай» ансамблендә уйнау өчен мөгездән эшләнгән сугыш быргыларын Кавказдан һәм Маҗарстаннан (Венгриядән) алып кайттык. Мондый быргыларның тавышы бик көчле түгел дә кебек, әмма ул 4-5 чакрымнан да бик ачык ишетелә. Татар халкы үзенең дәүләтчелеген югалтканнан соң, хәрби музыка уен кораллары кулланудан төшеп кала.

***Ринат Гыйләҗев,***
*«Сорнай» фольклор ансамбленең сәнгать җитәкчесе*

Дәвамы бар ■

# Тукай шигърияте безгә ник якын һәм кадерле?

Вахит Хаков

Тел-әдәбият галиме, тәнкыйтьче Җамал Вәлиди Тукай турында болай дигән иде: «Тукайның иң сөйдергән ягы, шөбһәсез, аның тел вә өслүбедер. Тукай кадәр җиңел вә тәкәлләфсез, шуның белән бергә аһәңле вә сәлис язучы шагыйрь әле һәнүз татарда килгәне юк. Давыт кулында тимер ничек балавыз кебек булып эресә, Тукай телендә татар теле шулай эри. Сөләйман падишаһка хайваннар вә пәриләр ничек мөсәххәр кылса, буйсынган булса, Тукай каршында татар сүзләре шулкадәр итагать белән баш ия». Бу шулай. Тукай – сихри моң иясе. Татар сөйләменең эчке яңгырашын ачык сиземләүче бөек шәхес ул. Татар әдәбияты һәм татар әдәби теле тарихында шагыйрь җуелмас эз калдырып китте, телнең гадилеген, матурлыгын һәм эчке серләрен ачып бирде, сүзнең көчен раслап күрсәтте. Тукай иҗатын үз чорыннан, татар халкы тарихыннан, иҗтимагый тормыш вакыйгаларыннан аерып

карау мөмкин түгел. Ул XX гасыр башындагы бөек шәхесләр – Гаяз Исхакый, Фатих Әмирхан, Дәрдемәнд, Сәгыйть Рәмиев, Галиәсгар Камал, Мәҗит Гафури, Галимҗан Ибраһимов, Шәриф Камаллар белән бер чорда яшәде, иҗат итте. Әмма татар теленең эчке хасыятләрен, нечкә төсмерләрен, татар халкының уй-кичерешләрен аеруча тоючы, рухи сиземләүче Тукай булды. Шагыйрь халык иҗатында гаҗәеп тел байлыгын, телнең камиллеген, халыкның осталыгын күрә. «Чын халык телен, чын халык рухын бездә тик халык җыруларыннан гына табып була», – диде ул. Тукайның телдән файдалану осталыгы шунда: аның тормыш күренешләрен, иҗтимагый хәлләрне тирән фикерли белүендә, әсәрләрен халык күңеленә керерлек итеп яза алуында, тел-сурәтләү чараларын урынлы һәм дөрес, максатка туры китерерлек итеп куллануында. Шигъриятне яңача алымнар белән баету, әдәби телне халыкчан итү, XX гасыр башында телдәге үзгәрешләр Тукай исеме белән тыгыз бәйләнгән. Шуңа күрә ул һаман да безнең белән атлый, безгә мәгънәви һәм зирәк киңәшләрен бирә. Әдәби телне халыкның җанлы сөйләм теленә якынайтуда, матур әдәбият һәм публицистика телен үстерүдә Тукайның башкарган эшләре бик зур. Үзенең әсәрләрендә ул телнең киң мөмкинлекләреннән файдалана, күренешләрне һәм вакыйгаларны сурәтләгәндә нәтиҗәле стиль алымнарын эшкә җигә. Тирән эчтәлекле һәм халыкчан әсәрләр шул җирлектә туа. Шагыйрь әдәби телне яңача юлга чыгарып, заман таләпләренә туры китереп, аңа киң үсеш юлы ачты. Тарихыбызда тел өлкәсендә гасырлар буе килгән уңай традицияләр, яңа тел чаралары белән кушылып, XX гасыр башында Тукайда бер ноктага җыелып, аңа киң гомумиләштерүләр ясарга мөмкинлек бирде. Ул әдәби телне халыкның җанлы сөйләме нигезендә үстерүне төп максат итеп алды. Тукай татар шигырь телен яңача үзгәртеп коруга ирешә. Һичшиксез, ул әдәби телнең язма традицияләренә дә тугрылыклы булып калды, җанлы сөйләмнең киң мөмкинлекләреннән дә дөрес файдаланды. Тукай яшәгән чорда әдәби телнең җирлеге тагын да киңәя, анда бөтен халык өчен уртак һәм бердәм нормалар үсеп чыга, әдәби телнең бөтен катламнарын да хәрәкәткә китергән киң күләмдә стилистик яңарыш башлана, яңа жанрлар мәйданга чыга, күптөрле тел-сурәтләү чаралары кулланышка керә. Бу үзгәрешләр сөйләмнең дөреслеге, ачыклыгы һәм гадилеге кебек төшенчәләр белән бәйләнгән һәм алар барысы да тел нормаларында чагылыш табалар. Матур әдәбият әсәрләренең теле эчтәлек һәм форма ягыннан тагын да байый. Тукай әсәрләреннән кайбер өзекләр:

*«Аерылып китсәм дә синнән, гомеремнең таңында мин,*
*И Казан арты! Сиңа кайтам тагын да мин.*
*Ул таныш кырлар, болыннар тартты әүвәл хиссеми,*
*Тарта торгач, куймады, кайтарды ахыр җисмеми...*
*Бу сәбәптән, аңладым мин, и туган җирем, синең*
*Җанга ягымлы икәндер ялкының да дулкының.*
*Җөмләтән изге икән ич: инешең, чишмәң, кырың,*
*Юлларың, авыл, әвен, кибәннәрең дә ындырың».*

Тукай телнең сүзлек байлыгы белән оста эш итә, сүзләрдәге мәгънә төсмерләрен дөрес куллана. Сүзләрнең күчерелмә мәгънәләрен куллану аеруча Тукайга хас. Ул: «Качасиде моннан, бу ямьсез тәмугтан», – дип, эшчеләрнең авыр тормышына, авыр эш шартларына ишарә итә.

Тукай, җәмгыятьтәге кимчелекләрне, аерым шәхесләрне фаш итү йөзеннән, еш кына сатирик тел чараларына да мөрәҗәгать итә. Сатирик нәтиҗә бер күренешне икенчесенә охшату нигезендә барлыкка килә. Охшату күп вакыт күчерелмә мәгънәдәге сүзләрдән тора. Мәсәлән:

*«Билгеле, һәрбер агачлар да корырга башлыйлар*
*Былбыл урынына оя тоткач башында каргалар».*
*(«Дин вә гавам»)*

*«Кисәрләр койрыгыңны, кермә былбыл читлегенә син».*
*(«Мөтәшагыйрьгә»)*

*«Табып мин шагыйремнең барча эшгарын карап бактым,*
*Укып чыктым бөтенләй буш нәзым, тозсыз шигырь таптым».*
*(«Урланган мәгънә»)*

Биредә таш йөрәк, койрык кисү, тозсыз шигырь, кара йөз, кара күңел кебек фразеологик чаралар күчерелмә мәгънәдә кулланылганнар.

Сатирик чагыштырулар да шундый ук фаш итү максатына ия булып торалар. Мисаллар:

*«Күрерсең син боларның йөргәнен һәрдәм коридорда:*
*Йөриләр карт кәҗәдәй, үзләрен анлар саный зурга».*
*(«Номерга төшкән искеләр»)*

*«Яшерми әйтегез миннән, китерми шөбһәне-шикне,*
*Мөхәррир, нашире кемдер, сыермы әллә ишәкме?»*
*(«Күрдегезме?»)*

Тукай шигърияте тел-сурәтләү чараларына, сәнгатьчә алымнарга бик бай. Ул бу алымнарның күп төрен, сүз уйнату, капма-каршы мәгънә тудыра торганнарын киң куллана. Тукай еш кына Көнбатыш һәм урыс әдәбияты вәкилләренә – Гейне, Байрон, Шекспир, Гёте, Пушкин, Лермонтов, Толстой, Крылов, Кольцов, Майков һ. б. га мөрәҗәгать итә, аларның әсәрләрен татарчага тәрҗемә итә, андагы мәгънәләрне милли җирлеккә күчерә, оригиналдан читкә китеп, аларга үзеннән дә күп үзгәрешләр кертә. Бу – шагыйрьгә әдәби телне яңа алымнар белән баетырга, башка әдәбиятлардагы тел-сурәтләү алымнарыннан иҗади файдаланырга мөмкинлек бирә.

Тукайның телгә карата гаять таләпчән булуын да әйтмичә узып булмый. Ул андагы мөмкинлекләрне дөрес һәм нәтиҗәле файдаланырга тырыша, кимчелекләре булуын да инкарь итми. «Ачы булгач күңелем, – дип яза ул, – шигырем дә ачы чыга, бәгъзан пешкән, дип уйласам да чи чыга». Шагыйрь тел бозучыларны, әдәбият бакчасын пычратучыларны туктаусыз чыбыркылап тора. Тукай үз иҗатындагы кимчелекләрне, тел кытыршылыкларын күрсәтә. «Уянгач беренче эшем» дигән әсәрендә үз үзенең халык теленнән ерак, чуар телдә язылган беренче шигырьләрен «чүпләрем» дип атый һәм шулардан арынуны үзенең төп максаты итеп күрә.

Җыеп әйткәндә, Тукайның әдәби телгә керткән өлеше күпьяклы һәм күпкырлы. Хәзерге әдәби телнең нигез ташларын салуда, XX гасыр башы татар шигърияте телен халыкның җанлы сөйләменә коруда ул зур эш башкарды. Шуңа күрә Тукай безгә бик якын һәм кадерле.

*20.04.200*

*Басмага* ***Рөстәм Фәйзуллин (Акъегет)*** *әзерләде.* ■

# *Татарстан Республикасының Милли китапханәсе*

## РАВИЛ ҮТӘБАЙ-КӘРИМИ ТУПЛАНМАСЫ

Үтәбаев Равил Алексеевич 1933 елның 30 августында Теләче районының Казаклар авылында туган. 1950-1952 елларда Мәскәүнең Шәрык институтында белем алган, аннан соң Казан дәүләт педагогия институтын тәмамлаган. 1956 елдан халык мәгарифе өлкәсендә эшләгән.

1988-1991 елларда ул – СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалында, Тел, әдәбият һәм тарих институтының өлкән фәнни хезмәткәре. 1992-1994 елларда ул – мәдрәсә ректоры, Россия һәм БДБнең Европа өлеше мөселманнары Үзәк диния нәзарәте Гыйльми шурасы әгъзасы була.

Равил Үтәбай-Кәрими күренекле гыйлем иясе, гарәп, шәрык, ислам белгече буларак, Шәрык халыкларының мәгърифәт тарихы буенча рус, татар, башкорт, үзбәк, казакъ, төрек телләрендә хезмәтләрен бастырды. Татарның танылган мәгърифәтчеләре һәм әдипләре Р.Фәхреддин, М.Гафури, З.Кадыйри мирасын барлап, китап итеп чыгарырга әзерләде. Исламның төп кагыйдәләре һәм тарихы турында белешмә басма төзеде. Равил Үтәбай-Кәрими 2005

Дәвамы. Башы журналның 2017 елгы 10 нчы санында.

елның 7 мартында Уфада вафат булды һәм Татарстанның Теләче районы Казаклар авылы зиратына җирләнде.

Р.Үтәбай-Кәриминең Милли китапханәбезгә бирелгән тупланмасы 600 нөсхә кадими һәм хәзерге заман басма китапларыннан тора. Татарның танылган дин һәм җәмәгать эшлеклеләре Р.Фәхреддин, Ф.Кәрими, К.Тәрҗемани, М.Бубыйларның култамгалы китаплары аерым бер кыйммәткә ия. Хәзерге чор басмаларыннан шәрыкны, исламны өйрәнүгә багышланган, гарәбияткә караган сирәк очрый торган китаплар, Коръәннең бик затлы нөсхәләре, күптомлы энциклопедияләр, чит тел сүзлекләре – болар бар да тупланманың байлыгын тәшкил итә. ■

# Ядкәрләр табыла

Назирә Фәттахова, Ләйсән Харрасова

*Узган 2018 елда республикабыз Милли музее фондында саклаучы Муса Җәлил мирасы тагын да тулыланды. Ул XX гасырның 50 нче елларында туплана башлап, бүген шактый бай мәгълүматны үз эченә ала. Әлбәттә, алар арасында шагыйрь үзе исән вакытта чыккан китаплар аерым бер урынны алып тора. 1925 елдан башлап сугышка киткәнче Муса Җәлилнең ун китабы дөнья күрә, шуларның берсе – рус теленә тәрҗемә. 1935 елда Мәскәүдә «Художественная литература» дәүләт нәшриятында басылып чыккан бу китапның тиражы нибары 3000 данә генә булу сәбәпләме яисә инде Мәскәүдә чыгуы роль уйнагандырмы, китап музей фондында бүгенге көнгә кадәр юк иде. Менә шушы басманы табу бәхетенә ирештек. Димәк, китапларның бездә тулы коллекциясе бар...*

М.Җәлилнең рус телендә чыккан шигырьләр җыентыгы

http://tatfrontu.ru/content/dzhalil-zalilov-musa-mustafovich

Муса Җәлил

Китап форматы буенча зур түгел, аңа Муса Җәлилнең 1926-1933 еллар аралыгында язылган 19 шигыре кергән. Аларны рус теленә Александр Миних тәрҗемә иткән. Заманында китап тәнкыйтьчеләр күзеннән дә читтә калмаган. «Художественная литература» журналының 9 нчы санында (1935 ел) тәнкыйтьче С.Гамаловның «Мәхәббәт һәм хезмәт лирикасы» дигән мәкаләсе басыла. Китапка рецензиядә мондый юллар бар: «...татар поэзиясе – идея-сәнгать үсешенең ачык мисалы.

Муса Җәлил шигырьләренең кечкенә китабы совет укучысына үз эченә нык ихтыяр көчен йомшак лирика, бөек ачуны назлы мәхәббәт белән тәңгәлләштерүче чын шигърилеге белән зур шатлык китерәчәк».

Китапның титул битенә штамп сугылган. Әлеге китап саклаган кешенең сүзләренә караганда, бу – репрессияләнгән грузин шагыйре Никола Мицишвили (1896-1937)

китапханәсен дәлилләүче штамп. Димәк, грузин шагыйренең шәхси китапханәсендә Муса Җәлилнең шигырьләр китабы сакланган.

Әлеге китапка шагыйрьнең «Махнога каршы» дип исемләнгән шигыре кертелгән. Күрәсең, әлеге шигырь заманына күрә популяр булгандыр. «Безнең юл» әдәби, гыйльми, иҗтимагый айлык журналының 1929 елгы сигезенче санында бу шигырь «Авыру комсомолец» шигыреннән өзек дип бастырылган, музей фонды шушы журнал белән дә баетылды. Белгәнегезчә, «Казан утлары» журналының тарихы нәкъ менә әлеге журналга барып тоташа. «Безнең юл» журналы 1920 елда чыга башлый. Ул алга таба «Яңалиф», «Атака» исемнәре белән нәшер ителгән. Алар башлаган эшне «Совет әдәбияты» дәвам итә. Хәзер ул – «Казан утлары» журналы.

«Авыру комсомолец» («Үткән юллар») – Муса Җәлилнең яратып эшләгән поэмаларыннан берсе. Бу поэманың берничә кулъязмасы – варианты бар. Шагыйрь әлеге поэманы беренче тапкыр 1924 елның июлендә тәмамлаган булса да, еллар үткән саен аңа яңадан әйләнеп кайтканлыгы һәм кабаттан эшләгәнлеге мәгълүм. Ул шагыйрьнең беренче җыентыгында «Авыру комсомолец» исеме белән урын алган («Барабыз», 1925). Җыентык шул поэма белән башлана. «Орденлы миллионнар» (1933) җыентыгында әсәр «Үткән еллар», ә 1934 елгы «Шигырьләр һәм поэмалар» җыентыгында «Үткән юллар» исеме белән басылган һәм поэмадан соң: «Бу шигырь 1924 елны «Авыру комсомолец» исемендә язылган иде. 1928 елны төзәтелеп, арттырылып, яңадан эшләнде. М.Җ.», – дип, искәрмә язылган.

Әсәрнең популяр булуы шагыйрьнең сеңлесе Хәдичә Җәлилова истәлекләреннән дә күренә: «Бервакыт абый мине студентлар кичәсенә алып китте. Без килгәндә инде концерт башланган иде. Озакламый конферансье:

– Залда безнең сөекле шагыйребез Муса Җәлил утыра, тамашачылар исеменнән мин аның «Авыру комсомолец» поэмасыннан өзекләр укуын сорыйм!.. – диде.

Зал дәррәү килеп шаулый башлады, барысы да кул чабалар, абыйның сәхнәгә күтәрелүен сорыйлар. Муса абый сәхнәгә менде. Шундук Маһирә Рәхимова исемле студентка рояль янына килде һәм аккомпанировать итәргә әзерләнде.

Муса абый «Гибель титаника» вальсы астында поэманы укыды...» (Х.Җәлилова. Абыем турында. – К., 1976. – 47 б.)

Музей фондын баеткан тагын ике экспонат турында язып үтәсе килә. Беренчесе – «Безнең яшьләр» шигырьләр, хикәяләр, очерклар китабының 1944 елны Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан сигнал саны. Әлеге китап Ленин комсомолының 25 еллыгына әзерләнгән, мөхәррире – Фатих Хөсни, төзүчесе – Әхмәт Юныс. Китапка, фронтовик язучыларыбыз: Фатих Кәрим, Хәйретдин Мөҗәй, Нур Баян, Нәби Дәүли, Шәйхи Маннур, Гали Хуҗи, Габдрахман Әпсәләмов, Кави Нәҗми һәм башка язучыларның әсәрләре белән бергә, Муса Җәлилнең «Хуш, акыллым», «Окоптан хат», «Күпер» дип аталган шигырьләре дә кертелгән. Бу – шагыйрьнең фронт лирикасы. «Хуш, акыллым» шигыре беренче тапкыр 1943 елны чыккан «Тупчы анты» җыентыгында 9 сентябрь 1941 ел датасы белән басыла. Әсәрнең Муса Җәлил хәрбисәяси курсларда укыган чакта, Марьинода 11 августта ук языла башлаганлыгы мәгълүм. Ул тулы килеш 9 сентябрь датасы белән Әминә Сәйфуллинага җибәрелгән кульязма буенча бастырыла.

Икенчесе – «Совет әдәбияты» журналының 1939 елгы өченче, дүртенче саннары. Анда Муса Җәлилнең «Атынчәч» либреттосының өч картинасы бастырылган. «Атынчәч» операсы либреттосының әдәби варианты аерым китап булып Татарстан дәүләт нәшриятының матур әдәбият секторында 1941 елны бастырыла. Китапка кереш




«Совет әдәбияты» журналы. Казан. 1939 ел

«Безнең юл» журналы. Казан. 1929 ел

1929-nсь jьl, AUGUS 8 san

# Bzneꞑ jul

Ədəʙi, ƣilmi-içtmaƣi ajlьq zurnal

**Ridaksiə adrise:** Qazan, Astrovski uramь, jort 10.

## Maxnoƣa qarşь...

Musa Çəlil şiƣrь.

(*„Auru komsomolis“ şiƣrnnən ɵzek*)

Maxno ʙanda çiƣan; Maxno ʙzgə,
Sovit jɵrəgenə suzьla.
Komsomollar!.. Jəgez, szneꞑ tauьş:
Çavap ʙiregez şunьꞑ yzenə.

———

Çiʙьş ide...
Kamʙat jɵrəgnnən
Cqqan tauьş ʙlən endəşte:
— Jə, jgtlər!..
Front!..
Kem jazьla!
Kem il ɵcen qurqmas kɵrəşce?..
Bez ʙarьʙz da ʙiton kykrəklərdə
Eş ʙietep yskən jgtlər,
Bez ʙləʙez: Maxno ʙzneꞑ eşne
Msqьl itep, taptar, kɵl itər.
Bez ʙləʙez: aqtьq snqlarnь
Tartьp alьp Maxno ʙandasь
Nəni ʙalalarnь qanƣa turьj,
Xatьn-qznь satlьq mal jasьj...
Kem jazьla!..
Çiʙьş ʙik azƣna
Tnьp torƣac kamʙat qarşnda
Qul kytərde
— „Urrra!..“ jaꞑƣьratьp,
Bar da, ʙar da... ənə, ʙarsь da...
Brəm, ʙrəm kilep sikritarƣa
Jazьlalar!..
Kamʙat quana...
Arqaʙzdan qaƣa... krfkləren
Jarsьp cqqan jəşlər jualar...
Kəçə ʙətie tɵsle jaꞑa ƣna
Kyzen acqan jəp jəş malajlar
Srƣa tɵsle tzep patrun taqtьq,
Bilgə eldek ʙumʙa, nagannar.
Jartь kəçə tunnь kiep alьp,
Salьnьp tɵşkən çiꞑne szƣanьp,
— Bez jəş guardiə...
Çrlьj, çrlьj
Maxnolarƣa qarşь quzƣaldьq...

———

Bznekelər şajan. Paxotta da
Talian garmun ʙlən əşnələr.
Ə, ut acqac, doşman saflarьna
Ut jomƣaƣь ʙulьp jəşnərlər...

* * *

Ut acldь.
Ə ʙez alƣь safta
Kykrək ʙlən çirne qocaqlap,
Kyzlər ʙlən tɵten jarьp,
Omtьlaʙьz utlь ucaqqa.
Bzneꞑ saflar qorьc. Komandirdan
Prikaz kɵtə janьp, qaranьp.

———

Prikaz tygel, kinət xəʙər kilde:
„Baş komandir auьr jaralь“.
Doşman pule kilep komandirnьꞑ
Taş kykrəgen qannan jalatqan.
Ə qorьc saf ytken ʙɵrket tɵsle
Prikaz kɵtə ʙatьr kamʙattan.
Ştiklarda ocqьn ujnьj tɵsle,
Qannar taşa tɵsle tamrda.
Ətrət qzƣan:
Davaj, davaj prikaz!!
Prikaz davaj, alƣa ʙarrƣa!!.

———

Kamʙat torьp, auьr ьnƣьraşьp
Akup qrьna totndь.
Qanƣa tuzƣan kymgək qulь ʙlən
Prikazƣa suzьlьp qul qujdь.
Kyzen tutьrьp qarap duslarьna:
— „Çiꞑegez...“ dide,
Yze ʙuьnnda
Xəle ʙtep, soꞑƣь kɵce ʙlən
Tartьşa, tartьşa audь urnьna...

* * *

Prikaz əzer.
Batьr kommunarlar,
Pritsilne turь alьƣьz.
Ştiklarnь iple kytəregez,
Jəşen tɵsle alƣa ʙarьƣьz.

———

Taꞑ jaqtьra inde...
Borƣь ujnьj...
Doşman tuʙь cəcəp jytkerə...
Bez çiꞑərʙez,
Bezgə prikaz ʙar,
Jə, ʙɵrket jau, kɵcne ytkrləl..
Taꞑ jaqtьra...
Duslar ʙez çiꞑərʙez,
Bez çiꞑər kɵn uttan jasala...

———

Ə komandir ylem tyşəgndə
Kykrəgnnən ərnep qan sava...
Soꞑƣь tamrь tiʙə jaꞑaƣnda,
Irne kiʙə, təne suьna...
Yze haman ʙzgə prikaz ʙirə,
Alda taƣьn çiꞑy turnda...

* * *

Taꞑ szldь...
Ətrət ʙəjrəm itə...
Ətrət çiꞑde... çiꞑde... ʙez çindek...
Ə komandir taꞑnь kɵtə almadь,
Ə komandir ylde...
Ɵzlde...
. . . . . . . . . . . . . . . .
. . . . . . . . . . . . . . . .

*Musa Çəlil.*

сүздә Муса Җәлил үзе болай дип яза: «1939 елда бу либретто белән РСФСР ның атказанган сәнгать эшлеклесе, алдынгы совет татар композиторы Нәҗип Җиһанов кызыксынып, аның буенча опера язарга теләген белдерде. Әсәрнең авторы, композиторның киңәшләрен күздә тотып, «Атынчәч» либреттосын яңадан бер кат ныклап эшләде һәм күп кенә үзгәртүләр, төзәтүләр кертте. Шулай итеп, бу либреттоның берничә төрле варианты барлыкка килде.

Укучының игътибарына тәкъдим ителгән бу әсәр – либреттоның соңгы варианты».

Күрәсез, китап басылып чыкканчы, либреттоның беренче варианты укучыларга журналда тәкъдим ителгән була.

Ә «Совет әдәбияты» журналына килсәк, шагыйрь аны Мәскәүдә яшәгәндә дә алдыра. Әдипнең Муса Җәлил музей-фатиры мемориаль экспозициясендәге шәхси китапханәсендә журналның 1938 елгы барлык саннары да бар.

Менә шулай музей фондының тупланмалары һәр елны тулылана бара. Алар теге яки бу шәхесне төрле яклап – тормыш юлы, иҗаты һәм хәтта характеры ягыннан да ачарга ярдәм итә. Ә без, музей хезмәткәрләре, алга таба да яңа мәгълүматлар табылыр, тупланмалар баетылыр, дигән өметтә калабыз. ■

Безнең мирас №4 апрель 2019

# «Иске Казан» дәүләт музей-тыюлыгы

*2010 нчы еллар башында «ТАТТЕЛЕКОМ» АҖ генераль директоры Лотфулла Нурислам улы Шәфигуллин һәм аның җитәкчелегендәге хәйриячеләр ярдәме белән Биектау районындагы «Иске Казан дәүләт тарих-мәдәният һәм табигать музей-тыюлыгы»нда берничә объект яңартып төзекләндерелде. Шуларның берсе – Камай авылындагы музей биләмәсендә XIII-XVI гасырлардагы Иске Казан шәһәренең тарихи реконструкциясе. Ул үз эченә саклану кирмәнен, капканы, күзәтү манараларын, хан сараен, саклану һәм һөҗүм итү коралларын, һөнәрчелек комплексын берләштерә.*

# МАРТ

Фотолар һәм видео beznenmiras.ru сайтында

● Март башында язучы Ринат Нуруллинның курай ясау остасы Рафаэль Гайзетдиновка нисбәтле «Курайлар дөньясында» дигән китабы дөнья күрде.

● 1 мартта Кукмара район Мәдәният йортында районның Әфган сугышын кичкән кешеләренә багышланган «Памяти достойны... 1979-1989» дигән китапны тәкъдим итү кичәсе булды.

● 1-2 мартта Калининград шәһәрендә һәм өлкәсендә каһарман шагыйрь Фатих Кәримнең тууына 110 ел тулуга багышланган чаралар узды.

Чараларда Татарстаннан күренекле язучылар, галимнәр һәм Фатих Кәримнең кызы Ләйлә ханым катнашты.

● 5 мартта күренекле фотограф Шамил Абдюшев вафат булды.

● 6 мартта төбәк тарихчылары Теләченең Туган якны өйрәнү музеена чираттагы очрашуга җыелды.

Очрашуны «Туган якны йөрәнү» музее җитәкчесе Фаягөл Имамиева ТАССРның 100 еллыгы уңаеннан районда эшләнгән күргәзмәләр, чаралар белән таныштырудан башлады. Олы Нырсы авылыннан Нурания Гыйльметдинова исә «Йөз ел элек» дип исемләнгән чираттагы китабының язылу тарихын сөйләде.

● 7 мартта IV Бөтенроссия ЮНЕСКО кафедралары конгрессының пленар утырышы үтте. Анда Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе, ЮНЕСКОның мәдәниятләр арасында диалог буенча махсус илчесе Минтимер Шәймиев, алдагы 3-4 елга планлаштырылган алты полилингваль комплексларның беренчесе укучыларны 2020 елның 1 сентябрендә кабул итәчәк, дип белдерде.

● 12 мартта тарих фәннәре докторы, Татарстан Фәннәр академиясенең шәрәфле әгъзасы Әгъдәс Борһановның китаплары (меңнән артык басма) һәм шәхси әйберләре ТР Фәннәр академиясенә тапшырылды.

● 19 мартта «Идел» журналы Сабада, яшь шагыйрә Илмира Гыймаеваның «Апрель күгеннән йолдыз каплаган» дип исемләнгән шигырьләр шәлкеменә бәйле рәвештә, әдәби суд оештырды. Казый ролендә – К.Кәримов, гаепләнүче – И.Гыймаева, гаепләүче – Р.Сәлах һәм гаепләүче ягыннан шаһит – М.Закир, яклаучы – Г.Бәйрәмова һәм яклаучы ягыннан шаһит – Л.Лерон.

● 20 мартта Ульяновск өлкәсендәге Иске Кулаткыда меценат Эдуард Әнвәр улы Ганиев истәлегенә багышланган «XIX нчы Кулаткы укулары» дигән чара үтте.

● 21 мартта Татарстан Язучылар берлеге идарәсенең чираттагы утырышы узды. Утырышта кайчандыр тукталган һәм хәзер яңартылган М.Горький исемендәге әдәби премиягә кандидат итеп урыс телендә иҗат итүче язучылар Лев Кожевников һәм Айрат Бик-Булатов тәкъдим ителде. Рамил Ханнанов, Айсылу Имамиева һәм Николай Сорокин Татарстан Язучылар берлегенә әгъза итеп алынды.

● 22 мартта Татарстан Милли китапханәсенең Зур уку залында Татарстанның халык шагыйре Разил Вәлиевнең 2019 елда Татарстан китап нәшриятында дөнья күргән 7 томлыгын тәкъдим итү чарасы үтте.

● 22 мартта Г.Тукай исемендәге Әтнә дәүләт театры «Безнең шәһәрнең серләре» дигән спектакльнең (Г.Камал әсәре) премьерасын күрсәтте.

● 22-23 мартта Габдулла Кариев исемендәге Казан Татар дәүләт яшь тамашачы театрында Баулы, Яшел Үзән, Арча, Зәй, Мамадыш, Нурлат, Менделеевск, Ютазы һәм Уфадан килгән коллективлар драма һәм курчак спектакльләре номинациясендә көч сынашты.

● 25 мартта Язучыларның Г.Тукай исемендәге клубында күренекле шагыйрә Нәҗибә Сафинага 70 яшь тулуга багышланган әдәби-музыкаль кичә булып узды.

● 28 мартта Г.Кариев исемендәге Казан Татар дәүләт яшь тамашачы театры ТРның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Камил Кәримовның «Шәй-бу! Шай-бу!» комедиясе (режиссеры – Р.Эюпов) премьерасын тамашачыларга тәкъдим итте. ■

# Мирасворд

Коръән сүрәсе

Нигез, төп (иск.)

Такташ, Атласи

Афәт килгәнен белдергәндә кага торган барабан (иск.)

Бакый …

Дагыстанда яшәүче төрки халык

Җөмләнең иярчен кисәге

Шагыйрь Госман …

«Афәт» трилогиясе авторы

К.Кәримов романында – сакау, З.Һәким драмасында - телсез

Ыргыту, ташлау

Фарсылар патшасы

XX йөз һинд әдибе

Композитор … Даутов

Борынгы Русьта халык җыелышы

Беренче хатын-кыз космонавт

Фатих Кәрим туган авыл

Трахома (иск.)

Гарәп артикле

Беренче совет автомобиле

Япон чиясе

Хафизова, Туфитулова

Әмирхан, Сәйфи-Казанлы

Зыя Ярмәки шигыре

Улан-…

Дөя сөтеннән ясалган кымыз (диал.)

Утта яндырылган итальян фәлсәфәчесе һәм шагыйре

Арыш ипиен кызарганчы киптереп, шуннан ясалган әчемлек

Драматург … Хәмид

Наполеон сугышында катнашкан рус генералы

Габдулла Тукайның 1909 елда язган шигыре

Атнаның бер көне

Шагыйрә … Булатова

… Гыйләҗев



Киндер сукканда кыстырыла торган җеп

…-чабы чыгу

«…-йолт» (1910-1918 елларда Казанда чыккан журнал)

Сәгыйть Рәмиев шигыре

Сирин поэмасы

Татар шагыйре, җәлилче

*Рәис Габдулла төзеде.*

**3 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:**
**Сулдан уңга:** Рәшидә, Бари, Лена, «Ватан», Әҗәл, Леоне, ымлык, богыл, ирән, Раев, ал, Луи, Гомәр, Чехов, алпар, чулпы, Баттал, Наум, Карл, илот, Ык, Швейк, юкса.
**Өстән аска:** Флорид, ау, Дунаев, Нобель, лар, Арсланов, Апулей, Гете, очлым, ашина, «Пе», иравыл, Бах, ода, агора, Әбҗәлилов, җыр, аталык, әкәмәт, Окс, иләт.

# «Безнең мирас» елъязмасы /апрель

**100 ел элек (1919)**

«Кызыл Армия газетасында С.Сүнчәләйнең «Җиһад» (Пушкинның «Ода вольности» шигыренә тәкълид) исемле шигыре басылып чыга.

**100 ел элек (1919)**

Танылган трагик артист Мохтар Мутин бенефисына азәрбәйҗан революционеры һәм язучысы Нариман Наримановның «Надиршаһ» трагедиясе куела (М.Мутин постановкасы, режиссеры – К.Тинчурин).

**100 ел элек (1919)**

Казандагы укучы яшьләрнең «Берек» оешмасы Г.Тукайны искә алу кичәсе оештыра.

**95 ел элек (1924)**

«Сулф» Һ.Такташка багышланган диспут уздыра. Футурист Ризванов шагыйрьнең иҗаты турында доклад ясый.

**90 ел элек (1929)**

Татар дәүләт академия театры бинасында драматург Галиәсгар Камалның 30 еллык әдәби хезмәт бәйрәменә багышланган кичә үткәрелә.

**85 ел элек (1934)**

«Правда» газетасы Халык Комиссарлары Советы тарафыннан 1933 елның февраль аенда иң яхшы пьесага ачылган конкурсның нәтиҗәләре турында хәбәр итә. Бүләкләнгән әсәрләр арасында Ш.Усмановның «Рупор» исемле пьесасы да бар (III урын).

**80 ел элек (1939)**

Татарстан Республикасының Халык иҗаты һәм мәдәни-агарту эшләре фәнни-методик үзәге оештырыла (1979 елга кадәр Республика Халык иҗаты йорты дип атала, 2011 елдан – Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге).

**75 ел элек (1944)**

Ш.Мөдәрриснең «Тупчы Ваһап» исемле шигырьләр һәм поэмалар җыентыгы басылып чыга.

**50 ел элек (1969)**

Шагыйрь һәм прозаик, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, «Кояшлы төн» (2005) дигән бердәнбер шигырьләр китабы белән киң танылу алган, 1999 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы булган Марат Закир (Марат Хәлил улы Закиров) дөньяга килә. Каләмдәшебезне гомер бәйрәме белән ихластан котлыйбыз һәм аңа иҗади озын гомер телибез!

**50 ел элек (1969)**

ТАССР Министрлар Советы карары нигезендә Болгар дәүләт тарихи-архитектура музей-тыюлыгы оештырыла.

*Журналга **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

## СОДЕРЖАНИЕ. АПРЕЛЬ 2019

**И останется в мире слово моё…:** Габдулла Тукай.

**Историческое наследие:** «Сююмбике». О.Иванова; «Всеобщая история тюркских народов». Х.Габаши; «Род Тарджеман-аль-Анджераи». А.Назми; «Тукаевские конфеты». Л.Муртазина; «Тукай в документах жандармерии». Л.Гайнанова; «Татары и Грузию спасли». А.Галимзянов.

**Татарский мир:** «Две победы учёного». Ф.Садриев; Накип Каштанов: «Мы – загадочный народ».

**Религиозное наследие:** «Исламский мир». Габдурашит Ибрагимов.

**Литературное наследие:** «Стихотворения Бики Рахимовой»; «Гаффаризмы». А.Гаффар.

**В глубине памяти:** «Соловей Татарстана». А.Файзрахманов; «Мой сосед Хасан Сарьян». Ф.Якупов; «Письма из Багдада». Н.Махмутов; «До сих пор в памяти!».

**Художественное наследие:** «Древние татарские музыкальные инструменты». Р.Гилязев.

**На страже памяти:** «Национальная библиотека Республики Татарстан»; В музее-заповеднике «Иске Казан» («Старая Казань»).

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

## CONTENT. APRIL 2019

**There will be left my word in the world…:** Gabdullah Tukay.

**Historic heritage:** «Suyumbike» by O.Ivanova; «General history of Turkic people» by Kh. Gabashi; «The kin of Tardjeman-al-Andjerai» by A.Nazmi; «Tukay's sweets» by L.Murtazina; «Tukay's name in the documents of gendarmerie» by L. Gaynanova; «The Tatars rescued even Georgia» by A.Galimzyanov.

**Tatar world:** «Two victories of the scientist»; Nakip Kashtanov: «We are mysterious ones».

**Religious heritage:** «Islamic world» by Gabdurashit Ibragimov.

**Literary heritage:** «The poems of Bika Rakhimova»; «Gaffarisms» by A.Gaffar.

**In the deepest store of memory:** «The nightingale of Tatarstan» by A. Fayzrakhmanov; «My neighbour Khasan Saryan» by F.Yakupov; «The letters from Bagdad» by N.Makhmutov; «Still keeping in the memory, still keeping!».

**Creative heritage:** «The ancient Tatar national musical instruments» by R.Gilyazev.

**On the guard of the memory:** «The National library of the Republic of Tatarstan»; «In the preserve-museum «Iske Kazan («Ancient Kazan»)».

The magazine constantly brings to light all the most important events of our nation's life.

«Н.Кузнецов портреты»
(рәссам Виктор Федоров эше)

# Николай Кузнецов

Рәссам Николай Дмитриевич Кузнецов 1923 елның 22 маенда Татарстан Республикасының хәзер Яшел Үзән районына кергән Васильево бистәсендә туа.
1945 елда Казан рәсем сәнгате училищесын тәмамлый. 1950 елда СССР Рәссамнар берлегенә кабул ителә. Татарстанның һәм Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе (1957 ел), Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты (1971 ел). Казанда яшәп һәм иҗат итеп, 1974 елда вафат була.

**«Казанның үткәне һәм хәзергесе».** 1972. Киндер, майлы буяу

**«Яз кояшы».** 1958. Киндер, майлы буяу

**«Казан Кремле».** 1955. Киндер, майлы буяу

## АЛДАГЫ САНДА УКЫГЫЗ:

Дуслар-каләмдәшләр: сулдан – Ризван Хәмид, Фаил Шәфигуллин, Зөлфәт.

«Әгәр Фаил исән булса...» (Эльмира Шәрифуллина)

Әтрәк әл-Каткан турында кыйсса. Алмаз Минһаж
«Татарстан». Рәис Сәфәров
Ә маймылы кайда? Мөдәррис Әгъләмов
Таҗетдин хәзрәт чишмәсеннән. Рухия Ахунҗанова
Ятимнәр сыенган җылы йорт. Ильяс Салихҗан
Җиңүне каршылаган әтием. Рауза Хуҗәхмәтова
Әгәр Фаил исән булса... Эльмира Шәрифуллина
Меценат Э.Ә.Ганиевкә нисбәтле «XIX нчы Кулаткы укулары»


ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА – П2343
РОССИЯДӘ – П7074
www.beznenmiras.ru

***«БЕЗНЕҢ МИРАС»***
***журналына башкача язылу:***
- *uslugi.tatarstan.ru сайты ярдәмендә*
- *редакциядә*
- *podpiska.pochta.ru сайты ярдәмендә*

*электрон версия*

4 612750 670172

*«БЕЗНЕҢ МИРАС» журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» кибетеннән (Бауман ур., 19 һәм 29/11), «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), республикабыз киоскларыннан сатып алырга мөмкин.*